epressa.ru

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2017 **МАРТ № 3**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398


ҖИҢҮЧЕ
дөнья матур икән

КЫРЫКТАН СОҢ
әни булу мөмкин әле

«ОНЫТТЫҢ БУГАЙ»
бер җыр тарихы

Зөһрә УРАЗБАХТИНА:

«ЧЫНЛАП ТЕЛӘГӘН ТЕЛӘКЛӘР ЧЫНГА АША!»



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!



Илсөяр ИКСАНОВА.
Лаеш районы.

1960 елда Идел буендагы урманнарны һәм далалы урманнарны саклау максатыннан, Татарстанда Идел–Чулман дәүләт табигый тыюлыгы булдырыла. Тыюлык ике өлештән – Саралан һәм Раифа бүлекчәләреннән тора. Саралан өлеше көньяктарак – Идел, Чулман һәм Мишә елгалары бергә кушылган урында. Исеменнән үк күренгәнчә, туган авылым Татар Сараланы шушы тыюлыкта урнашкан. Урман шаулавының, Идел киңлекләренең шигърияtемдә аерым урын алып торуы гаҗәп түгел.

Илсөяр ИКСАНОВА

Юк

Төксерләрдән биек таулар юк, дип
Ышаныплар йөрдек күңелдән.
Умырзая үскән текә ярлар
Аксыл томаннарга күмелгән.
Иделләрдән дә киң елга бар, дип
Бәхәсләшер кемнәр арада?!
Безнең сабый-самим карашыбыз –
Йомшак песи бөдрә талларда.
Умырзая иле – Төксер тавы
Кичерәеп калды берзаман.
Памирлар бар икән,
Һималайлар...
Иделләрдән дә киң елгалар...
Диңгезләрне күреп хәйран калдым,
Җилкендерде мәгъръур таулары.
Горур таулар
Минем күңелемнең
Иркә хисен тоя алмады.
Хыял биеклегем – Төксер тавы,
Идел шавы – йөрәк тибешем.
Илләр иңләп,
Сагышымнан иңрәп,
Талларына башым иешем.
Бу җанымның ашкынулы хисен
Аңлый алыр башка таллар юк.
Иделләрдән бөек елгалар юк,
Төксерләрдән биек таулар юк!

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Зөһрә Уразбахтина
Фото: Карина Гыйззәтуллина

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 27.02.2017 ел.
Заказ А-470.
Тираж 6140.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

«ЕЛ ХАТЫН-КЫЗЫ. ЕЛ ИР-АТЫ: ХАТЫН-КЫЗ КАРАШЫ»













Тулырак сайтыбызның махсус сәхифәсендә:











Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

Яз кояшы

Яз кояшы
Карашларга нурлар сибә,
Яз кояшы
Яңакларга сипкел чигә.
Кәефләрнең кыңгыраудай чыңлы чагы,
Әбиләр – шат, әниләр – яшь,
кызлар – чибәр!
Яз сулышы
Агачларга бөре элә,
Яз тавышы
Гөрләвекләр булып көлә.
Зәңгәр күктә ак болытны
җилкән итеп,
Бәйрәм килә, бар җиһанга
бәйрәм килә!
Яз ашыга –
Кызлар кебек кәс-кәс атлый,
Яз һавасы
Ширбәт төсле шундый татлы!
Дөнья көяз, әйтерсең лә кунак кызы
Яңа күлмәк киеп бүген безгә кайтты.
Яз уята
Егетләрне-кызларны да,
Яз кузгата
Күңелдәге бозларны да.
Рәхмәт инде мәхәббәткә, онытмаган
Бу дөньяда сезнең белән без барны да!

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



16+

ТАҢГА – ЧУЛПАН, ЭФИРГА – ЗӨҺРӘ!

РЕКЛАМА

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8

ЗАЛИМНӘРГӘ ҖӘЗА ЙОМШАРА

М. Авзалова



22

ЯХШЫ ӘНИ. НАЧАР ӘНИ...

Л. Әбүдәрова



«БӘХЕТ» ТУКТАЛЫШЫНДА

Э. Закирова

12

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





26

«КҮЛМӘК СИНЕ ҮЗГӘРТЕРГӘ ТИЕШ...»

Г. Сафиуллина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 АЛМАЛЫ КӨЯНТӘ
Г. Әдһәм

ЯШӘЕШ 





48 КЫРЫКТАН СОҢ
Г. Насыйрова





50 КАФ ТАУ АРТЫНДА
Р. Миңнуллина

ШУЛАЙ УК: 

38 «ОНЫТТЫҢ БУГАЙ» ОНЫТЫЛМЫЙ...
Г. Рәхим

44 САГЫНЫП КАЙТЫП КЕРСӘҢ...
Э. Закирова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58 БӘЙРӘМ ЧӘЕНӘ – СИННАБОН

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ЧАЛЫ КОШЫ.
МИН ЯЗМЫШНЫ ҖИҢДЕМ.

АХИРӘТЛӘРГӘ КИҢӘШЛӘР.
ӘНИ БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ.

ХАТЫН-КЫЗ БАШТА ЭШЛИ,
АННАРЫ УИЛЫЙ.

«ПАР АЛМА».
БЕР ҖЫР ТАРИХЫ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Радио һәм телевидениене күп тәнкыйтьлиләр, мин дә сүземне тәнкыйтьтән башлыйм әле. Кайсы гына каналны яки радионы ачма, гел бер җырлар, бер үк җырчылар. Үзләре бер җырны кабатлатудан ничек туймыйлардыр, ә менә без, радиотыңлаучылар, гел бер җырлардан бик туябыз.

Радионы ачсаң, алып баручылары көлешеп, сөйләшеп утыра. Алай утырганчы, күңелгә ятышлы матур җырлар тапшырсыннар иде. Алар күп бит, кайберләре инде онытылып та бара. Радиолар халык өчен эшләргә тиештер бит. Тапшырулар да халык өчен булырга тиеш ләбаса.

Мин үзем дә җырларга бик яратам. Тыңлаган кеше: «Син чын артистларча җырлыйсың бит, радиога барып кара әле», – диләр. Түли алмагач, радиога яздырмыйлар мена. Кассетага яздырып та илтеп караганым булгалады. Моннан бер-ике ел элек «Акчарлак» газетасы җыр конкурсы уздырган иде. Катнашасым килеп, мин дә килдем. Газетаның беренче битендә фотом да басылып чыкты, әмма конкурста катнаштырмадылар.

«Сиңа миннән сәлам» тапшыруында бер җыр җырлату өчен матур гына акча түлисе. Әле анда да вакытны әрәм итеп, шакмак уены уйнап утыралар. Һич аңламыйм, ник кирәк ул уен монда? Вакытны шуңа исраф иткәнче иң матур, күңелгә ятышлы җырлар тапшырсалар, күпкә файдалырак булыр иде.

Икенче сүзем, мәчетләр һәм дини белем турында. Ахыр заман алдыннан: «Дине булыр, дин тотучысы булмас», – дигәннәр. Әнә шундый заман килде. Мәсәлән, безнең шәһәрдә дини белем алыйм дисәң, аена 450 сум түлисе. Мин үзем Казанга йөреп укыйм, анда бушка укыталар. Имамга: «Мәчетнең эчен-тышын мәрмәр белән бизәр өчен спонсор тапкансыз бит, теләсәгез, абыстайга түләр өчен дә акча таба аласыз. Спонсорлар бар ул, җыелган гөнаһлары өчен акча китерүчеләр күп», – дидем. Миңа – инвалид һәм тол хатынга, укыган өчен түлисең килмәсә, ни өчен инвалид булуың турында белешмә алып кил, диделәр. Алып килмәдем. Бер төркемдә без 15 кеше укыдык, алар түләп, мин түләмәсәм, Аллаһы кушканча булмас иде.

Хәзер хәтта имамнар да байлык дип чаба. Безнең бер хәзрәт яңа бизнес ачып җибәргән: 4000 сумга үлгән кешене юып, кәфенләп, җеназа намазы укып озаталар. Кеше кайгысыннан бизнес ясау дөрес буламы? Бәлки, ире үлеп, хатыны тол, балалары ятим калгандыр. Иртәгә ничек яшәрбез, дип, кан калтырап торалардыр. Бу акча аларның соңгы акчасыдыр. Андыйлар нишләргә тиеш инде хәзер? Күптән түгел энем Хәмзә вафат булды. Аны хатынының авылына алып кайтып җирләделәр. Транспортны эш урыныннан бирделәр. 4000 сум алып кайтырга да, юарга да, кабер казырга да җитте.

Ә менә безгә үрнәк булырга тиешле имамнарның кигән киемнәре, йөргән машиналары, яшәгән йортлары гади халыкныкыннан аерылып торырга тиешме? Байлык дип яшәү Аллаһы Тәгалә кушканча яшәү буламы? Мәчет кибетләренә керсәң, алардагы товарлар башка кибетләрдәгедән кыйммәтрәк. Ни өчен шулай ул? Бу турыда үзебезнең хакимият башлыгыннан сорагач, мәчеткә су, ут, җылылык өчен түләргә кирәк бит, дип җавап бирде. СССР заманында заводта эшләдем. Шунда завод директоры болай дигән иде: «Чиновниклар, медицина, полиция, сәүдә, бухгалтерия – барысы-барысы да – җитештерүчеләр хисабына яши. Синең 8 сәгать эшләгәнеңнең 15 минуты өчен генә хезмәт хакы түләнә, калганы әнә шул оешмаларны асрау өчен тотыла». Димәк, шулай булгач, минем кебек гади эшче халыкны түбәнсетеп караучылар кем хисабына яшәгәннәрен бераз уйласыннар иде.

Миңнур НУРИЕВА.
Түбән Кама шәһәре.



Өлкән килендәшем, олы йөрәкле җиңгәбез Рушан Әлки районы Карамалы авылында туып, гомере буе шушында яшәгән кеше. Сугыш афәтләрен дә кичерергә туры килә аңа.

Рушан апабыз бер минут та эшсез тора алмады. Ишле балалы зур гаиләгә килен булып төшеп, нәсел-нәсәп, кардәш-ыруга ачык

йөзле, тәмле сүзле булып, өлкәннәргә хөрмәт күрсәтеп яшәде.

Рушан апа яшьлегендә башкарган эшләрне хәзер авылда да онытып баралар инде. Иртә таңнан сыер савып, җәй көннәрендә сәгать өчтәдүрттә көтү куа авыл хатыны, мичепә утын салып, ут кабызып җибәрә, мич алдында таба-чуен белән кайнашып, ризык әзерли, мичтә күмер төшкәч, самавырын куя. Ул арада җилкәсенә чиләккөянтә асып, тау астындагы чишмәгә йөгерә. Казан асты учагына ут элдереп, учак өстендәге казанда аертырга дигән сөтне җылытып ала. Кул белән сепарат әйләндереп, сөт аерта, каймакны гөбедә атлап, май яза. Аннары бу казанны юып, аш, бәрәңге пешерәсе. Кайвакыт шушында ук корт та кайнатыла. Аннан соң казанны юулары бер әҗәл була инде.

Болар өстенә, ул таба-чуеннарны, самавырны ком белән ышкып ялтыратасы, агач идәннәрне, түшәмнәрне кырып-кырып юасы, мич агартасы, кул белән керен уасы (хәзерге порошоклар юк, кер юу машинасы турында әйтеп тә тормыйм) – куллар гына чыдасын.

Эш дигәннән, Рушан апа сөйләгән бер мәзәк искә төште.

Бер ир, көне буе нәрсә генә эшлисең, дип, хатынын битәрли икән. Беркөнне эшне алмашкан болар, хатыны ире урынына эшкә чыгып киткән, ир өйдә бала белән калган. Ир күңеленнән хатыны әйтеп калдырган эшләрне барлап, хәзер ипи салам, аннары мунча ягам, дип йөргәндә, бала уянып елый башлый, эше бүленә. Инде аны көйләп, кабат эшкә тотынам дисә, түтәлгә тавыклар кергән, аларны куып чыгара. Ул арада казлар җим сорап каңгылдаша. Аннары тагын бала уяна. Хатын кайтып кергәндә, казанда аш ташып ята, самавыр куелмаган да, ире, атлап-атлап та мае төшмәгән гөбене бау белән аягына бәйләп куйган, имеш, йөргәндә, селкенеп, май төшмәсме. Ә үзенең кулында бертуктаусыз елаучы яшь бала...

Рушан апабыз әнә шулай илдә йөргән мәзәкләрне хәтерендә саклап, җае чыкканда ялт итеп сөйләп бирә торган иде. Җырбиюгә дә һәвәс булды, сүзгә дә бик оста иде.

Аның кулыннан килмәгән эш булмагандыр. Эш күплектән, авырлыктан зарланганын хәтерләмим. Авыр хезмәттә үткән гомерен мәзәк кушып, уен-көлке белән сөйләр иде. «Иң яхшы эш кораллары гел миндә булды. Иң үткен чалгы, уң уңайлы тәпке минеке, су ташый торган чиләкләрне үземә дип атап ясадылар. Пычаклар, сарык йонын кырка торган кайчылар бар да җырлап эшләп тора торган иде», – дип, тимерче кайнатасын, ирен мактар. «Унҗиде егет арасыннан Таһир абыегызны сайлап чыктым, ул бит данлыклы тимерче Закиров Сәгыйрь малае», – дип шаяртырга ярата иде.

Ул вакытта колхоздагы эшләр бар да кул көче белән башкарыла. Закирова Рушан Мотыйгулла кызы урман да кисә, ат та җигә, фермада бозаулар, сарыклар да карый, яшелчә бакчасында эшли, Ярославль якларына торф чыгарырга да бара. Гомумән, нәселебез тырыш, танылган кешеләргә бай. Сәүдә министры урынбасары булып эшләгән Вагыйз абый Закиров, аның хатыны атаклы күз табибы Хәят апа Килдиева, «Спартак» аяк киеме комбинатының генераль директоры Абдулла абый Кыямовларның барысы өчен дә җиңгәбез «безнең Рушан» булды. Табигатьтән бирелгән зирәклеге аңа белемле, дәрәҗәле кешеләр янында да үзен дәрәҗәле итеп тотарга, һәркемгә иш була белергә ярдәм иткәндер. «Безнең Рушан кем янына да сыя ул», – ди торган иде Әлки районының ул замандагы абруйлы хуҗалык җитәкчесе Дамир Насыйбуллин.

Тырышлыгына өстәп, күңеле дә киң иде Рушан апаның. Хәтеремдә, нәселебезнең олы-карысы исән вакытта Рушан апа белән Таһир абый карчыкларны кунакка чакыралар иде. Алар үзара рәхәтләнеп сөйләшеп, җырлашып, бергә намазлар укып, берәр атна кунак булып китәләр иде. Бу вакытта фермада эшләгән Рушан апа очып кына йөри, тәмле ризыклар әзерли, мунчасын яга.

Яшьләрнең дә күңелен күрә белде алар. Нәселебездә берәрсе гаилә корса, яшь гаиләне, аларның дусишләрен, күрше-күләнне чакырып кунак итәләр, бәйрәм ясыйлар иде. Ул чакта мәҗлесләр мул сыйлы, уен-көлкеле, вәгазь-нәсыйхәтле дә булып, тормыш итү, дөнья көтү дәресләренә охшап кала торган иде.

Килен-кайнана темасына Рушан апаның тагын үз мәзәге булыр иде.

Бер өйдә килен белән кайнана ызгышып яши икән. «Безгә килгәндә, өстәлгә капларга ашъяулыгың да юк иде», – ди икән кайнана. Килен бер дә аптырап тормый: «Мин килгәндә аның юньле өстәле дә юк иде бит», – дип җавап кайтарган, ди.

Икенче бер йортта килен белән кайнана бик тату яшиләр икән. Берсендә кайнана, күңеле нечкәреп китеп, киленнән сорый икән: «Килен, син мине күбрәк яратасыңмы, үз анаңнымы?» – «Әни, бәгърем, син менә мине күбрәк яратасыңмы, үз кызыңнымы?» – дип, сорауга сорау белән җавап биргән ди килене.

Абдулла абыебыз өченче ел җәй ахырында Америкага китәр алдыннан Карамалыга кайтып, Рушан апаның хәлен белеп, бәхилләшеп чыккан иде. Рушан апа шуннан соң озак яшәмәде инде. Хезмәт сөючә, киң күңелле, игелекле Рушан апабыз күңелләребездә якты, матур хатирәләр калдырып китте. Кайткан саен, безне озатканда бер җыры бар иде Рушан апаның:

Чәй эчәбез чәйнүкдин,
Бабаебыз Гайнетдин.
Әбиебез Хәерниса,
Кайтырсыз, Алла боерса.
Кайтырбыз, Алла боерса, туган нигезгә, зиратларга кайтырбыз.

Нәҗия НАСЫЙБУЛЛИНА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

ТӨП ТЕМА



ЗАЛИМНӘРГӘ ҖӘЗА ЙОМШАРА

ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫ ГАИЛӘДӘГЕ ҖӘБЕР-ЗОЛЫМГА КАГЫЛЫШЛЫ ЯҢА ЗАКОН КАБУЛ ИТТЕ. БЕРЕНЧЕСЕНДӘ – ШТРАФ, ЗОЛЫМ ЕЛ ДӘВАМЫНДА ТАГЫН КАБАТЛАНСА – ТӨРМӘ...

Фото интернеттан алынды



Мәдинә АВЗАЛОВА

Белмим, кыйнауларга яңача караш ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне кайчан да бер җайга салырмы-юкмы – әйтүе кыен. Моңарчы да бит гаилә хәлләренә кагылышлы законнар булмады түгел, булды. 2016 елның июль аенда чыккан законны гына искә төшерик: хатынга кул күтәргән ирне, сәламәтлеккә җиңелчә зыян китергәндә, алты айга кадәр кулга алу яисә 360 сәгать мәҗбүри эш, ә каты зыян салганда ике елга төрмәгә ябып кую каралган иде. Депутатлар моны гаилә мәнфәгатьләренә туры килми торган зур хата, дип таптылар. Һәм менә... яңасы. Ул «Гаиләдә җәбер-золымны декриминализацияләү» дип атала, ягъни мәсәлән, сүз биредә хатынын кыйнаган иргә җәзаны йомшарту турында бара. Беренче мәртәбә кыйнаганда, әгәр дә хатын җитди зыян күрмәсә, ирне административ җаваплылыкка гына тарталар: бу – 30 мең сумга чаклы штраф яки 15 тәүлеккә мәҗбүри эш. Ә инде кыйнаулар икенче мәртәбә кабатланса, 40 мең сум штраф, йә 240 сәгать мәҗбүри эш яки 6 айга төзәтү эшләре, йә ул 3 айга кулга алына.

Зур бәхәсләр кузгаткан әлеге закон, халык арасында сораштырулар алып барылганнан соң, гаилә язмышын хәл итә торган әлеге мәсьәләгә карата уртак бер фикергә киленгәннән соң кабул ителде. Чөнки ул гаять катлаулы, четерекле... «Гаилә эшенә тыкшынырга ярамый» кагыйдәсе безне тәмам төп башына утыртты. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, авыр җинаятьләрнең 40 проценты гаиләдә кылына. Шуның һәр унынчысы үлем-китем белән тәгәлләнә. Ел саен

илдә залим кулыннан 13–15 мең хатын-кыз һәлак була. Шуңа да карамастан, сораштырган 1800 кешенең 59 проценты – законны йомшарту ягында; 33 проценты – катгый рәвештә каршы; 40 проценты – законның сүздә генә калачагын белдерә, эшләп китә алырына шикләнә.

Закон кемгә «не по чем»?

Якыныңны кимсетү, кул күтәрү – ул зур җинаятьләрнең берсе. Гаиләдәге чит кеше күрми, белми торган бу афәттән качып котылып буламы? Залим ир белән яшәгән хатыннар моңа ничек карый? Әйе, алар ирне төрмәгә утырту, аннан штраф түләтү ягында түгел. Чөнки бу чаралар беренче чиратта янә гаилә кесәсенә суга. Ирне ябып куйсалар, аның бит бер әйләнеп кайтасы бар. Шул балалары, хатыны янына кайта бит ул. Алдагысы янә билгесез… Ничек араларга соң җәбер-золым корбаннарын бу хәлләрдән? Тиран белән килешеп, аның җәберләвенә түзеп яшәүнең үзе өчен генә түгел, иң элек балалары өчен һәлакәт булуын аңлаган хатын котылгысыз күренгән вазгыятьне көйләүгә беренче адымын ясый. Хатынын тукмаклаган иргә беренче мәртәбәсендә – штраф, ә инде бу хәл ел дәвамында тагын кабатланса, төрмә, дидек. Ни сөйлибез без? Күктән җиргә төшик. Башы көндәлек җәбердән чыкмаган корбаннар да җитәрлек бит һәм бу күп гаиләләр өчен табигыйга әйләнеп бара. Бәлкем, безгә бу мәсьәләдә чит илләр үрнәгенә күз салыргадыр?! АКШта әле 1996 елда ук кабул ителгән «Гаиләдә җәбер-золым турында»гы федераль закон гамәлгә кергәннән соң, «гаиләдә үтерешүләр» саны дүрт мәртәбә кимегән. Хәзер, мәсәлән, хатын-кыздан хәбәр килеп ирешә икән, аның янына шундук махсус әзерлекле полиция хезмәткәре барып җитә. Тормышына, сәламәтлегенә куркыныч яный дип санаган хатын-кыз судьядан үзен саклый торган ордер ала. Нәтиҗәдә, залим, билгеле бер вакытка, гаиләгә якын килә алмый.

Гафу итәргә ярамый

«Бер генә сукты бит…» дип, ирегезне гафу итәргә ашыкмагыз. «Тагын бер мәртәбә шундый хәл булса», – дип тә әйтмәгез. Андый хәл булган ич инде. Бередә: «Яныма якын киләсе булма», – дип, ике арага киртә кую дөресрәк. Ул якыннарына карата начар гамәл кылганын тәмам аңларга тиеш. Гомер буе үкенерлек итәргә кирәк аны.

Җәберләүгә хирыслык – тумыштан килә торган сыйфат. Аны үзгәртеп булмый. Бу хакта хыялланмагыз да. Залимне тәрбияләргә түгел, ә бәлки куркытырга, без әйткән әлеге законнар белән «бастырып» торырга гына була. Башкача берничек тә… Аннары бер күтәрелгән кул икенче, өченче мәртәбә дә күтәрелергә мөмкин. Һәрхәлдә, тәҗрибә шуны күрсәтә. Ләкин нинди генә очракта да хатын-кызның үз хокукларын яклыйсы урында, аны дөмбәсләп тоткан сугыш чукмары ягына басуы үзе үк инде күп нәрсә турында сөйли. Җәбер корбаннары хокук саклау органнарына шикаять белдерергә, гариза язарга ашыкмый. Язган очракта да, җинаять эше ачылып, судка барып җиткәч, күпләр гаризаларын кире ала. Шуңа полиция хезмәткәрләре гаилә эшләренә тыкшынуны кирәк санамый. Моңа алар вакыт уздыру гына дип карыйлар. Чыны шулай бит. Зыян күрүче, эш зурга киткәч, мөнәсәбәтен шундук үзгәртә. Юк, аның ирен утыртасы килми. Юк, аның фәлән меңнәрчә сум акчаны чыгарып бирәсе килми. Ирен җәзага тартырга теләгән хатын документларны үзе җыя. Ә бу бик җиңел эш түгел.

– Шунысы да бар, – ди Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова, – әтисе хөкемгә тартылган бала киләчәктә дәүләт хезмәтендә, эчке эшләр органнарында эшли алмый. Гомумән, халык законнарны белми. Тәрбияне мәктәптән башларга кирәк. Хатын-кызлар үзләренә кагылышлы законнарны белергә тиеш.

Кылганнары өчен җавап тотмау, залимнең аяк-кулларын тагын да ныграк чишеп җибәрә. Ул үзенең җәзасыз калачагына күптән ышанган инде. Психологлар әйтүенчә, арадан бик сирәкләре генә ихластан тәүбәгә килә. Якыннарына нинди зур бәла, хәсрәт-борчулар китерүен аңлый. Ә хатын-кызга шул гына кирәк. Хәер, алар, ирләре бик үзгәләнмәсә дә, чыгып киткән җирләреннән кире әйләнеп кайталар.

Язма әзерләгәндә без ир кул астында тукмалып яшәгән ханымнар белән очраштык. Сүзне шуларның берсенә биреп карыйк әле. Ул сөйләгәннәрдән нәтиҗәне үзегез ясарсыз. Артык сүзләр дә, дәлилләр дә кирәкми бередә…

Депутатлар фикеренчә, яңа закон гаиләдә имин шартлар тудыруны күз алдында тота.

«Чарасызлык шулай итә»

«Барысы да шул килеш калачак. Беркем дә иренә шикаять язып, аны төрмәгә утыртыгыз, дип йөрмәячәк». Бу хакта сүз чыккач, 33 яшендә тормышның бөтен ачысын-төчесен татырга өлгергән, күрмәгәне калмаган өч бала анасы шулай ди. «Менә күрерсез…» – ди ул, зур зәңгәр күзләрен миңа төбәп. Бер караганда, ул бер дә хәсрәт-борчудан, кыен күрүдән башканы белмәгән хатынга охшамаган. Яшь, матур… үз-үзен тотышы да күңелгә ятып тора. Сөйли башлагач та, нинди генә хәлләрдә калмаган, үз вакытында зур хаталар ясаган, шикле юлларда йөргән танышыма карата фикер үзгәрми: ул бит чарасызлыктан шулай эшләгән.

– Бөтен бәхетсезлегем әти үлгәннән соң башланган икән, – ди яшь ханым, сүзен кинәт дөнья хәлләреннән үзенә күчереп. – Җиде яшемдә әти үлеп китте. Мин уйнарга чыгып киткәндә өйдә нәрсәдер эшләп калган иде. Кайтуыма, идәндә ята. Ток сугып үтергән. Күмгәндә әнинең зиратта әйткән сүзе бер дә истән чыкмый: «Ирсез ничек яшәрмен?» – дип елады ул. Соңыннан кайта-кайта уйладым. «Әтиегездән башка ничек яшәрмен» – димәгән

PRESSA.RU

бит. «Ирсез ничек яшәрмен?» – дигән. Гаиләдә без ике бала. Мин – олысы, кечесе – малай. Әни ирне үзенә бик тиз тапты. Ул башта безгә килеп, тегесен-монысын эшләп, әнигә булышкан булып йөрде, аннары бөтенләй күченеп килде. Без генә әтисез калдык.

Мин ул кеше белән уртак тел таба алмадым. Өйдә гел минем өчен тавыш чыга торган иде. Иң сәере: әни мине түгел, шул кешене яклый иде. 16 яшем тулуга, өйдән бөтенләйгә чыгып киттем. Барып сыеныр урыным юк иде. Эшкә дә алмадылар башта. Яшь идем бит. Белемем дә чамалы... Әле төзелештә эшләп, әле подъезд җыештырып йөрдем. Әни мине эзләмәде. Бер генә мәртәбә дә кайдалыгым, нишләп йөрүем белән кызыксынмады. Бер-ике мәртәбә үзем шалтыраттым. «Кем бу?» – ди, танымый мине. Йә танымаганга салынгандыр, кем белә? Шундый әниләр дә бар, – ди ул, минем гаҗәпләнүемне күреп.

Хатын-кызның бик сирәге генә, хокукларын яклап, судка мөрәҗәгать итә.

«Исәп буенча язылыштык»

– 17 яшемдә бер егет белән таныштым. Аңа ул чагында утыз яшь иде. 18 тулгач, язылыштык. Мәхәббәт тә, бер-береңә тартылу, хис дигән нәрсә дә булмады. Ул миңа тәкъдим ясады, мин чыктым. Миңа кайдадыр яшәргә кирәк, ә аңа – чит илгә чыгып эшләү өчен өйләнгән кеше булуын дәлилләүче паспорт. Ул миңа бер бүлмәле фатирын калдырды да, чит илгә китеп барды. Вакытлыча, билгеле. Ике елдан ул кайтты, һәм без аерылыштык. Ул чагында мин төнге клубта җыештыручы булып эшли идем. Фатирга кереп торыр өчен азмыкүпме акчам да бар. Көтмәгәндә авырып киттем. Салкын тидергәнмен, күрәсең. Табиб миңа әйтә: «Син, – ди, – йә хәзер бала табасың. Йә бөтенләй баласыз каласың».

Ә миңа бала кирәк. Мин балалар яратам. Ышансагыз, ышаныгыз, ышанмасагыз, юк: мин бала табар өчен ир кеше эзли башладым. Таптым. Сөйлим аңа, аңлатам: «Бары үземнеке булыр, сиңа бернинди дәгъва булмас. Миңа бала кирәк», – дим. Ялвара торгач, ризалашты. Мин йөккә уздым. Бала табарыма ике атна кала эштән киттем. Шуңарчы эшләдем. Балага акча кирәк булачак бит. Малай тапкач, дус кызыма күченеп килдем. Әнисе бик әйбәт аның. «Бәбиеңне үзем карармын», – дип, мине өч атна узуга, эшкә чыгарды. Балага бер яшь тулганда, әйтә миңа: «Үпкәләмә, арыдым, карый алмыйм», – ди. Кая инде үпкәлисең. Үз әниең түгел ләбаса. Әйберләремне җыйдым да баламны күтәреп чыгып киттем. Өч көн урамда кундык. Ярый әле көннәр җылы торды. Салкын булса, нишләр идең? Ул вакытта кесәмдә җилләр уйный. Ә баланы ашатырга кирәк, кайдадыр яшәргә...

Уйладым-уйладым да «досуг»ка киттем. «Анысы ни була тагын?» – дим, әңгәмәдәшемне бүлдереп. – Фахишәлеккә, – ди ул, берни булмагандай. – Нишләргә иде соң миңа? Акча юк, яшәргә урын юк, ярдәмчем юк... Баланы бакчага урнаштырдым да, дүрт ел шул эш белән шөгыльләндем. Ниләр генә күрмәдем: кыйнадылар да, төн уртасында урманда ташлап та калдырдылар. Үземә: «Аз гына түз, бала хакына түз...» – дип әйтә торган идем. Хәзер бик үкенәм, дүрт ел баламны чит кулларда үстердем. Үзем күрмәдем дә.

«Ул мине куды, мин тагын кайттым»

...Һәм көннәрдән бер көнне мин булачак ирем белән таныштым. Клиентларымның берсе иде ул. «Туймадыңмы әле болай йөрүдән? Балаңны соңгы мәртәбә кайчан күрдең?» – ди бу миңа, чираттагы очрашуларның берсендә. «Туйдым, бик туйдым», – дим. «Китәсеңме минем белән, минем авылда фатирым бар», – ди, үзенә чакыра. Ике дә уйламадым. Миңа мондый тәкъдимне тагын кайчан ясарлар әле?! Малайны алдык та авылга күченеп килдек. Икенче балага узгач, мин аңа «С» гепатиты белән авыруымны әйттем. Әйтмичә булмады, барыбер белер иде. Шул вакыт беренче мәртәбә өйдә зур тавыш чыкты. «Теләсә кем белән өстерәлгәнгә ул», – ди, мыскыл итә. «Аңа түгел, бу чир бары кан аша керә», – дип аңлатам, аңламый. Тәнемә тату ясаткан идем. Чиста эшләмәгән, күрәсең. Шунда гына эләктердем. Әй, үкенгән нәрсәләр күп инде. Өйрәтүче булмады, булышучы булмады. Әни сүзе юк та юк инде.

Тагын малай туды. Сау-сәламәт бала. Бераздан тагын авырга уздым. Ирем: «Кыз булмасмы?» – дигәч, тагын төшертмәдем. Өченчесе дә малай туды. Мин балалар белән өйдә, ул да өйдә, беркайда эшләми. Өч бала белән тәртип саклап булмый. Ә ул: «Син шуны да карамыйсың», – дип миңа кычкыра. Аннары кыйнарга ук тотынды. Өстемә бензин сибеп, артымнан: «Яндырам», – дип куып йөргәннәрен әле дә онытасым юк. Кыйнаганда биткә тими, аяк-кулга тибә иде. Шундый чакларда өч баланы алам да, күзем кая карый, шул якка чыгып качам, йөрим-йөрим дә, тагын әйләнеп кайтам. Үзенең өстенлеген, минем барыбер кайтасымны белә иде ул. Чыгып китүемә шуңа күрә аз гына да борчылмый иде.

Соңгы мәртәбә, 2 гыйнвар көнне булды. Бик ярсыды. Хәтта үз баласы дип тә тормады. Уйнап утырган баланы тибеп кенә очырды да өстемә ташланды. Хәле беткәнче кыйнады. Күгәрмәгән бер җирем калмады. Балалар елаша, мин елыйм. Нәкъ шул вакыт кайнанам килеп керде. «Полиция чакырт, үтерә бит», – дим. «Чыгып кит. Минем бердәнберем ул», – ди әнисе. Оныклары турында уйламый да. Чатнама салкын көндә өч бала белән урамда калдым. Олы малаема 10 яшь. Уртанчысына – өч, бәләкәенә 1 яшь тә 10 ай. Өсләренә рәтләп кигертә дә алмадым. Олы малаем бер футболкадан, аягында ноские да юк. Дус хатыныма киттек. Ишекне ачмый. Кунакка китеп барган икән. Балалар белән төнлә урамда кала алмыйм бит инде. Ни дә булса

эшләргә кирәк. «Добро даром» хәйрия фонды турында ишеткәнем бар иде. Шунда шалтыраттым. Шундук җавап бирделәр. Адресны әйттеләр, ничек эзләп табарга икәнлеген өйрәттеләр. Дүртәүләшеп килеп кердек. Балалар дер-дер калтырана. Киендерделәр, ашарга утырттылар. Без анда дүрт көн яшәдек. Шул вакыт эчендә мин үземнең күптәнге хыялымны тормышка ашырдым дисәм дә була. Икенче балага бирелгән Ана капиталына авылдан бер өй сатып алдым. Үземнең өй! Күз алдына китерәсезме?! Бакчасы бар, бәрәңге утыртырга җире бар, сарае бар. Их-х, – ди ул, хыялга бирелеп, – сыер да алып җибәрсәм. Яратам мин авылны, балалар да рәхәтләнер иде.

– Алайса, барысы да тәртиптә. Авылга китәсе генә калды.

– Юк, – ди ул, мине шундук туктатып, – ирем чакыра: «Кайтыгыз, бүтән рәнҗетмәм, йортны да балаларга яздырам. Кайтыгыз гына...» – ди.

– Кайтасыңмы? – дим, әйткәненә хәйран калып.

– Кайттым инде! Авырый ул. Минем ярдәмгә мохтаҗ, – ди ханым, тагын да гаҗәпкә калдырып. – Укол ясыйм. Ашатам-эчертәм, минем дүртенче балам ул хәзер. Әле менә кибеттән аңа җылы свитер алган идем, кечкенәрәк булган. Алыштырам, – ди ул, миңа иремә алган бүләген күрсәтеп.

Хатын-кыз диген... Кыйналган, кимсетелгән хатын-кыз. Әнә бит аңа ире нинди якын. «Балаларымның әтисе», – дип, барын да кичерергә әзер. Ә без судка мөрәҗәгать итәр, гариза язар, дип өметләнәбез. Һай, белмим, язарлар микән. Ә менә саубуллашканда ханым миңа: «Үзең өчен көрәшергә кирәк! Җебеп йөрмәскә!» – дигән сүзләрне әйтте әйтүен. Әмма ул бит: «Кыйнаса, төрмәгә утыртырга», – димәде. «Барысы да шул килеш калачак», – диде.

Биредә язылганнарның берсе дә уйлап чыгарылган түгел. Бу язмыш артында иреннән җәбер-золым күреп яшәгән меңнәрчә хатын-кызларның язмышы ята.



Татарстанда кеше хокуклары яклау буенча вәкаләтле вәкил Сәрия САБУРСКАЯ

Хатын-кызны җәберләү-кыерсыту – кеше хокукларын бозу гына түгел, ә бәлки җәмгыятебезне тарката, нәтиҗәсе, билгеләре бик тирәнгә үтеп керә торган куркыныч күренеш. Бүген без моны иң җитди социаль һәм сәяси проблема буларак кабул итәбез. Дәүләтебез, һәм әлбәттә инде, иҗтимагый оешмалар игътибарын шушы афәткә юнәлтергә тырышабыз. Без бит моңарчы гел гаилә эшләренә тыкшынырга ярамый, дигән фикердә булдык. Безгә шулай уңай иде. Чит хатынны кыйныйлар бит, чит гаилә җәфалана бит... Бүген гаилә, ир белән хатын мөнәсәбәтләренә, бу безнең дә проблема, дип карарга күнегеп киләбез. Башкача мөмкин түгел. Саннарга гына күз төшерик: дөньяда ел саен иреннән золым күргән хатыннарның саны 1800 меңгә җитә. Бу мәсьәләдә безнең ил дә калышмый. Мисал өчен, Татарстан буенча гына да 2016 елның ноябренә 7236 хатын-кызның кыйналуы, 28 енең үлем очрагы теркәлгән. Илкүләм алганда, һәр дүртенче гаиләдә шундый хәл. Былтыр безгә 3549 кеше мөрәҗәгать иткән. Шуларның 45 проценты – хатын-кызлар. Бу сан ел саен 1,1 мәртәбә арта бара. Димәк, ышаналар безгә. Кызы каты авырып киткәч, фатирын сатып, кызы белән бергә Мәскәүгә киткән, баласын аякка бастыру өчен кредит алырга мәҗбүр булган һәм хәзер менә икәүләшеп урамда калган ана белән кызның хәлен бик яхшы аңлыйм мин. Ничек ярдәм итмисең аларга?!

Узган ел торак мәсьәләләре буенча 425 гариза һәм шикаять кергән: кемдер торакка чиратны торгызуны, кемдер социаль ипотека программасы буенча фатир сайлау хокукын даулап килә. Коммуналь хезмәткә түләүләрдән риза булмаучылар да күп.

Чаллы, Тукай, Лаеш районнарында яшәүче күп балалы әниләрне җир белән тәэмин итү мәсьәләләре кызыксындыра. Бу да актуаль проблемаларның берсенә әверелеп бара. Әмма, әйткәнемчә, иң җитди проблема – гаиләдәге җәбер-золым. Иренең рәхимсезлегеннән зарланып килүче хатыннар бездән яклау эзли. Ана кешенең бердәнбер теләге – баласын сәламәт һәм бәхетле итеп үстерү. Ә гаугалы гаиләдә моның булуы мөмкин түгел. Былтыр безгә иреннән качып, «Добро даром» кризис үзәгендә яшәргә мәҗбүр булган биш бала анасы мөрәҗәгать иткән иде. Минемчә, гаиләдәге җәбер-золым кемнеңдер шәхси эше түгел. Бу – кеше хокукларын бозу. Ул гаиләләрне тарката, милләтебез сәламәтлегенә зур зыян сала. «Хатын-кызга карата дискриминациянең барлык төр формаларын бетерү турында конвенция» 1979 елда кабул ителгән иде. Аны башкача «Хатын-кызлар конвенциясе» дип тә атыйлар. Ә 2008 елда БМОның Генераль секретаре Пан Ги Мун «Хатын-кызны җәберләүгә каршы бергәләшеп алыныйк» дигән шигарь астында бу эшкә хөкүмәтне, җәмәгатьчелекне, иҗтимагый оешмаларны күтәрү тәкъдиме белән чыкты.

Гражданнарның хокукларын саклауга юнәлдерелгән законнар бездә җитәрлек: әйтик, Конституциябез буенча беркем дә кыерсытылуларга дучар ителергә тиеш түгел. Җинаять кодексы, Гаилә кодексы да хатын-кыз һәм бала, гаилә хокукларын саклый, яклый... Ләкин кайбер белгечләрнең фикеренә караганда, безнең законнар хокук бозучылар белән кисәтү чаралары алып баруны күздә тотмый. Алар җаваплылыкка законнарны бозганнан соң гына тартыла, ягъни мәсәлән, эш узгач кына... Хатын-кызны кыйнау фактлары булмый торып, гаилә эшенә тыкшынырга дәүләтебезнең хакы юк. Зыян күрүчене яклый торган механизмнар эшләнмәгән. Еш кына гаепләне штрафка тарту гаилә өчен чын мәгънәсендә җәзага әверелә. Штраф дигәнебез төзәтмәләр белән кабул ителгән яңа законда да каралган ул. Ничек эшләп китәр, анысын вакыт күрсәтер. Дәүләт Думасы депутатлары тарафыннан «Гаиләдә җәбер-золымны декриминализацияләү» турында кабул ителгән яңа закон бу хәлләргә чик куяр, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләргә ярдәм итәр, ә иң мөһиме: балалар зыян күрмәс, дип уйлыйм.

PRESSA.RU









«БӘХЕТ» ТУКТАЛЫШЫНДА

ТҮБӘН КАМАЛАР ОЕШТЫРГАН ЧАРАЛАР ҺӘРВАКЫТ ҮЗЕНЧӘ, ЯҢАЧА, КАБАТЛАНМАС БУЛА.

Эльмира ЗАКИРОВА

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең Түбән Камада узган зона турыннан да без сокланып, һәр чыгышка җан атып, уңган-булган хатын-кызларыбызны барлап кайттык. Химиклар шәһәренең генә түгел, республиканың мактанычы булырдай асыл затлар шактый икән бит Түбән Камада! Түбән Кама муниципаль районы башлыгы һәм Түбән Кама шәһәре мэры урынбасары Долотказина Эльвира Рәфгать кызы бу эштә үзе башлап, кызларны энә күзеннән үткәреп әзерләп йөргәч соң! Булдырасыз, дип, илһамландырып торучылары да әле ул! Беренче чыгышларны күрү белән үк жюри югары баллар тезә башлады. Һәркайсы кабатланмас! Кайсын сайларга?



АЛСУ МӘРДАНОВА. «ХАТЫН-КЫЗ – ЕЛ ҮРНӘГЕ» НОМИНАЦИЯСЕ

Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсе инженеры, яшь белгеч Алсу Мәрданова активлыгы, үзеннән сирпелгән яхшы энергетикасы белән бөтен залны җылытты! Әйдәгез, аның чыгышын кабат күз алдыннан уткәрик әле. Менә ул сәяхәтләр ярата торган Алсу. «Тормыш үзе дә күпмедер дәрәҗәдә сәяхәт. Бик күп тукталышлары, маршруттагы үзгәрешләре белән...» – дип, ул тамашачыларны да юлдашлары итеп, мавыктыргыч сәфәргә алып китте.

Поезд. Купе-вагон. Үзенә бер атмосфера, тәгәрмәчләр тыкылдавы, тәрәзәдән ялтырап күренеп калган пейзажлар... Яшьләр ерак сәфәргә җыенган. «Мәктәп» иленнән китәр вакытлары җиткән, алда – «Аттестат» станциясе. Араларында мәктәп, шәһәр бәйгеләрендә җиңгән, фәнни-тикшеренү конференцияләрендә призлы урыннар яулаган Алсу да бар. Тик... алтын медале, китаплар шыплап тулган чемоданы белән юллар чатында калган ул. Нишләргә, кая барырга? Сыйныфташлар «Алабуга», «Казан», «Мәскәү», «Санкт-Петербург» станцияләрен сайлаган. Ә Алсу өчен бабалары нигез салган Түбән Камадан да матуррак, кадерлерәк бер җир юк дөньяда! Әнә туган шәһәренең утлары балкый. Алсуның станциясе – «Түбән Кама химия-технология институты». Анда кызыклы, мавыктыргыч тормыш! Укуның өченче елында инде ул инглиз теле дөньясын ача. Тора-бара инглиз теле тылсымлы ачкычка әйләнә. «Мәгълүматны эшкәртү һәм идарә итүне автоматлаштыру системасы инженеры» һәм «Профессиональ коммуникацияләр өлкәсе тәрҗемәчесе» дигән кызыл дипломнарын тотып, Алсу Түбән Кама «Нефтехим» станциясенә баручы поездга утыра. Анда кызны җитештерү белән бәйле катлаулы дөнья, яңа кешеләр көтә. Һөнәри сәяхәтендә җитди үзгәрешләр дә була. Бөтенроссия конкурсында «Россиянең яшь инженеры» исемен яулый! Эштән тыш мавыгулар да бар бит әле! Туган ил шәһәрләрен, диңгез-тауларын күреп кайту бик ошый Алсуга. Җай чыгу белән ул кулына китап ала. Китап үзе дә сәяхәт бит инде. Моңарчы күрмәгән шәһәрләргә, ерак үткәнгә, ашкындырган киләчәккә, башка планеталарга барып чыга. Юл йөрүдән арыса, кулына төрле җепләр, сәйләннәр, энҗе-мәрҗән бөртекләре ала. Һәр сәяхәтнең алдагы тукталышы бик мөһим. «Кая бара бу кыз?» – дип сорарсыз. Алдагы тукталыш – 50 ел элек Балтач районы Оры авылында әбисе һәм бабасы тукталган станция булыр, әлбәттә. «Бәхетле гаилә тормышы» дип атала ул. Таяныч булырдай ышанычлы юлдашы да бар! Билеты – кулда, поездны гына көтәсе калды.

Җәй кызы Алсу, кояш кебек балкып, чәчәкле күлмәк итәкләрен җилфердәтеп, ерактан балкыган Түбән Камасын кочардай булып, яңа тукталышына таба йөгерде...



ГҮЗӘЛ ГЫЙЛАЕВА «ХАТЫН-КЫЗ – ГАЛИМӘ» НОМИНАЦИЯСЕ

Ул инде чыннан да Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсендә экология проблемаларын чишү буенча конкрет эшләр башкарган, яңа физик-химик һәм биологик технологияләрне камилләштерү өчен күп тәҗрибәләр уткәргән фән кешесе! Сүзе һәм эше белән табигатьне саклауга йогынты ясый торган галим-белгеч. Фәнни-тикшеренү үзәгенең файдаланылган суларны тикшерү лабораториясе начальнигы. Казан дәүләт технология университетында «Әйләнә-тирәне саклау техникасы һәм технологиясе» белгечлеге буенча укыган. «Экология» буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Техник фәннәр кандидаты.

Ун минутта үзең, яраткан эшең, сине чолгап алган дөньяң турында ниләр генә сөйләп була соң?

Үзләренең берләшмәсендәге биологик чистарту корылмаларында реконструкция уткәрү турындадыр, мөгаен. Бөтен Түбән Кама районы һәм шәһәрендәге сәнәгать үзәкләренең файдаланылган суларын чистарта. Чистартылган су Кама елгасы сусаклагычына агызыла. Мөһим балыкчылык хуҗалыгы мәйданы һәм эчә торган су чыганагы да бит ул. Тикмәгә генә Түбән Кама халкы суны краннан агызып кына эчми шул! Уйлап карасаң, без җәй көне коена, зур йөк баржалары йөзә торган елганың суы инде. Эчәргә яраклы булганчы санитар нормаларга туры килерлек итеп чистартыла. Бу эш катлаулы гына түгел, җаваплы да. Ә кешеләр белә микән: суның туган көне бар! 2 стакан чиста су... аруны, начар кәефне юкка чыгара! Галимнәр... суның «хәтер»е барын да исбатлаган!

Гүзәл үзе тарафыннан сыналып, кулланылышка кертелгән нитри- һәм денитрификация ысулы белән азотны тирәннән арындыру, азот һәм фосфор реагентларын, биофильтрдагы газларны чистарту технологияләрен мавыктыргыч итеп сөйләргә җыенган иде башта.

PRESSA.RU

Ләкин бу бит фәнни-гамәли конференция түгел, дип, уйларыннан кире кайтты.

1978 елда, Идел белән Чулман кушылган урында, изге Болгар җирендә тууы, туган ягының гүзәл табигате, зур сулары белән илһамлануы, мәктәп сәхнәләрендә үк «Кара пулат» легендасыннан өзекләр башкаруы, Алтынчәч ролен уйнавы – берсе дә эзсез калмаган бит! Алар барысы Гүзәлне табигать баласы, янәшәдәгеләренә ихтирамлы, әйләнә-тирәгә сакчыл карашлы кыз итеп үстергән! Әкренләп эколог һөнәренә әзерләгән. Математика, физика буенча республика олимпиадаларында катнашуы, мәктәпне медальгә тәмамлавы исә аның фән дөньясына кереп китәренә бер ишарә булган.

Студент елларында ук Түбән Камага китәргә карар кылган була ул. Яшь фән кандидатын химиклар шәһәре колач җәеп каршылый. Гүзәл Гыйлаева шәһәрне бер күрүдә ошата. Яшеллек, төзек урамнар. Исемнәре үк күңелгә ятышлы: Сөембикә, Чишмәле, Ямьле, Чулман... Ә кешеләре!..

Гүзәл беренче тапкыр эшкә килгән көнен искә төшерә. Фәнни-технология үзәгенең икенче катына күтәрелеп, кабул иту бүлмәсенә уза. Һәм шунда берничә яшь ир-егетнең татарча сөйләшүен ишетеп, хәйран кала. Гаҗәпләнә дә, сөенә дә. «Казанда бит яшьләр болай рәхәтләнеп татарча сөйләшми», дигән уй йөгереп уза. «Әңгәмәгә директор кабинетына узыгыз!» – диләр аңа. Фәнни үзәк директоры Азат Шәймулла улы Зыятдинов химия һәм технология буенча төрледән-төрле катлаулы сораулар яудырып кына калмый, әйләнә-тирә мохит, кызның табигатькә мөнәсәбәте, хәтта Болгар тарихы буенча чын-чынлап имтихан ала!

2005 елда Италиянең Basell фәнни-тикшеренү үзәгендә укып кайту, чит ил белгечләре тәҗрибәсен өйрәнү, яңа производствоны эшләтеп җибәрүләр... Химкомбинат эшчеләре, Гүзәлнең студентлары булып, икенче югары белем алып йөри. Кичләрен институтта ул аларга органик химиядән лекцияләр укый, көндезләрен производствода бергә эшлиләр. Күбесе әле үзеннән яшькә зуррак та. Технологик җайланмалар яныннан узганда: «Исәнмесез, Гүзәл Вануровна!» – дип сәламлиләр аны. Аппаратчылар, машинистлар, кайчак хәтта цех башлыклары арасында да үзенең студентларын күрә. Нәкъ «Весна на Заречной улице» киносындагыча!

...Гүзәл елмаеп куйды. Бәхетле ул! Яраткан эше, шәһәре, гаиләсе бар! Спортка, җырга, театрга гашыйк Гүзәлнең Равиле дә үзе кебек: спортчы да, биюче дә. Ул Түбән Кама «Шин» заводында эшли. Балалар бакчасына йөрүче кызлары Айгөл дә инде «Айгөл» хореография мәктәбендә бии, I, II дәрәҗәдәге лауреат исеме бар. Рәсемнәр ясый, әнисе белән икәүләп Тильда курчаклары тегәләр. Кызы белән бергә Гүзәл дә курчаклы уйный! Әлбәттә инде, үзләре теккән курчаклар белән!

...Яратып, илһамланып кайттык Түбән Камадан. Ак шәһәрдә ак, пакь күңелле кызлар, ханымнар яши! Яшьлек каласының рухына тәңгәл яшьлек, романтика, матур эшләр белән бизи алар тормышны!

«АК ХИСЛӘР»

Оренбург өлкәсе, Әсәкәй авылы. Менә унөченче мәртәбә инде анда «Ак хисләр» фестивале уза. Быел исә фестиваль үзенең форматын үзгәртте: матурлык һәм талант бәйгесе дәрәҗәсенә үк күтәрелде. Чыгыш ясаган кызлар «Татар кызы-2017» республика конкурсының сайлап алу этабына узды.

Конкурсның оештырылу дәрәҗәсе, концепциясе бу чараны башка бәйгеләрдән аерып тора иде. Бәйге программасы өч номинациягә корылган булып чыкты. Монысы да бер яңалык иде. 55 яшьлекләр һәм аннан өлкәнрәкләр – «Аксакал» һәм «Хуҗабикә», 35 тән 54 яшькәчә катнашучылар – «Зирәк ир» һәм «Киленбикә», ә 15 тән 34 яшькәчә булганнар «Татар егете» һәм «Татар кызы» номинацияләрендә үзләрен сынады.

Татар хатын-кызын матурлыгы, зирәк акылы, белеме ягыннан гына бәяләп калмаганнар, милләтнең рухын саклаучы итеп тә караганнар. Урта һәм өлкән яшьтәгеләр категориясендә чыгыш ясаучы ир-атлар һәркемне сокландырды. Гадәттә, без аларны аз сүзле, бераз төксе, күп вакыт оялчан итеп күрергә күнеккән. Алар исә шундый итеп чыгыш ясады: талантларын зал аягүрә алкышлады.

«Хуҗабикә» номинациясендә Наҗия Әhлиуллина (I урын), Рәсимә Саниева (II урын), Орскидан Флюра Әбүбәкерова (III урын) җиңүчеләр дип табылды. Яңа Колшәрип авылыннан Мөхәммәт Саниев (I урын), Иске Солтанголдан Рафаэль Вәгыйзов (II урын), Фәнил Заһидуллин һәм Зөфәр Мәхмүтҗанов (III урын) «Аксакал»лар дип игълан ителде.

«Киленбикә» номинациясендә Динә Хәйруллина белән Гүзәл Фәттахова – I урынны, Алсу Кыямова белән Равия Садыйкова II урынны бүлеште, Резеда Бадаева III урынга лаек булды. «Зирәк ир» номинациясендә Илдус Абдрахманов һәм Фәрит Мифтахов I урынга чыктылар, Халит Ганиев – II, Илшат Мөхәммәтҗанов III урынны яулады.

«Татар кызы» дигән исемгә лаек булучылар бишәү: Эльвира Яруллина (I урын), Эльвина Касыймова белән Эвелина Мөхәммәтҗанова (II урын), Руфия Сәлахова белән Алсинә Әбүзәрова (III урын). «Татар егете» дигән исемне дә биш егет йөртә: Илдар Яруллин, Ришат Мөхәммәтҗанов (I урын), Артур Сөләйманов (II урын), Илнур Йосыпов һәм Ленар Мөхетдинов (III урын).

Татар халкының үзенчәлекле яшәү рәвеше кайчан да заманча, кызыклы, актуаль икән – фестиваль шуны ачып бирде. Әлеге матур традицияне киләчәктә дә дәвам итүләрен теләп, «Сөембикә» журналының баш мөхәррир урынбасары Рәмзия Кашапова районның мәдәният идарәсе башлыгы Элеонора Дәүләтовага калфак бүләк итеп кидерде.





ҖӘМГЫЯТЬ



■ Казанга Париж шәһәре мэры Анн Идальго килеп китте. Ул шәһәребездәге күп кенә спорт корылмаларында булып, Kazan Arena, Су спортлары төрләре сараен, Универсиада авылын карап чыкты. Кунак ханымны Казанның халыкара зур спорт чараларын уздыру өчен барган көрәштә җиңү тәҗрибәсе кызыксындыра, 2024 елда Җәйге олимпия уеннарын Париж үзендә кабул итәргә ниятли.

■ Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Кытай Халык Республикасына эш сәфәре кысаларында Чанша шәһәрендә булып, «Татарстан–Хунань» эшлекле форумында катнашты. Рөстәм Миңнеханов Чанша шәһәрендә төзелеш техникасы җитештерүче Sany Group халыкара компаниясе мәйданчыгына да визит ясап, бу компания җитәкчелеген Татарстан Республикасына чакырды һәм төзелеш техникасын «КАМАЗ» шассие нигезендә бергә җитештерү мөмкинлеген тәкъдим итте.

■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Ватанны саклаучылар көне уңаеннан, Казан Кремлендә ветераннарны һәм хәрбиләрне кабул итеп, аларга Россиянең һәм Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды.

■ Казанда Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаиләләренә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнү таныклыклары тапшырылды. Бу бүләк фронтовикларга 1941–1945 елларда бирелеп тә, исем-фамилияләрендәге төгәлсезлекләр аркасында бу көнгә кадәр ияләренә барып ирешмәгән булган.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ Pause халыкара архитектура конкурсында Казан архитектура һәм төзелеш университеты студенты Алсу Садриеваның проекты җиңеп чыкты. Анда 20 илдән вәкилләр катнашты. Конкурсантларга шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып ял итү өчен павильон эскизын ясау бурычы куелган иде. Алсу тәкъдим иткән «Левиафан» павильоны Ванкуверда (Канада) төзеләчәк.



МӘГАРИФ

■ Түбән Камада һөнәри белем бирү оешмалары студентларының «Ел казанышы-2016» I Республика конкурсы җиңүчеләрен котладылар. Мондый конкурс әлегә беренче мәртәбә уздырыла.

■ Казанның 113 нче мәктәбе Марат Әхмәтшин исемен йөртә башлады. Капитан Марат Радик улы Әхмәтшин 2016 елның июнендә Сүрия Гарәп Республикасында барган сугышларда хәрби антына тугры калып, иптәшләрен ИГИЛ хәрбиләреннән саклаганда һәлак була. РФ Президенты Указы белән аңа үзе үлгәннән соң, Россия Герое исеме бирелә.

МӘДӘНИЯТ

■ Казан мәдәният институтында «Әлмәндәр варислары» дигән II Халыкара театр иҗаты фестивале үтте. Театрның легендар артисты Шәүкәт Биктимеров истәлегенә багышланган бу проект Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фонды, Татарстанның Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм башка мәдәни оешмалар ярдәме белән гамәлгә ашырыла.


■ 2017 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен дәгъвалаучыларның исемлеге билгеле булды. Быел бу премиягә 19 кеше тәкъдим ителгән. Елдагыча, Тукай бүләге лауреатлары 26 апрельдә билгеле булачак. 2014 елдан бирле премиянең күләме 500 мең сумны тәшкил итә.



■ Казанда «Мирас» татар музыкасы фестивале булды. Фестиваль Россиянең халык артисты Татарстанның дәүләт симфоник оркестры җитәкчесе Александр Сладковский җитәкчелегендә узды. Өч концерттан гыйбарәт фестиваль программасында төрле елларда иҗат ителгән әсәрләр яңгырады. Традиция буенча, беренче концерт Нәҗип Җиһанов иҗатына багышланган иде.

СПОРТ

■ Казанның Теннис академиясендә яшүсмерләр арасында «Ельцин кубогы 2017» Халыкара теннис турниры узды. Чарада Россиянең беренче Президенты хатыны Наина Ельцина һәм кызы Татьяна Юмашевалар да катнашты.



PRESSA.RU



РЕКЛАМА

ТАҢГА – ЧУЛПАН, ЭФИРГА – ЗӨҺРӘ!

16+

«ТАТАРСТАН-24» ТӘҮЛЕК БУЕ ЭШЛИ ТОРГАН МӘГЪЛҮМАТИ КАНАЛ. УЛ КӨН САЕН РЕСПУБЛИКА ЯҢАЛЫКЛАРЫ ХАКЫНДА СӨЙЛӘП ТОРА.

Һәр ике сәгать саен – 10, 12, 14, 16, 18 сәгатьләрдә яңалыклар чыгарылышы туры эфирга чыга. Анда Татарстан тормышы турында иң мөһим мәгълүмат биреп барыла. Әлбәттә, көн дәвамында ихтимал булачак яңалыкларның беркадәре алдан ук фаразлана, материаллары әзерләп куела. Шулай да көтелмәгән хәлләргә дә әзер булырга кирәк.



■ Ил-көндә барган вакыйгалар кайвакытта бик тиз алышына. Алар турында хәбәр минутысәгате белән туры эфирга килергә дә мөмкин. Андый чакта хәбәрчеләр вакыйга барган урыннан туры элемтәгә чыгалар.



Татарстан-24» телеканалының яңалыклар хезмәте Республиканың көнен бербөтен манзара итеп чагылдырырга сәләтле. Телеканал журналистлары объективлык, профессиональлек белән аерылып тора. Алар эфир материалын дөрес һәм истә калырлык итеп күрсәтә белергә тиешләр. Тележурналистлар һәм редакторлар яңалыклар турында хәбәр итеп кенә калмыйлар, бәлки вакыйгалар агышын да күз угында тоталар. Алай гына да түгел. Алар үз тыңлаучыларын да алдагы көн барышына әзерләп куялар. Әйтик, иртәнге 6 белән 10 арасындагы яңалыклар чыгарылышларында кеше эшкә җыенганда ук электр яки суның кайда булмавын белеп, ишетеп китә.

Канал тапшыруларын республиканың 1,6 миллионлап кешесе карый. Ул быел район телеканаллары өчен эфир челтәрендә партнер булыр дип уйланыла. Беренче иҗади хезмәттәшлек килешүе «Яшел Үзән» телеканалы белән төзелде. Аларның яңалыклары иртәнге һәм кичке прайм-таймда чыга. Шул ук вакытта җирле телеканаллар үзләренә хас үзенчәлекләрен дә, татар телендә чыгучы тапшыруларын да саклап калачак. «Татарстан-24» тапшырулары социаль челтәрләр аша да республика халкы белән элемтәдә тора.

Канал тормышка битараф булмаган тамашачыларга адресланган. Телеканалның яңалыклар сәхифәсе сәламәт яшәү рәвешенә, ял итү формаларына кагылышлы мәгълүмати-аналитик манзаралар белән чиратлашып бара. «Актуаль әңгәмә», «Көн кадагына», «Сәламәт булыйк» дигән тапшырулар, Татарстанның икътисадый тормышына караган программалар җитдилеге белән аерылып торалар. Шулай да бу телеканалның иң зур үзенчәлеге – ул оператив һәм һәрвакыт элемтәдә!

Димәк, яңалыклар сәхифәсе аларны халыкка җиткезүчедән дә беренче чиратта җитезлек, өлгерлек, аек фикерләү сәләте таләп итә. Әлбәттә инде, тапшыруны алып баручының үзенең дә күркәле булуы шарт. Телевизор караучыларга бездән бүләк булсын әле, дип, аларның берсеннән – Зөһрә Уразбахтинадан интервью алырга булдык.

Зөһрә, син кайсы яктан, нинди сулар эчеп үстең? «Кем бәхетенә үстең?» дигәнен әлегә сорамый торабыз.

Яңа каналның экран йолдызы Зөһрәдә акыл да, күркәмлек тә бар...

– Мин Мари Иле Республикасының Бәрәңге бистәсендә туганмын. Шулай дип әйтүгә миннән: «Бәрәңге ашап та шулай зифа булып буламыни», – дип көләргә яраталар. Ә кайсы татар бәрәңге яратмый! Ә Бәрәңге районында, нигездә, татарлар яши. Шуңа күрә рус, мари телләрен генә түгел, мәктәптә татар телен дә өйрәнәләр. Ул телләрне дә беләм. Гаиләдә дә татарча гына сөйләштек үзе. Мин Тукай, Җәлил шигырьләрен ятлап үстем. Милли бәйрәмнәрне барлык туганнар җыелышып, бергәләп бәйрәм итәбез, татар ашларын пешерәбез... Әтием республикада танылган нейрохирург. Әби белән әни тәрбиясендә – тәртип кысаларында үстем мин. Кичке уннан да соңга калмыйча кайтып ятарга тиеш идек. Казан федераль университетын тәмамлауга ук Дәүләт Думасы депутатының ярдәмчесе булып эшли башладым. Тик бу минем юлым, минем эшем түгеллеген бик тиз төшендем...

Шуңа күрә телевидениегә китәргә уйладыңмы?

– *(Елмая.)* Икенче сыйныфта укыганда ук мин үземнең көндәлегемә телевизор экраныннан карап тора торган бөдрә чәчле кыз рәсемен ясап куйган идем. Ул кыз, әлбәттә, мин булырга тиеш идем. Хәтта рәсем астына: «Телевидение дикторы буласым килә», дип язып та куйганмын. Тик мин коры хыяллар белән генә мавыгып утырмадым, үзем дә бик нык тырыштым!

PRESSA.RU





Шактый көч куярга, үз өстемдә нык кына эшләргә туры килде миңа. Актерлык осталыгы курсларына да йөрдем. Педагогым Вероника Валерьевна Чепегинадан сөйләм дәресләре дә алдым - акцентым көчле иде. Әле хәзер дә аның янына барып, осталыгымны чарлап торам. Хәтта спортның су төрләре чемпионаты алдыннан махсус роликларда төшеп, үземне экраннарда «балкытып» алдым. Ә аңынчы... Артык килограммнарымны «яндырдым!» Утызны!

Чынлап теләгән теләк тормышка аша икән.

«Татарстан-24»кә мондый әзерлекле кызны бишкуллап алганнардыр инде.

– Бик ашыкмадылар шул... 31 мәртәбә (!) әңгәмә генә үттем. Һәм һәр юлы үземнең шәхес икәнлегемә ышандыра алмадым – мине «блондинка» итеп кенә күрәләр иде. Нык кайгыра идем моңа, әмма юкка борчылганмын – вакыты җиткәч, морадыма ирештем. Үз-үзеңә ышану һәм тәвәккәллек барыбер юл яра ул! Телеэкранга эләгү өчен бөтен танышларыма, кастингка эләгергә ярдәм итегез, дип шалтыратып чыктым. Ә миннән көлделәр генә. Имеш, таныш-белешең булмаган килеш телевидениегә эләгеп буламыни? Хәзер аларның белеп сөйләмәгәннәрен аңладым инде. Кыюлык белән үҗәтлек кенә кирәк. Узган елның 1 мартында тәки кастингка килдем бит! Каушадым, әлбәттә. Чөнки бу урынга дәгъва кылучылар йөздән артык булып чыкты. Күбесенең инде телевидениедә эшләү тәҗрибәсе дә бар. Ә жюри мине сайлады! Бәхетем бу минем!

Ә нигә соң нәкъ менә «Татарстан-24»?

– Татарстанда берничә телекомпания бар. Һәркайсының үз юлы, үз аудиториясе. «Татарстан-24» яшьлеге, зур максатлар куюы белән аерылып тора. Телеканал бөтен республика тормышы турында сөйли. Хәбәрләр Татарстанның иң ерак төбәкләреннән дә алына. Ялсызнисез тәүлек әйләнә эшләп торуның җаваплылыгы зур аның. Ләкин кулыңның «тормыш пультында» икәнен тоеп эшләү кызык та бит ул! Яңалыкларны бөтен кешедән алда белеп торасың... Эфир барышында шулкадәр адреналин алам мин! Тамашачының мәхәббәтен тою да миңа энергия өсти, яшәү дәрте бирә!

Күп нәрсәгә өйрәнгәнсеңдер үзең дә?

– Әлбәттә, өйрәндем! Телевидение җитәкчеләренә мине, мөмкинлекләремне күреп алганнары өчен бик рәхмәтлемен. Бу гаҗәеп һөнәр серләренә өйрәткән остазларыма, мөхәррирләргә, бүтән алып баручыларга – бүген минем дусларыма әверелгән хезмәттәшләремә рәхмәтемнең иң зурысы. Алар мине шундый кызыклы дөньяга алып керделәр! Иң зирәк остаз – ясалган хаталар дигән нәрсә дә бар бит әле. Иң мөһиме: ялгышлардан куркып калмаска, белмәгәнне сорарга оялмаска кирәк. Мин һәрвакыт эшемә бәя бирүне сорыйм. Тәнкыйтьтән курыкмыйм. Казанда гына түгел, республикадан читтә дә танылган профессионаллар белән янәшә эшләргә туры килә бит миңа. Бердәм команда булып эшләү кыенлыкларны ерып чыгарга ярдәм итә.

Димәк ки, син эшеңнән канәгать? Ә якыннарың эшең турында нинди фикердә?

– Туганнарым, гаиләм Зөһрәләре белән бик тә горурланалар. Тапшыруларны карап баралар, мактыйлар да, җитешмәгән якларны да күрсәтәләр. Бигрәк тә әниемә рәхмәтлемен. Таянычым, барлык уңышларыма сөенүче, рухландыручы, өметләремә канат куючы кешем ул!

Зөһрә, күзәтеп барам: син бит әле бик актив рәвештә интернет-тормыш белән дә яшисең...

– Хәзер бу нәрсәгә бүтәнчәрәк карыйм. Социаль челтәрләр минем өчен телеканалны популяр итүнең бер мөмкинлеге ул. Минем тырышлыгым белән дә безнең аудиториянең киңәя баруын белү миңа горурлык хисе бирә. Россиядәге һәм чит илләрдәге абунәчеләрем безнең яңалыкларны сайттан укый.

Социаль челтәрләрдә утырудан башка да кызыклы шөгыльләрең бармы?

– Музыка мәктәбен «бишле»гә тәмамлаган идем. Хәзер дә әле, арып эштән кайткач, пианино янына утырып уйнап алам. Шуннан хәл кереп китә. Классик әсәрләр уйныйм күбрәк. Бетховенның «Айлы соната»сын бигрәк тә яратам. Рус классикларын йотлыгып укыйм. Достоевскийның «Преступление и наказание», Булгаковның «Мастер и Маргарита», Тургеневның «Отцы и дети» әсәрләре һичкайчан да туйдырмый. Соңгы вакытта психология белән мавыга башладым.

Зөһрә, Татарстан йөзе булган кыз экранда күренгән саен: «Безнең кызлар чибәр шул ул!» – дип горурланып куябыз. Ул матурлыкны кайгыртып, саклап торасы да бар бит әле.

– Телевизор караучыларның әнә шундый җылы мөнәсәбәте матур итеп күрсәтә торгандыр мине. Туры эфир бик күп адреналин бирә ул. Шул адреналиннан йоклый алмый яткан чакларым да була... Эфирга чыгу миңа эш кенә түгел, хобби сыман шөгыль инде ул! Спорт белән мавыгам. Безнең эштә үзеңне формада тоту бик мөһим нәрсә. Баштагы авырлыгымны киметкәнемне әйткән идем инде - хәзер шул күрсәткеч үзгәрмәсен өчен тырышам. Йөгерү, йога, пилатес, кроссфит, хәтта бокс та... Мин әле «Ак барс»ның фанаты да. Хоккейны бала вакыттан ук яратып карый идем. Быел хоккей буенча Дөнья чемпионатына бару бәхетенә ирештем. Хоккей матчын стадионда карауның үз ләззәте бар икән аның. Сәяхәт итәргә, бүтән мәдәният вәкилләре белән танышырга, аралашырга, дөньяга бүтән күзлектән карауларның фикерен белергә яратам. Әнә шул рәвешле телеканалыбыз белән бергә үзем дә үсәм. Дөньяның 22 дәүләтендә булырга өлгердем инде. Ә күрмәгән илләр күбрәк!

Бу әңгәмә 8 Март алдыннан булды. Бу бәйрәмдә без бүләкләр алырга гына түгел, бер-беребезгә матур теләкләр теләшергә дә яратабыз. Хыялына ирешкән, ил күгендә йолдыз булып балкырга өлгергән кызга иҗади бәхет, иминлек нигезе булган ныклы сәламәтлек телибез.

– Мин дә, үз нәүбәтемдә, үземнең генә түгел, бөтен гаиләбезнең яраткан журналы булган «Сөембикә» аша аның меңләгән укучыларына зур максатлар куюдан курыкмауларын, язмышның кешегә һәрвакыт бәхетле булу өчен шанс бирәчәгенә, ягъни күк капусы ачылып китәренә ышанып яшәүләрен телим. Аннары тагын әйтәсе килгән бер сүзем бар: иң бәхетле чакларында да алар якын кешеләрен, остазларын онытмасыннар иде.



PRESSA.RU























АЛАР НИНДИ ЙОЛДЫЗЛАР?

БИЕКТАУГА УЛ КӨННЕ БАРЧА КАЗАН АРТЫ РАЙОННАРЫ ҖЫЕЛДЫ!

Буран дими, кар дими (ә табигать, гадәттәгечә, хатын-кызларыбызны тагын бер кат сынады!), иртүк килеп җитте кызлар. Арча, Әтнә, Теләче, Саба, Биектау, Балтач, Кукмара, Балык Бистәсе, Питрәч, Лаештан...

Елның иң булган, иң булдыклы, иң үрнәк хатын-кызларын сайлыйбыз. Юк, алар барысы да – йолдыз, барысы да – җиңүче! Араларында укытучылар, тәрбиячеләр, мәдәният йорты мөдирләре бик күп. Сыер савучы, медик, журналист та бар...

Күңелдә гел бер җыр яңгырый:
Нурлар сибеп, балкып яна –
Алар нинди йолдызлар?

Һәр чыгыш артында соклангыч та, гыйбрәтле дә гаҗәеп язмышлар!.. Әйтерсең, алар турында кино карыйбыз. Менә Саба районы Югары Симет авылыннан Рушания Шамилова. Җиде баланы тәрбияләп үстергән ул! Балаларның бишесе – әнисез калган ятимнәр! Кечкенә генә күренештән дә йөрәк сулкылдап кала, күз яшьләнә... Гомере буе сыер савучы булып эшләгән Мәрьям Вафинаны Балтачта белмәгән кеше юктыр! Ире Борис белән алар «Үрнәк гаилә» исемен йөртә! Әйтүе үк күңелле: 6 бала, 15 онык, 6 турун! Балык Бистәсеннән Фәридә Шәриповага ничек сокланмыйсың тагын: тәрбиягә алып, ире белән ике шәп егет үстереп яталар! Биектаудан Елена Агеева гаиләсе (ире, 5 баласы!) чып-чын концерт күрсәтте!

Без караган киноның «Мәдәният һәм рухият» сериясендә Саба районы Шәмәрдән мәдәният йорты директоры Рушания Хаҗиеваның үзен актриса дип кабул итәрлек. Биектаудан өстәмә белем бирү педагогы Екатерина Холинаның мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүче «Балкыш» үзәге дә чын мәгънәсендә талантлар мәктәбе! Гөлсинә Зәкиеваны Арчада талантлы журналист буларак беләләр, әлбәттә. «Арча хәбәрләре» газетасындагы язмалары белән ул һәр авылга, һәр өйгә барып җитә. Ә менә Гөлсинәнең «Җидегән чишмә» халык театрында да уйнавы, Бөтенроссия, төбәкара, республика конкурслары лауреаты булуы, үзе дә пьесалар язуы, аның «Елый икән, елый ирләр дә» спектаклен тамашачы яратып каравы безнең өчен сюрприз булды!

«Ай, кызлар, йолдызлар!» – дип сокланып, без алкышларга күмгән ханымнар һәркайсы үзенчә матур, үзенчә кабатланмас! Сабадагы талантлы балалар интернат-мәктәбе директоры Ләйсән Билалова, шул ук районның «Туган як» ҖЧҖ сыер савучысы, хезмәте республика орден-медальләре белән бәяләнгән Кадрия Ибраһимовалар... Лаеш районындагы Нармонка авылы «Кояшкай» балалар бакчасында эшләүче Миләүшә Абдуллина исә ике ел рәттән «Ел тәрбиячесе» булган; халыкара дистанцион конкурслар лауреаты да ул. «Балаларны татар теленә өйрәтүче иң яхшы тәрбияче» дигән исеме дә бар, җитмәсә! Балык Бистәсендәге Яңа Арышның Мәдинәсе менә дигән «Бизнес-леди», ичмаса! Әйе-әйе, ай саен 700 килограмм ит җитештерүче, авыл халкыннан сөт җыеп тапшыручы Мәдинә Гыйлемханова ул!

Россия Федерациясе Яшьләр сәясәте сферасының почетлы хезмәткәре, Питрәчтәге Аграр яшьләр берләшмәсе рәисе Наилә Таҗиева сәхнәгә чыгуга, аңардагы шәп энергетика, яшьлек, күтәренке кәеф бөтен залга күчте! Менә нинди кызлар килгән бит!

Балтач районы Карадуган авылында «Ак каен» балалар бакчасы мөдире булып эшләүче фән кандидаты Зөлфирә Камалова – үзе бер шәхес! РСФСР халык мәгарифе отличнигы, Каюм Насыйри премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган укытучысы, 31 китап, кулланмалар авторы, районның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе... Валентина Васильевна Борисова исә Кукмараның спорт йолдызы!

Егетләрсез бәйрәм – бәйрәммени?! Апастан, Балык Бистәсеннән, Питрәчтән, Сабадан килгән асыл ир-егетләр чыгышы да күңелләргә уелып калды. Хатын-кызлар карашы буенча Сабадагы «Олимп» балалар-үсмерләр спорт мәктәбе директоры Рифат Хисамов – «лидер ир-ат», ә Апас аграр колледжы укытучысы Рөстәм Мингазиев «олы йөрәкле ир-ат» дип табылды.

...Менә шундый йолдызлар яши Казан артында. Эшләре дә, тормышлары да, үзләре дә матур!

PRESSA.RU

ЯХШЫ КЕШЕ БУЛУ КЫЕН ТҮГЕЛ ДӘ УЛ, МЕНӘ БАЛАҢА ҺӘРВАКЫТТА ДА ЯХШЫ ӘНИ БУЛУ КЫЕН.

Бигрәк тә яхшылыкка бала туган көннән алып адым саен сыналып торганда. Алар күңел түрендәге аерым бер киштәгә туплана бара, туплана бара... Әни кешенең өф-өф итеп кенә саклаган гөлбакчасына беренче таш кайчан төшә соң? Мөгаен, бала тудыру йортында уктыр.



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

ЯХШЫ ӘНИ. НАЧАР ӘНИ...

– Синекен дә ярып алдылармыни? Андый балаларның чирләргә каршы торучанлыгы начар була, диләр. Алар өчен шок була икән ул, – ди күрше койкадагы яшь хатын планшетыннан аерылмыйча гына.

Ул үзе тапкан! Әни булу бәхетендә коенып, тәхеттә утырган күңел беренче тапкыр шунда шәлперәеп төшә: кешечә итеп таба да алмаганны, ничек багарсың...

Аннан соң акушер апа: «Имәргә тизрәк өйрәнсен өчен менә болай тоталар баланы. Аның өчен институт бетерергә кирәкми», – дип, каты гына әйтеп чыгып китә. Шундук күзләргә мөлдерәп яшь тула: «Апа җаным, мин, гомумән, аны тотарга куркам, берәр җирен авырттырсам». Менә икенче таш: тота да белмим...

Яхшы әниләрнең эшләре хутта: аларның балалары еламый, эчләре авыртмый, аслары юешләнсә, әниләре тизрәк алыштырып куя, алар урамга да көн саен бер үк вакытта чыгып, бер үк вакытта керәләр. Прививкалары вакытында ясалган һәм, гомумән, алар беркайчан да чирләми. Хәтта тешләре чыкканда да температуралары күтәрелми. Яхшы әниләр бала чүпрәкләрен ике яклап үтүкли, бала уенчыкларын атна саен хлорлап юа. Алар балаларына кибеттән пюре алмый, ә базардан сайлап кына алган брокколи белән кишерне майсыз-тозсыз итеп парда пешереп, төеп ашата. Яхшы әниләрнең балалары шуны тагын сорап ашый. Яхшы әниләрнең өендә бер тузан бөртеген тапмассың, ризык вакытында пешкән була. Аларның балалары яшь ярымда хәреф таный, ике яшьтә «Әлифба» укый. Балалар бакчасына теләп йөри, түгәрәкләрнең берсен дә калдырмый. Мәктәптә – беренче!

Бала тудыру йортыннан ук шушы тере төргәкне күкрәгеңә кысып: «Нинди әни инде мин?» – дип, үз-үзеңне гаепли-гаепли чыкканда, «моннан соң әйбәт булырмын», дигән оптимистик рух көч бирә әле. Ләкин кайткан көннән башлап акыл өйрәтүчеләр тагын да күбәя: берәүләр баланы үз яныңда йоклатмаска, икенчесе үзен генә калдырмаска куша; берәүләр артык

төрәсең ди, икенчеләр салкын тидерәсең, дип куркыта. «Урамда озак йөрисең», дигәненә, «таш яуса да, чыгарга кирәк», дип, каршы төшүчесе табыла... Әлбәттә, яхшы әни буласың килсә, барысын да дәшми генә тыңлыйсың. Һәм үзеңне туктаусыз гаепле итеп сизәсең.

Йә кемнең инде тәмле йокыга талуга, сикереп торып бишек тирбәтәсе килсен? Дөрес, яхшы әнинең. «Их, нигә шулай тиз уянды инде, керфек кагарга да өлгермәдем бит», – дигән уй яхшы әнинең инде башына да кереп карамый. Үзегезне «бала белән уйнап утырасым килми», дигән уйда тотканыгыз бармы? Тавыш күтәргәнегез яки йомшак урынга эләктереп алганыгыз? Ә яхшы әниләр алай итми!

Безнең буынның үз әниләре бу хиснең көчәюенә «өлеш» кертми калмый. Уйлап карасаң, аларга чыннан да һәйкәл куярлык: безне автомат кер юу машинасыз, памперссыз, кайнар сусыз һәм кибет киштәләре такыр заманда үстергәннәр бит әле. Ул вакытларны искә төшерә башласалар, аларны туктатып булмый: яхшы әни генә түгел, алар яхшы хатын да, яхшы килен дә була алган. Бала чүпрәкләребезне кайнатып юа-юа, шулай ук ике яклап үтүкләгәннәр. Бала идәндә мүкәләп йөри башлагач, өшемәсен дип, дүрт кат ыштан кидерткәннәр – асты юешләнгәндә барысын да алыштырырга туры килгән. Әле кибеттә өчәр сәгать чиратта торып, кирәк-ярак юнәткәннәр. Ипине үзләре пешергән, шул арада сыер да савып кергәннәр. Ничек өлгергәннәр? «Өлгергәнбез инде», – ди алар горурланып.

Ә бу вакытта мин нишләгәнмен? Әлбәттә, ялгызым сабыр гына көтеп утырганмын. Һәм елак булмаганмын. (Яхшы әнинең баласы да тыныч була!) Моның бүгенге бәясе – күңел түренә яшерелгән ялгызлык хисе, әнине югалтудан курку һәм башка психологик киртәләр. Әни, тавышындагы горурлыгын киметмичә, дәвам итә: «Сиңа 9 ай тулуга эшкә чыктым». Ә мин кем белән калганмын? Әлбәттә, дәү әни белән ерак әби тәрбиясендә.

Юк, мин үзебезнең әти-әниләр буынын тәнкыйтьләү ягында түгел. Ул вакыттагы яхшы әни булуның нормасы шундый. Алар үзләре ничек дөрес дип тапкан, шулай тәрбияләгән. Һәм әти-әниләребезнең безнең буынның бала тәрбияләүдәге ысулларын аңламауларын да аңлап була. Читтән караганда, чыннан да шаккатарлык: безнең буын балаларына артык яхшы ата-ана булам диеп саташа, шаша хәтта ки. Гаилә башлыгы хәзер әти дә, әни дә түгел – бала. Без балаларыбызның теләкләрен алдан күрәбез һәм шунда ук үтибез, аларны бишектән үк диярлек ниндидер мәктәпләргә йөртәбез, уенчыкларның ниндие сатыла – барысын да алып бирергә тырышабыз, хәтта ки подгузникларның да иң кыйммәтлесен сайлыйбыз.

Балалар бакчасындагы Яңа ел бәйрәмендә шуңа игътибар иттем: барлык әниләр дә шулай кылана икән. Бәйрәмгә бер ай әзерләндек, күлмәк сайлау үзе бер вакыйгага әйләнде. Ватсаптагы чатта әниләр:

– Видеога төшерәбезме? Бала гомерендә бер генә була торган вакыйга, истәлеккә кирәк, – дия башлады.

– Кыйммәт бит, – дип каршы төшә берсе.

– 300 суммы? Вак-төяккә җәлләмибез әле. Ә бу бит балага! – дип оялта икенчесе.

Болай ук оялткач, начар әти-әни булып каласы килми – ризалаштык. Югыйсә бала гомерендәге өченче бәйрәм – өченче видеодиск бу һәм моңа кадәрге икесе дә кабат каралмаган килеш ята инде.

Баланың һәр уңышы «яхшы әни» дигән якка, егылгандагы һәрбер сыдырылган урыны «начар әни» дигәненә салынып барып, инде бизмән ниндидер бер тигезлек тирәсендә тирбәлә башлаганда, котылгысыз рәвештә иң катлаулы дилеммага килеп төртеләсең икән әле.

Әни кешенең декрет ялыннан соң яки аңа кадәр үк эшкә чыгуы гаиләдәге соңгы вакыт салынган тәртипнең астын-өскә китереп ташлый. Без яши торган җәмгыять хатын-кызның да акча эшләве, ә еш кына аның керемнәренең күбрәк тә булу ихтималына юл куя. Шуңа күрә дә күпләр сабыйларына бала карауччы яллап, тизрәк эшкә чыга. Ә нигә чыкмаска? Баланың якты киләчәге өчен бит...

Үз-үзеңә «начар әни» дигән диагноз куйганчы, йөз кат үлчәп, бер кат кисүең яхшырак.

Хатын-кызның бала табу белән эшкә чыгарга омтылуының тарихи һәм социаль алшартлары турында озаклап сөйли башласаң, француз инкыйлабларына кадәр казынып төшәргә туры киләчәк. Клара Цеткин манифестына да кагылып тормыйм. Ни булган – шул булган. Хатын-кызларыбызның бүген ир-атлар белән хокукы шул дәрәҗәгә җитеп тигезләште ки, ул хатын-кыз икәнен әлеге дә баягы 8 Март көнне генә искә төшерә башлады кебек. Ә менә әле «социальләшергә» өлгермәгән табигать баласы – нарасыеңа contemporary women икәнеңне ничек аңлатырга?

Нәни балаларын йөрәкләреннән аерып, акча эшләүне һәм карьераны беренче урынга куйган хатын-кызларга «начар әни» дигән тамга сугарга җыенмыйм. Һич кенә дә алай дип уйламыйм. Эшкә чыга алмаганга яки баласына кирәк-ярак алырга акчасы җитмәгәнгә (чөнки әти кеше эшләгән акча ипотека түләргә һәм ашарга тотылып бара) үртәлеп, төшенкелеккә бирелеп, көндәлек мәшәкатьләр тозагында үрсәләнеп яткан әнинең янәшәдә булуы гына балага йөз процент канәгатьлек хисе бирәме икән?

Әни булу тәҗрибәсеннән чыгып шуны әйтә алам: яхшы, хәтта идеаль әниләр күп, ә менә «начар әни» – стереотип. Бер генә әни дә баласына начар булсын, дип теләми. Һәрбер әни мөстәкыйль тормышка әзер, җаваплылыкны үз өстенә ала белә, егылганда, мөмкин кадәр авырттырмаска тырыша, кирәк икән, үзе үк салам җәеп куя белә торган сәламәт шәхес тәрбияләргә омтыла. Ә хаталар?.. Ансыз кеше бармы икән? Бәлки, баланы ярату, ихлас ярату кайчан да булса балага ул хаталарны аңларга ярдәм итәр әле... Үзе әти яки әни булгач.

Фото: Ксения Богданова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

PRESSA.RU









ҖИДЕ ЯКТАН БИШ ӘНИ

ЧЕЛТЕР-ЧЕЛТЕР ТАЛИР ТӘҢКӘ ЧЫҢЫ, ГАРМУН ТАВЫШЛАРЫ, БИЮ КӨЕ, ҖЫР-МОҢ – АКСУБАЙДА БҮГЕН БӘЙРӘМ РУХЫ.

Лилия ГӘРӘЕВА

Юк, Сабантуй да, Нәүрүз дә түгел. Аларына әле иртәрәк, бүген – «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика конкурсының зона этабы. Анысы да күптән инде көтеп алынган, зурлап әзерләнгән, дулкынландырган, өметләндергән, канатлар куйган бер бәйрәмгә әверелде бит.

Аксубайга көньяк юллардан да, төньяктан да кунаклар агыла: Алексеевскийлар, Нурлатлар, Әлкиләр, Чистайлар, Яңа Чишмәләр, Спас районы – җиде район «көч сынашачак». Ана – бөек исем! Хатын-кызның иң зур хезмәте – балалар үстерү, дисәк, һичкем инкарь итмәс. Сәхнәдә – биш әни – «Хатын-кыз – ана» номинантлары. Яңа Чишмә районыннан Венера Носкова җиде балага гомер бирүче. Сәхнәгә һәркайсы ул-кызларын җитәкләп чыгып, әниләре тирәли тезелеп баскач, зал аларны алкышларга күмде. Венера ханым бәхетле ана – җиде баласының бишесе бәхетен үз авылларында тапкан, гомерләрен үз халкына хезмәт итүгә багышлаган.

Ә менә Нурлат районыннан үзенең өч баласы янына җиде ятимне сыендырган Ирина Вырмаскинаның: «Я не могу иначе, ведь где-то детство плачет», – дигән сүзләреннән соң, яшереп кенә күз яшьләрен сөртеп алучылар булды. «Мин – әни дә, табиб та, укытучы да, ашчы да, психолог та...» Әйе, әни булу – бөтенесенә җитешү, барысын аңлау, һәркайсына булышу, һәрберсен ярату...

Чистайдан Ләйсән Чернышева да күп балалы ана. Баһадирдай биш егет үстерүче бу гаилә дә үзләренең ике улы янына тагын өч ятимне сыендырган. «Ә син әнине беренче күргән көнне хәтерлисеңме?» – «Хәтерләмичә! Мин әле сөйләшә алмый идем, ул килде дә минем кулларымны үз учына алып, битенә тидерде. Мин шунда беренче тапкыр әнинең нинди җылы, нинди йомшак кеше булуын аңладым». Ана назы хәтта сөйләшә алмастай балага да тел ачкычы биргән.

Земфира Әхмәтшина (Алексеевский районы) һәм Любовь Гобәйдуллиналар да (Әлки районы) – авырлыктан курыкмыйча, итәк тутырып бала үстерүче әниләр. Алты баласына гомер биргән Любовь – арада иң яше.

«Мәдәният һәм рухият» номинациясендә катнашучы ханымнарның барысын да мин «җан табиблары» дип атар идем. Фәимә Гатина күптән инде Аксубайның үз кешесе. 1981 елдан Аксубай үзәк китапханәсендә хезмәт куючы бу ханымны яше-карты, баласы-чагасы үзенең иң якын дусты саный.

Залда агылган дәртле көйгә киң итәкләрен җилфердәтеп, чегән кызы чыга. Аксубай районы, Беловка авылы клубы җитәкчесе Тамара Андреева ул. Үзе баянда уйнап, үзе биеп һәм үзе җитәкләгән коллективлары белән чыгыш ясап, тамашачыны хәйран итте шулай.

Чистайдан Динара Злыднина оештырган «Рус җыры театры» хәтта Франциягә кадәр барып җиткән. Әлкидән Рәмзия Хөсәенова (ул да туган авылы Апакта яшәп, үз халкына хезмәт итә – авыл клубын җитәкли, өстәвенә, умартачы да икән әле), Спас районыннан Надежда Каштановалар да (кул эшләре буенча уздырылган конкурслар призеры, корама тегү остасы) үз эшләренә чын күңелдән бирелеп, халыкка рухи ләззәт бүләк итүчеләр.

Спастан Маргарита Маркова (район мәгариф бүлеге методисты) һәм бар көчен Алексеевский районының «Забота» балалар һәм яшүсмерләр приютына багышлаган Ирина Байкова, Нурлатның 3 нче урта мәктәбе директоры Мария Монахова һәм Әлкидән Рәсимә Гайфуллиналар (районның мәдәният бүлеге җитәкчесе) – «Ел хатын-кызы – лидер, җәмгать эшлеклесе» номинантлары – һәркайсы аерым ихтирамга лаек шәхесләр.

«Ел хатын-кызы – ел үрнәге» номинациясендә беренче булып сәхнәгә күтәрелгән Гөлнар Шарашева өч ел Аксубайның «Мечта» балалар приютын җитәкли. «Арада иң күп балалы әни ул», – диделәр аның турында. Ә менә Алексеевскийның балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә шәфкать туташы булып эшләүче Анна Крылова һәрвакыт сәламәтлек сагында булуын хәтта сәхнәдән дә күрсәтә алды. Чистайның 20 нче балалар бакчасы мөдире Ольга Симонова исә оешманы «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» дәрәҗәсенә күтәргән кеше. Спорт белән дуслыгы да, һәр яңалыкка ачык булуы да чыгышыннан ук аңлашылырлык булды.

«Өлкән буын» номинантлары: Фирдәүсә Вафина (Яңа Чишмә), Антонина Самсонова (Алексеевский), Раиса Надршина (Әлки), Мәдинә Кашаповаларны да (Чистай) аерым әйтеп китәр идем. Фирдәүсә апа халкыбызның борынгы җырлары, ә Мәдинә апа «Аулак өй» күренеше белән истә калыр. Гомере буе аш-су өлкәсендә эшләгән Антонина ханым, пенсиягә чыккач, хыялларына хөррият биргән. Спорт өлкәсендә дә (беренче урыннарны беркем белән дә бүлешмәс чаңгычы), мәдәният өлкәсендә дә (аңа кушылып, тамашачылар арасында да биеп китүчеләр булды) зур уңышларга ирешкән кеше ул.

Хатын-кыз өчен беренче урында гаиләсе тора, дисәк тә, гаиләсен дә эшен дә беренче урынга куеп, икесенә дә җитешкән ханымнар да бар. «Язмышым – һөнәрем» номинациясендә катнашучы Елена Баландова, Ольга Смолина, Наталья Сударкиналар – моңа дәлил. Елена Баландова Аксубайның «Аксу-Агро» җәмгыятендә 27 ел сыер савучы булып эшли. «Хайваннарны ярату, гөлләр үстерү һәм сканвордлар чишү – хоббием», – ди ул. Спас районыннан Ольга Смолкина – ашчы-кондитер. Хәер, аның һөнәрләре бу гына түгел әле, кисүче модельер да ул, технолог-эшмәкәр дә. 2010 елдан «Спас тармак технологияләре техникумы»нда укыта. Тәмле ризыклар пешерү (алар чын сәнгать әсәренә тиң) һәм улы белән икесенә матур киемнәр тегү. Яңа Чишмә районыннан Наталья Сударкина башлангыч сыйныф укытучысы. Мәктәп һәм укучыларыннан башка тормышын күз алдына да китерә алмаучы фидакарьләрнең берсе.

«Олы йөрәкле ир-ат» номинанты – 16 ел мәктәптә тарих фәнен укыткан Виктор Озеров (Алексеевский районы) инде тугыз ел хәтер сагында. «Вахта памяти» эзтабарлар отряды белән берлектә, сугыш эзләреннән барып, хәбәрсез югалганнарны табу, аларның җәсәденә соңгы хөрмәт күрсәтеп, җир куенына иңдерү белән шөгыльләнә. Мондый кеше турында олы йөрәкле дими, тагын ни дисең?

Икенче ир-егетебез – «Ир-ат – лидер» номинациясенең бердәнбер номинанты – Аксубайның Урмандәй авыл клубы җитәкчесе Эдуард Ильин сәхнәләрдә ут уйнатты. Аның җитәкчелегендәге «Урмандәй әбиләре» фольклор ансамбленең чыгышын тамашачы аягүрә алкышлады.

Фото: Людмила Жаренова

PRESSA.RU



– Абикайның алъяпкычы иде монысы... Ә монысын танныйсызмы? Әйе, чиккән сөлге башы. Абикай яшь чакта бик күп чиккән безнең. Тузган дип, сөлгеләрен ташламакчы иде инде ул. Мин үземә алдым. Без аның белән бик якын... Күрәсезме, күлмәк җиңенең бер өлешендә нинди матур бизәк булып утыра алар. Үземә бик ошый! Мин аларны үземнең коллекциямдә куллангач, абикай шундый сөенде! Миңа кирәге чыккан диптер инде. Күлмәкнең аркасындагы менә бу тукыма да аныкы... Чаршауга охшаган, дисезме? Мөгаен, шулайдыр, чаршау булгандыр, йә тәрәзә кашагасы...



Асия БАРЕЕВАны мөселман киемнәре дизайны өлкәсендә яңа исем дип атыйлар. Яңа, әмма инде шактый танылырга өлгергән исем. Һәрхәлдә, Мәскәүнең мода белән бәйле даирәләрендә ул билгеле дизайнер. Vogue, Elle, Wonderzine, Cosmopolitan, Grazia, Глазурь кебек журналлар аның белән инде шактый күләмле әңгәмәләр оештырырга өлгергән. Инде менә безнең чират... Үзәк матбугатта: «Журналистлар белән аралашырга бик

«КҮЛМӘК СИНЕ ҮЗГӘРТЕРГӘ ТИЕШ...»

яратмый», – дигән хәбәр күзгә чалынып калгач, дөресен әйтәм, аның белән элемтәгә кергәндә очрашырга ризалашыр дигән өметем алай зур түгел иде. «Килегез, көтәм», – дип җавап бирде ул. Һәм... мине өенә чакырды. «Аралашмый», дип, мәскәүләр, димәк, ялгышкан... Тәрәзәләре мәчеткә карап торган, манарадан көнгә биш тапкыр яңгыраган азан моңына күмелеп утырган фатирларына аяк басуга, барысы да ачыкланды. «Их, әни эшкә киткәнче аз гына иртәрәк килмәдегез. «Сөембикә» – аның яраткан журналы», – дип каршылады Асия. «Казан–Мәскәү» поезды башкалага җиде тулганчы ук барып төшә, кешегә бу вакытта барып керергә иртәрәк, дип, вокзалда утырып торганыма үкенеп куям...

...Түрдә – подиум, анда, әлбәттә, элгечләргә эленгән киемнәр, шунда ук «Зингер» тегү машинасы, тукымалар... Идәннән түшәмгә кадәр көзгеле борынгы кием шкафы («Антиквариат» кибетеннән эзләп таптым», – ди ул). Асия бүлмәсе бу. «Бераз гына алданрак килсәгез, монда зур өстәл торганын күрер идегез. Хәзер остаханәм бар – шунда күчердем», – ди дә, әбисеннән алып килгән ниндидер бер тукыманы кушып теккән күлмәген миңа күрсәтергә теләп, кием элгечләре астындагы капчыкларны берәм-берәм бушата башлый.

– Дубайдан күргәзмәдән кайткан килеш... Элергә өлгермәдем. Грузиянең Pia Keburte бренды белән коллабрациябезне тәкъдим иттек анда.

«Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә чакырганнар, ә Казан әле дәшми...» Юк, моны ул әйтми, эчемнән генә мин уйлап куям.

...Мәскәү кызы Асиянең балачакта бөтен җәйләре Пенза өлкәсенең Ришитен авылында үткән. (Әйе, шул, бик таныш – «аникай», «абикай» дип, Пенза мишәрләре сөйләшә!) Әтисе Әнвәр дә, әнисе Зөһрә дә бер үк авылда үскәннәр. 93 яшьлек Мөнәвәрә әбисе бүген дә шунда яшәп ята әле. Ә аның кулы кагылган төрле-төрле тукымалар (безнең татар апалары, ак яулыклы әбиләр яраткан чәчәкле ситсыларны әллә кайдан таныйсың!), оныгы иҗат иткән күлмәкләргә күчкән дә, подиумнан – подиумга, шәһәрдән – шәһәргә, илдән илгә сәяхәт итә.

– Әбием – гап-гади авыл хатыны... Балаларына кием тегәргә юклык мәҗбүр иткән аны. Үзенә кулдан теккән бер күлмәген күреп шаккаткан идем. Ничекләр пөхтә эшләгән!

Техникумда диплом эшем дә татар милли күлмәге булды. Әбинең яшел бәрхет җиләне кебек җилән дә тектем, тик минеке кызыл вельветтан иде. Абикайга бүләк иттем, хәзер дә кия әле ул аны. Тамырлар тартуыдыр бу... Илһам чыганагын үзеңнән, үз тамырларыңнан эзләү дөресрәктер. Бу очракта иҗат иткән эшләрең ихласрак килеп чыга, аңа башкалар да күбрәк игътибар итә.

«Әнигә рәхмәт, бер теләгемә дә каршы төшмәде, – ди Асия. – Олылар күзлегеннән бик үк җитди булмаган эшләр белән шөгыльләнсәм дә, тыймады. Кешедә талант бармы-юкмы икәнен башта ук аңлау авыр бит. Вакытны бушка уздыру булып чыгуы да бар иде... Ә әни миңа ышанды. Сәләтләремне үстерергә тырышты». Зөһрә ханым кызын җитәкләп башта сәнгать мәктәбенә йөртә. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, текстиль техникумын сайлавы белән дә килешә.

Югары белем алырга уйлагач, архитектура урынына кабат текстильгә туктала Асия. Ә дизайнер булып китүе... Рәсем ясарга, үз куллары белән нидер тудырырга яраткан кыз үзен беркайчан да офиста эшләячәк дип, күз алдына китерми, билгеле. Иҗатка тартылу кечкенәдән була аңарда. Барысын да дипломга әзерләгән коллекция хәл итә. Шул коллекция белән башта Асия Барееваны Санкт-Петербургта узучы Мода атналыгында – LMA Fashion Weekда, аннан «Русский силуэт» яшь дизайнерларның Халыкара бәйгесендә катнашырга чакыралар. «Ниндидер яңалык күрсәтә алам, дип, башта уйламадым да. Бик гади формалар, конструкцияләр, төсне үз тоемлавым гына иде бит бу. Ә аннан аңладым – боларның берсе дә башкаларда юк икән», – ди ул. «Русский силуэт»та Асияне трикотаж буенча атаклы дизайнер Людмила Норсоянда дәресләр алу мөмкинлеге белән бүләклиләр. Офыклар киңәя...

Бернәрсәгә дә озак вакыт сарыф итәргә яратмыйм.

Ә аннан барысы да – тормыш, иҗат, яшәү рәвеше икегә бүленә. Хәтта гардеробтагы кием-салым да. Мода өлкәсендәге белгечләр, Асияне телгә алганда, «мөселман киемнәре дизайнеры» дип атый башлыйлар. Интервьюлар биргәндә, әңгәмә шушы җиргә җиткәч: «Ә аннары мин хаҗга киттем...» – дип дәвам итә ул.

– Аллаһы Тәгаләгә мин һәрвакыт ышана, аның үземә ярдәм итүен дә тоя идем. Әмма миңа кеше кайсы дингә омтылса, шул хакыйкать булып тоелды, аны ислам белән бәйләп карамадым. Күңелемдә туган бихисап сорауларга җавапны кайдан гына эзләмәдем, тик нигәдер исламга гына мөрәҗәгать итмәдем... Ә аннан кинәт күңелемә

PRESSA.RU



хаҗ турындагы уй керде. Кешеләр нигә баралар хаҗга, нигә анда үзгәрәләр, аларга анда ни була? Беркөнне әнигә: «Минем дә хаҗга барасым килә», – дидем. Ул тагын мине аңлады, хуплады.

Моның гади генә сәяхәт булмаячагын, тормышым үзгәрәчәген барып төшүгә сиздем. Пәйгамбәребезнең аяк эзләре саклангын җир икәнен хәтта һавасыннан тоярга була анда. Без яшәгән отельнең фойесында утырганда Коръәннән бер сүрәнең тәрҗемәсе кулыма эләкте. Моңарчы Коръәнне укыганым юк иде: тетрәндем, әйтерсең, ул минем өчен язылган иде.

Әнигә сораулар яудыра башладым. Кечкенә чакта Мөнәвәрә әбием намаз укырга өйрәткән иде мине. Дини нәсел алар... Аннан ташладым. И-и, борчылды инде абикай аның өчен... Хаҗда мин кабат намазга бастым. Һәр намазым артында Ходайга ялварам: минем дә тирә-юнемдәге кешеләр тойганны тоясым килә. Күзләре юкка гына яшьле түгел бит аларның! Кошларның, хәтта агачларның Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылганына шаһит булдым – алар да Ходайга мохтаҗ. Минем дә күңелем ышана, тик йөрәгем генә дәшми, сизми...

Мәдинә шәһәрендә без урнашкан отель Пәйгамбәребез мәчете белән янәшә иде. Мин инде намазны көтеп кенә торам – үзем генә дә мәчеткә керәм. Ахшам вакыты иде. Гарәпчә берни аңламыйм, ләкин имам ниндидер бер сүзгә җиткәч, күзләремнән яшь коела башлады. Йөрәгемнең ачылганын, догаларымның кабул булганын шунда тойдым... Намаз бетте, мәчеттән чыктым. Анда күк бик матур, бигрәк тә шәфәкъ вакытында. Отельгә кайтасым килмәде – урам буйлап киттем. Бара-бара шәһәр читенә үк килеп чыкканмын. Алда – таулар, алсу төстәге күк. Ә мин ниндидер ярату нурына коенып басып торам... Урыннан кузгалсам, бу хисне башка тоймам төсле... Ул җирләрдән китәсем килмичә, очкычта да еладым да, еладым. Мәскәүгә кайткач, элеккечә яши алмаячагымны белә идем инде. 2013 елның ноябрендә, шулай итеп, минем яңа тормышым башланды...

Үзен биш вакыт намазсыз күз алдына китерә алмый инде ул хәзер. Хаҗдан кайтканнан соң, бер ел узгач, гарәп теле өйрәнергә дип, өч айга Мароккога бара ул. Беренче тапкыр уразаны шунда тота. Тәравихлар, ифтарлар... Мароккода чак бәйләгән яулыгын Асия кайткач та салмый инде.

Исламга килү аның коллекцияләрендә дә чагыла: иркенрәк фасоннар арта (хәер, сыланып торган күлмәкләр аңарда элек тә күп булмый), алар гәүдәне күбрәк каплый – дизайнерның ачык изүле, кыска җиңле коллекцияләр эшләгән чоры артта кала.

– Мине элеккечә төрле чараларга чакырып торалар, – ди Асия. – Коллекцияләремә игътибарның кимегәне юк, ул кызыксыну хәтта соңгы вакытта артты да бугай. Минем «ябык» киемнәремдә тамашачы бөтенләй башка нәрсә күрә. Лукбук вакытында модельләрнең битләрен ябуыма да исләре китми. Бу аларны куркытмый. Син үзүзеңне яхшырак, күбрәк аңлаганда, үзеңә ни кирәген тойганда, башкаларга иярмәгәндә кешеләр дә моны тоймый калмый. Иҗатыңның кыйбласы аларга никадәр чит булуга карамастан, сиңа якынаерга, нигә нәкъ менә шулай эшләгәнеңне аңларга омтылалар.

Лукбук – дизайнер иҗат иткән кием-салым һәм аксессуарлардан образ һәм стильне ничек тудырырга икәнен фотосурәтләрдә күрсәтү ул. Кайчак кием сатып алганда, аны тәгаен нәрсә белән киясебезне белмибез. Бу очракта лукбук иң яхшы ярдәмче. Дизайнер Асия Бареева лукбукларын башкаларныкы белән бутау мөмкин түгел: аныкында йөзләр капланган.

– Беренче тапкыр модельләрнең битен Bella Kareema бренды өчен әзерләнгән коллекциямне тәкъдим иткәндә яптым. Модельләр подиумга чыкканда, гадәттәгечә музыка да уйнамады, табигатьтә булган тавышлар – су челтерәве, дулкыннар кагуы, күк күкрәве, яңгыр явуы гына ишетелеп торды. Тамашачының модельнең йөзенә түгел, ә аны

тулыландырган башка нәрсәләргә игътибар итүен теләдем. Фикерләр төрле булды.

Bella Kareema бренды белән Асия Барееваның коллабрацияләре (ике брендның уртак эше шулай дип атала) инде берничә. Аның өчен яңа тәҗрибә була бу. Үзенең төп коллекциясеннән монысы, әлбәттә, аерыла. Asiya Bareeva брендына авангрaдлык хас булса, Bella Kareema өчен ул коллекцияләрне гадирәк, көн дә киярлек итеп эшләргә тырыша. «Миндәге кебек киемнәрне кияргә әзер булмаган кешеләр дә кия алсын», – ди. Болары – мөселман кызларына күбрәк туры килә. Аннан Bella Kareema кием-салымны, Асиядән аермалы буларак, берәрне генә түгел, ә күпләп җитештерә.

– Ә Asiya Bareeva брендын теләсә кем кия алмый, минем клиентларым гади генә кешеләр түгел, – ди ул. – Һәм аны мөселманнар гына да сайламый.

Әйе, шулайдыр. Беренче карашка «кыса»ларга кертелгән кебек тоелган Asiya Bareeva бренды артында ирkенлекне, көчне тою өчен башка төрле уйлау, дөньяга башкача карау кирәктер.

Асиянең иң яраткан шөгыле – барлык тукымаларын идән уртасына таратып ташлап, төсе, бизәге, фактурасы буенча бер-берсенә туры килгәннәрен, яраклашканын табып алу. «Хыялың күзаллангач, монысын эшләү бик җиңел. Мин аларны бик тиз табам», – ди ул. Бер генә тукыма кисәген дә ташламый ул – кирәге чыгуы бар. Кибет киштәсендә яткан тукымага күзе төшкәндә, гадәттә, ул инде аны киләчәктә кайда, ничек кулланачагын белә. Әмма еллар буе чират көтеп яткан тукымалар да бар икән.

Кая, нинди генә сәяхәткә барса да, тукыма җыеп кайта Асия. Сәяхәтләргә ул хәзер шуңа да күбрәк буш чемодан белән барырга тырыша. Тукыманы күбрәк Европада ала: Бельгиядән, Италиядән, Франциядән... Тукыма алырга дип, махсус чыгып китми, дисәм... Бельгия дизайнерлары елга ике тапкыр үзләренең тукымаларын ташлама белән сата икән. «Бу вакытка туры китереп барсаң, шактый сыйфатлы тукымаларны күпкә арзангарак алырга була», – ди ул.

Асиянең тукымаларга булган «мәхәббәте» берәүдән дә сер түгел: дуслары, кая барсалар да, аңа бүләккә тукыма алып кайтырга тырыша. Төрле илләрдән кайткан тукымаларны – төрле энергетиканы кушып, нидер тудырудан тәм таба ул.

– Миңа интерьер тукымалары күбрәк ошый, – ди ул. – Калын, «бүртеп» торган чәчәкле тукымалар, жаккард, челтәр дә ошый, җитенне бик яратам, мамык белән ефәкне... Кыскасы, табигый тукымаларны. Шулар белән генә эшлим дә.

Бүлмә уртасындагы борынгы шкафны ачабыз да, әңгәмәнең иң кызык өлешенә – аның гардеробына күчәбез. Үзе әйтмешли, «элеккеге, дуамал» тормышында аның гардеробы күпкә бай булган.

– Элек үзем иҗат иткән һәр кием белән аерылышу авыр иде миңа. Хәзер аларга артык бәйләнмәскә тырышам. Бу бит әйбер генә... Әмма үзем белгән, үзем аралашкан кешеләргә аларны сату күңеллерәк – теләгән вакытымда күрә алам. Саша исемле бер дус кызым, мин бу эшкә тотынуга, беренчеләрдән булып киемнәремне сатып ала башлады. Мөмкинлеге бар, ул теләсә нинди брендны сайлый ала, әмма миңа килә. Әлбәттә, күңелле хәл!

Киләчәктә гел үзем иҗат иткән киемнәрне генә кияргә җыенам: йокы күлмәгеннән алып пальтога кадәр. Коллекцияләрдән кием-салымны үземә бик сирәк калдырам. Менә бу «толстовка» узган елгы коллекциядән. Тукымасын Бельгиядән алган идем, ә кесәсендә тагын абикайдан алып килгән тукыма!


Хаҗдан кайткач, хәтта төсләрне дә ачыграк күрә башладым.

Без тагын әңгәмә башындагы сүзгә кайтып төшәбез: аны тамырлар рухландыра! Әбисенең сандыгы! Андагы төсе уңган тукымалар. Кайсы изрәп тузган булса да... Алдагы коллекциядән менә бу чалбарның тукымасы да авылда – Мөнәвәрә әбисе өендә «яшәгән». Абикае аңардан нәрсә теккән булгандыр, анысы мөһим түгел, оныгы, сул ягын әйләндергән дә (Асиягә, гомумән, күп тукымаларның эчке ягы күбрәк ошый!), аңа яңа тормыш бүләк иткән. Асия бернәрсәне дә исраф итми: күлмәгә искергән икән, аның чәчәкләрен кисеп ала да, аппликация итеп яңа күлмәгенә «күчерә». Әбисенең чиккән сөлгеләре, алъяпкычы, күлмәкләре, Асия генә күргән, тойган, ул гына яраклаштыра алган юл белән яңа күлмәкләрнең матур бер бизәгенә әйләнә. Дөресрәге, Asiya Bareeva брендының бер өлешенә!

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Асия БАРЕЕВА:

- Мин иҗат иткән киемнәрне кигән кешеләрнең тышкы кыяфәтләре генә түгел, эчке дөньялары да үзгәрүен телим.
- Начар тирәлеккә караганда, ялгызлык әйбәтрәк. Үзеңне буш кешеләр белән әйләндереп алырга ярамый.
- Иманга килү – Аллаһының зур бүләге ул, мин моңа ни өчен лаек булганмындыр, белмим. Мөселман хатын-кызлар өчен кием-салым иҗат иткәндә минимализмга омтылу кирәк.
- Дизайнер тегәргә тиеш, дип уйлап, кешеләр ялгыша. Әгәр мин боларның барысын үзем эшләп утырсам, бернигә өлгермәячәкмен.
- Күргәзмәләргә күп чакыралар. Күңелем тартканына гына барам: юл чыгу – минем үземә дә, коллекциямә дә стресс ул.
- Кием дизайны гомерлек һөнәрем, дия алмыйм. Соңгы вакыт керамика белән шөгыльләнәм. Кызыл балчык тере кебек бит ул, аннан үз кулларың белән нидер әвәләү миңа бик ошый.



Асия Бареева модельләрен сайтыбызның «Милләттәш» сәхифәсендә карый аласыз.

PRESSA.RU

НӘФИС СҮЗ ОСТАСЫ... ГАДИ ГЕНӘ СҮЗТЕЗМӘ КЕБЕК. ӘММА БУ СҮЗЛӘРГӘ КҮҢЕЛ КҮЗЕ БЕЛӘН КАРАСАҢ ЯКИ КИНӘТ КЕНӘ РОЗАЛИЯНЕҢ КҮЗ КАРАШЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШСАҢ, КҮҢЕЛ ТӨПКЕЛЕНӘ ЯШЕРЕЛГӘН БЕР ШӘҮЛӘНЕ АБАЙЛЫЙСЫҢ, РОЗАЛИЯ ЯЗМЫШЫНЫҢ ШӘҮЛӘСЕ УЛ...

РОЗАЛИЯ ЗӘКИЕВА: «МИН БӘХЕТНЕҢ НИ ИКӘНЕН БЕЛӘМ!»

Буа шәһәрендә дөньяга килгән бу кызчык. Актаныш гүзәле белән кызу канлы мишәр егетенең мәхәббәт җимеше. Совет чоры тәрбиясе алган, совет мәктәбендә укыган, аклы-каралы телевизордан совет фильмнары, мультфильмнары караган, Мәскәү, Ульяновск телестудияләренең дикторларын тыңлап хозурланган, аларга охшарга тырышкан, көзгедән һаман саен үзен диктор итеп күргән. Урамнардан узганда сокланулы карашларда коенган, җитез адымнар белән хыялы эзеннән вак-вак адымнар белән атлаган.

Алабуга мәдәни-агарту училищесына кергән ул. Әмма йөрәге аңа: бу синеке түгел, дигән. Кыз Казан тарафына юл тоткан. Хыял ишеге нәзек билле кыз бала үтәрлек итеп кенә ачылган: театр училищесы баскычларыннан ул татар эстрадасына атлаган.

– Без училищеның эстрада бүлеген тугыз кеше тәмамладык. Шулар арасыннан икебезне – Илфат Абдрахманов белән мине Татар дәүләт филармониясенә эшкә алдылар, – дип, яшьлек хатирәләренә бирелә Розалия. – Римма Ибраһимова труппасына эләктем. Римманың бик тә популяр чоры иде. Концертлар гөрләп бара, үзебез яшьләр, тормыш матур... Беренче чыгышым Казанның Офицерлар йортында булды, Саҗидә Сөләйманова шигырьләрен укыдым. Тамашачы гөрләтеп кул чапты. Сүз көчен, татар теленең тәмен, матурлыгын, мөгаен, шул кичтә тойганмындыр.

Ул көннәр инде шактый ерак калган. Татар эстрадасы чын-чынлап чәчәк аткан 80 нче елларда Розалия Зәкиева исеме зур сәхнәләрдән туктаусыз яңгырады, радио-телевидение аша еш ишетелеп, күренеп торды. Сөембикә ханбикә исемен зур сәхнәгә иң элек Розалия Зәкиева алып чыкты. Затлы киемнәрдән, чын ханбикәләрчә, горур атлап чыкты, тетрәндерерлек итеп «Сөембикә» бәетен укып, тамашачыны бер мәлгә тынсыз калдырды ул! Зал диңгез шавын хәтерләткән алкышларга күмелде.

– Мин рус мәктәбендә укып, күбрәк рус балалары белән аралашып үстем. Казанга килгәч, татарча укыган беренче китабым Әмирхан Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» иде. Хәер, мин бу әсәр белән таныш, рус телендә тәрҗемәсен укыган идем. Әмма әсәрне татар телендә уку миндә искиткеч тәэсир калдырды, татар телебезнең гаять бай, зур мөмкинлекле, матур тел икәнен аңладым. Классик әсәрләргә тартылуым шуннан башланды, – ди Розалия ханым.

Әйе, артистканың репертуар сандыгын актарып карасаң, андагы байлыкка, сүзләрдән тезелгән энҗе-мәрҗәннәргә исең китәрлек! Гаяз Исхакый, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре, Саҗидә Сөләйманова, Илдар Юзеев, Ренат Харис, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Равил Фәйзуллин, Нияз Акмал, Фаил Шәфигуллин, Мәхмүт Галәү, Дәрдмәнд, Габделҗаббар Кандалый, Фәрит Яхин, Ркаил Зәйдулла, Гамил Афзал, Фәнис Яруллин шигырьләре... Тукай шигырьләреннән тупланган «Сабыйга» дип аталган аудиодиск, йөзләгән мөнәҗәтләр, бәетләр, сатира-юмор әсәрләре... Санасаң, санап бетерерлек түгел...

Кызганыч ки, «нәфис сүз» кәлимәсе теллərдән төшеп, концерт-тамашаларны «алып баручылар», «шоуменнар» басып алган бүгенге чорда сүз кадерен аңлаучылар, һичьюгында, аңларга теләүчеләр бик аз калып бара.

Коллегалары үзара «тимер леди» дип атап йөрткән Розалия Зәкиева филармониядән гариза язып китә. Юк, эштән туеп түгел, эшләргә, иҗат итәргә ирек булмаудан туеп. Кулында сабый баласы һәм «Сөембикә» костюмы... Классик әсәрләрдән мәктәп балалары өчен махсус программа төзеп, Татарстанның бик күп районнарында, шәһәрләрдә була, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында чыгышлар ясый ул. Шул чорларны, балаларның кызыксынучан карашларын хәзер дә сагына нәфис сүз остасы.

«Башыңа төшсә, башмакчы булырсың», ди халык мәкале.

1995 нче елларда артистка туйлар алып бара башлый. «Әче, әче!» дип кычкыртып, мәҗлес алып баручылардан аермалы буларак, ул туйларны зур бер тантана, күңелләрдә озак еллар сакланырдай бәйрәм итеп әзерли.

– Инде егерме елдан артыграктыр, туйларны Нияз Акмал шигыре белән башлап җибәрәм. «...Мең мәртәбә бәхет телим сезгә, / Мәхәббәтен таба белгәннәр!» Туй йолаларына кагылышлы әдәбият туплыйм, күп укыйм. Мәҗлес барышында халкыбызның борынгы йолаларын уздырам, туй җырларын җырлатам, гаилә тормышына кагылышлы гыйбрәтле хикәятләр сөйлим, мәкальәйтемнәрне искә алам. Туйдан соң да аралар өзелми, бәби ашларына, юбилейларга чакыралар. Туйларын үзем уздырган яшьләрнең тормышларына битараф кала алмыйм, алар өчен борчылам, шатлыкларын уртаклашам, барысының да бәхетле булуын телим.

– Ә үзең?..

– Мин бәхетнең ни икәнен беләм! Ике ел бәхеттә коенып яшәдем мин! Ул елларым, бәлки, кемнеңдер гомере буе тойган бәхетенә торадыр... Мин кичергән сөюне, кемдер бер тапкыр да татымагандыр... Ходайга шөкер итеп яшим. Ышанасыңмы-юкмы, бу хисләр мине гомерем буе озата бара.

– Бүген сиңа нәрсә җитми?

– Сәхнә! Мин үземне моннан егерме ел элеккегә карый күпкә җегәрлерәк итеп тоям. Күп укыйм, күп аралашам. Репертуарымны баетам. Үзем өчен яңа бер шигъри дөнья ачтым – Бакый Урманче шигъриятен. Күптән түгел Останың музеенда чыгыш ясадым, хәзер виолончелист Лариса Маслова белән телевидение өчен тапшыру әзерлибез. Күптән түгел Г. Камал театры оркестры җитәкчесе, скрипкачы Фуат Әбүбәкеров белән Зөлфәт шигырьләрен телевидениегә яздырдык. Безнең әдәби мирасыбыз шулкадәр зур, аны халыкка җиткерү өчен эшләргә дә эшләргә әле!

– Хыялларың чынга ашсын, якынлашып килүче юбилееӊ белән сине, Розалия!

Чулпан ӘХМӘТОВА.

PRESSA.RU

Редакциябез почтасында – кочак-кочак шигырь! Урап-урап, хатлар булып та килә, сәгате-минуты белән электрон почта аша да килеп ирешә... Һәм бар дөньяны язгы кәефкә, җылы сүзгә төрә! Кызларыбыз шигырь яза. Яратуны, сагынуны, соклануны, өметләрне шигырь юлларына салалар. Балалар укытучы, төрле өлкәләрдә халыкка хезмәт күрсәтүче ханымнар әнә шулай шигырь телендә сөйләшә.

ЙӨРӘКТӘ ЯЗ ЧИГҮ ЧИККӘНДӘ...

Рушания ГЫЙЛАҖЕВА

Ел фасыллары

Кышларны эретәм...
Кыш озын... Салкыны талдырды.
Кайда яз, яшенле яңгырың?
Кушыйм да күңелем җылысын,
Күз кыскан кояшның сарысын,
Күк төсен – ап-ачык зәңгәрен,
Гөлләрнең күбәләк күзләрен...
Рәссамдай төшерим тәрәзгә.
Иртәләр алланып килгәндә,
Саф чыкка чыланган үләнгә
Салават күперен эләм дә!..
Хыялда кышларны эретәм,
Йөрәктә яз чигү чиккәндә...
Кышларны эретәм...

Тамчылар тавышы

Тәрәздә тамчылар йөгерде,
Әй, кызык куышу уены.
Яшеннән чәчелгән яктылык
Күкләргә күтәрә уемны.

Тамчылар туктамый, куыша –
Су тулы касәләр ялтырый.
Тамчылар тавышы күкләрнең
Күкрәвен ишетеп калтырый.

Яшенле яңгырда коенып,
Йөрәгем сафлана, яшәрә.
Мин – тамчы, ташны да
тишәм, дип,
Омтылам дөньяда яшәргә.

Богылга җыярга бу җәйне

Богылга җыярга бу җәйне:
Чәчәккә күмелгән үләнне,
Ал таңдай алмалар битенең
Күңелгә бөркелгән саф ямен.
Чыкларны җиһанга сибәргә,
Печәнне чабарга, өяргә.
Исеннән исереп чилләдә
Толымнар үреп лә печәннән,
Күкрәккә кысканмын икән лә...
Күңелгә түшәргә бу мәлне:
Богылга җыелган бу җәйнең
Күз явын алырлык саф ямен!

Урман кояшы

Таслый-таслый сары яфрак җыям,
Иплән кенә салам чиләккә.
Сары көзнең затлы бүләкләре
Җан дәвасы булыр йөрәккә.

Яфрак җыям. Урман тәмам тынган.
Усакларны сарган сары моң.
Басар өчен күңел моңсулыгын
Сыйпап куям сары яфракны.

Узган гомер җимешле җәй икән...
Үзем өчен шуны аңладым:
Моңсу көзем килеп җиткән мәлдә
Яфрактан үрермен калфагым.

Назлы җырлар сирпер калфагымнан
Җәй җылысын, назын тоясың.
Яфраклардан йөрәкләргә күчкән
Сары яфрак – урман кояшы.

Фәйрүзә ХИСАМИЕВА

Бишек җыры – Ана иманы

Бишекләрдә һәркем тирбәлгән,
Бишек җырын Ана көйләгән.
Газизенә изге теләген
Бишек җырларында теләгән.

Бишек җыры – гади җыр түгел,
Бишек җыры – Ана иманы!
Баласына теләп игелек,
Җырга сала изге доганы!

Ана догалары изге бит,
Ә баласы аңа – көзге бит!
Һәр ананың күңел аклыгы –
Баласының тормыш шатлыгы!

Балаларның туган көннәре –
Аналарның олуг бәйрәме!
...Котлап бүген изге Ананы
Бүләк итик чәчәк бәйләме!

Яну кирәк

Мин үземчә сине сөям, дисең,
Мәхәббәткә сине төрәм, дисең...
Мин дә күпне өмет итмимен,
Чит-ятлардан сөю көтмимен!

Пар алкалар миңа бүләк иттең,
Муенымда – мәрҗән муенса.
Җилләр булып, болытларны тарат,
Күкләремдә алар куерса!

Йөрәгемне кояш булып җылыт,
Төннәремдә тулган Аем бул!
Йолдыз булып күкләремне бизә,
Таңнарымда шәфәкъ нурым бул!

Пар канатым бул син очар өчен,
Йөрәгемнең бул син яртысы!
Янар өчен сөю учагында –
Шул учакның бул син чаткысы!

Мәхәббәтнең сүнмәс хисләреннән
Сөю учаклары янганда:

Пыскып түгел – дөрләп яну кирәк
Бәхет касәләре тулганда!

Фасылларда – еллар дәвамы
Энҗеләргә охшаш карлар ява –
Акка төреп барлык дөньяны!
Яз кояшы, ерганаклар аша
Берләштерә елга, дәрьяны...

Язлар килгәч, агач яфрак яра,
Яшеллеккә төреп җиһанны.
Алтын-сары төскә бизәп куя
Якты көзләр шул ук урманны...

Офыклардан иртән кояш калка,
Нурга төреп туар көннәрне.
Тау артына качып кояш бата,
Ай-йолдызлар нурлый төннәрне.

Кеше туа җирдә яшәр өчен –
Ак кар кебек аның күңеле.
Яши-яши төрле төсләр белән
Бизәкләнә кеше гомере...

Килер фасылларда кабатлана
Яшел урман, туар таң нуры...
Кеше киткәч, дәвамчысы булып
Җирдә кала килер буыны.

Буыннардан-буыннарга күчә
Исеме һәм олы хезмәте...
Үлмәс исем белән мәңгеләшә –
Булгач аңа халык хөрмәте.

Фасылларда еллар дәвам итә –
Табигатьтә һәрчак яңарыш...
Үзе серле, үзе сихерле дә –
Яшәп туялмаслык бу тормыш!

Безнең төсле икән!

Тормышның сөю утында
Янарлык булсак икән.
Язмышның кырыс юлларын
Ялгышмый узсак икән.

Сөйгәннәргә мәхәббәттә
Нык терәк булсак икән.
Шатлыкта да, кайгыда да
Без кирәк булсак икән.

Ике йөрәк бергә типсә,
Мәхәббәт көчле икән.
Биек кыя, чиксез диңгез,
Иманнар төсле икән...
Нәкъ безнең төсле икән!

Лилия ФӘТТАХОВА

Сиптем – җыям

Сиптем – җыям уйларымны,
Сүттем – җыям.
Көйсезен дә, көйлесен дә
Бергә куям.

Минем уйлар – минем язмыш –
Үрелеп бара.
Асыллары тыйнаграк,
Чүбе – сара...

Башсыз җайдак чагым була –
Көчсез чагым.
Йомычкадай алып китә
Көчле агым.

Ишкәкләрне – уйларымны
Иярләсәм,
Офыкларны күреп алып,
Тагын ишәм.

Мин – иясе уйларымның,
Мин – хуҗасы.
Ничек кылсам фаразымны –
Шул буласы.

Туй

Мәхәббәт таҗын кидерә
Сөйгәннәр сөйгәненә.
Шаһинә тәхете әзер
Сөйгәннең йөрәгендә.

Татлы төшнең дәвамы ук
Яратып, назлап дәшү.
Якты хисләр танго бии
Үз телендә серләшеп.

Мәңге дәвам итәр кебек
Төшле-өнле бу халәт.
...Бүген – бер өйдә туй гөрли,
Өй түрендә – мәхәббәт.

Керфегемә төн эленгән

Керфегемә инде Төн эленгән...
Айдан төшкән
Өлгер Зөһрә-кыз
Бер әкият сөйли моңлы көйгә.
Ул әкият –
Сөю турындагы –
Синең турындагы татлы төш.
Бүген Көнем
Синсез – төссез иде,
Төнем якты итте тулган Ай:
Йолдызларны
Бераз читкә этеп,
Күктән сукмак салып
Килгән ул
Һәм Төш элгән керфек очына.
...Бер тамчы яшь
Тәгәрәде биттән.
Сөенечкәдер ул –
Очынам...

Нигә сүзләр?!

Каләмемне алдым, куйдым бүген...
Куйдым... алдым...
Телем – ярлы.
Вакланмасмы хисләрем дип,
Уйга калдым.
Үҗәт акыл дилбегәне
йомшартты да –
Сулу алдым –
Дөнья шулкадәрле гүзәл икән!
Хәйран калдым!
Сөю көен көйли җаным –
Нигә сүзләр?!
Күңел багым уртасында –
Синең эзләр.

Вакыт сиртмәсенә салдым
Уемның иң көйсезен.
Бәйләнчеккә әйләнгәнен,
Адашкан бер өйсезен.

Талгын гына тирбәлгәндә
Уяулыгы бетәрме?
Күңелемнең ишегеннән
Сердәш булып үтәрме?!

Вакыт сиртмәсенә салдым
Уемның иң көйсезен.
Иләк аша үткән инде –
Вакыт әйтер үз сүзен.

PRESSA.RU

Гүзәл ӘДҺӘМ укучыларыбызны өр-яңа хикәясе белән сөендерә. Бүгенге авыл, мәхәббәт, йолалар – бар да бер-берсен тулыландырып, җай гына үрелеп бара, якты тәэсирләр калдыра. Автор үзенең түгәрәк гомер бәйрәмен – 60 яшьлек юбилеен әнә шулай матур әсәрләре белән каршылый. Котлыйбыз! Илһамлы иҗат телибез!



Гүзәл ӘДҺӘМ

АЛМАЛЫ КӨЯНТӘ

(Хикәя)

Томырылып егеткә төбәлде кыз:
– Бу – нәрсә?
Егет каушады, ни әйтергә белми, бераз тотлыгып торды:
– Ч-ч-чиләк бит...
– Чиләк икәнен күрәм. Нинди чиләк дип соравым ла!
Егет кып-кызыл булды, сүзләрен дә авызыннан көчкә генә әвәләп чыгарды:
– С-с-сиңа... Б-б-бүләк...
Ну, шушы кыюсызлыкны! Җитмәсә, бераз гына каушадымы, тотлыга башлый Хәбир.
Зөлфирә, инеш буен яңгыратып, көлеп җибәрде. Туйганчы көлде...
– Чиләк бүләк итәләр димени, тиле...
Аннан, ишетелер-ишетелмәс кенә:
– ...кәем ... – дип өстәде.

Кызның авыз ерып торуы, егетнең бөтен кыюлыгын сыпырып алгандай итте... Күпмеләр әзерләнде бит югыйсә! Әйтәсе сүзләрен кат-кат кабатлап, ятлап ук бетергән иде.

«Зөлфирә! Җырдагыдай пар чиләкләр болар! Алмалы чиләкләр. Миңа кияүгә чык та, бу чиләкләр бергә тормыш башлап җибәрүебез билгесе булсын!»

Ие, менә шулай дияргә тиеш иде ул!

Билгеле, китапчарак яңгырый үзе. Булса соң! Киноларда гел шулай күрсәтәләр әле: «Синең кулыңны сорыйм!» – диләр дә, сөйгән кызларының учына йөзек салалар. Тик менә Хәбир үзе, үтерсәләр дә, алай дия алмас иде. «Кулыңны сорыйм, имеш». Аннары әле аның йөзеген дә каян табасың, ди? Кереп карады инде Казанның «Яхонт» дигән кибетенә. Күрде!

Сатучылары тезелешеп басып тора, киштәләре – буп-буш... Алтын балдакны да ЗАГС кәгазен күрсәткәч кенә саталар икән.

Егет уянып киткәндәй булды:

– Җырдагы кебек... итеп...

Зөлфирә көлүеннән шып туктады:

– Нинди җыр ул?

– Теге... Бар бит... «Сания апа суга бара, көянтәсе алмалы...»

Кызның тавышы кырыслана төште:

– Кайсы Санияне әйтәсең? Теге Түбән оч Саниями? Әллә аңа күзең төштеме?

«Их! Тагын аңлатып бирә алмады! Ну, шушы кыюсызлыкны!»

Колхоз аны Арчадагы өч айлык курска җибәргән иде. Әле кичә генә шуннан кайтып төште Хәбир. «Тимер эшләре остасы» дигән таныклык тоттырып җибәрделәр. Кайтышына машина-трактор паркында эш әзерләп куйганнар. Персидәтел үзе кулын кысты: «Синең кебек эш рәте белгән егетләр кирәк безгә!» – диде. Кечкенәдән тимер-томыр арасында кайнашып үсте лә ул. Хәзер кулда таныклык та бар, колхозда эш – муеннан, өйләнеп җибәрсәң дә була. Үлепләр сагынып кайтты бит ул Зөлфирәсен.

...Көтмәгәндә, Зөлфирә бер чиләкне кулына алды.

– Әнекәйгенәм! Алма төшерелгән түгелме соң моңа!

Егеткә җан керде:

– Алмалы чиләк... Җырдагы кебек дим бит...

– Абауларым! «Зөлфирә» дип язылган түгелме соң?

– Ие-е-е-е...

– Кая, икенчесен карыйм әле! Монда – «Хәбир» диелгән... Бу чиләкләрне чынлап та син ясадыңмы? Үзеңме?

– Ие-е-е-е...

– Йә... Йә... Шуннан?

Туктале! Нишләргә тиеш иде соң әле Хәбир? Әзерләп куйган матур сүзләр гел башыннан чыгып очкан бит!

Зөлфирә, зәп-зәңгәр күзләрен егеткә төбәп, тын гына көтә.

– Йә... шуннан? Җырдагы кебек дидең бит...

Егет тагын җанланды:

– Ие-е-е-е... Җырдагы кебек... Алмалы... Кияүгә чыгып...

Кыз бүтән көлмәде, калган сүзләрне, тыны белән суырып алгандай тыңлады.

– Миңа кияүгә чыгып... Бу чиләкләр... бергә тормышның билгесе...

...Ниһаять! Ниһаять, Хәбир Зөлфирәгә тәкъдим ясады! Күпмеләр көтте моны кыз. Пәһлеван гәүдәле шушы кыюсыз егетне үлепләр ярата бит ул. Үзе – Сабантуй батыры, көрәшкә чыгучыларны, берәм-берәм генә җилкә аша томыра, бүләккә бирелгән тәкәне сыртына салып, мәйданны «ә!» дигәнче урап чыга. Ә үзе... Бигрәкләр дә кыюсыз инде! Зөлфирә кыюрак булмаса, тәки шушы көнгә кадәр үбешмичә дә йөрерләр иде әле.

Йөрәге күкрәктән чыгардай булып: «Мин риза!» – дип дөпелдәсә дә, кызның бераз ялындырып аласы килеп китте.

– И-и-и-иии... – дип иренен бүлтәйтте ул. – Көянтәсе дә булмагач...

Шулай дип әйтүе булды, Хәбир – «ялт!» куак арасына.

– Көянтәсе дә бар... Менә!.. Алмалы көянтә... Җырдагы кебек...

Зөлфирә сөеп тә, сокланып та, томырылып карады: «Менә нинди егет бит аның Хәбире!»

Инеш буеннан алар, алмалы көянтәгә мөлдерәмә су тулы чиләкләрне асып, янәшә атлап кайттылар. Чишмә бурасында егетнең пәке очы белән уеп язган сүзләре калды: «Зөлфирә+Хәбир. 1975»...

***

...Фәрит Санияне инеш сукмагында тәки куып җитте.

– Сания-я-я-яү... Көт инде...

Сания ник бер сүз әйтсен, портфелен селки-селки тын гына атлавын белә.

– Сания дим... Ник дәшмисең инде?

– Агач тел!

Фәрит шаккатты:

– Кем? Минме агач тел?

– Кем булсын тагын! Күпме әйттем бит: «Сания апа диген», дип. Сания апа! Аңладыңмы?

– Икебез дә җиденчедә ләбаса! Бер класста укыйбыз!

– Укыса ни!

– Әле, җитмәсә, бер үк көнне туганбыз!

– Туса ни!

– Син миңа апа түгел! Сания син!

– Алайса, акыллым, бар, әниеңнән кайтып сора, яме!

– Нәрсәне?

– Беләсең килсә, мин иртү-ү-үк туганмын, таң атканда ук. Ә син миннән төп-төгәл ун сәгатькә соңрак тугансың! Аңладыңмы? Соңрак! Шулай булгач, син – энекәш!

Фәрит, ни әйтергә белми, шым булды.

«Буем тәбәнәк булганга, шулай мыскыллавы инде бу Саниянең».

Шулай да бер сүзсез генә биреләсе килмәде Фәритнең.

– Беләсең килсә, төрле кеше төрле вакытта үсә ул! Минем әти дә унынчы класста гына үсеп киткән. Ә хәзер әнә нинди – о-һо-һо!

Сания инеш буен яңгыратып чыркылдады:

– Шулаймын-и-и-и? Алайса, менә шул! Минем арттан зу-у-у-ур үскәч килерсең, яме, энекәш!

...Гарьләнү, үпкәләү һәм күпме рәнҗүле хисләргә шаһит булды бу инеш сукмагы. Барысы да – буй булмау галәмәте. Йә, күпме көтәргә була инде? Мәктәпне бетереп, кулына аттестат та алды бит югыйсә. Ә буй юк! Һаман да шул – метр ярым! Башкалар кичке

PRESSA.RU

«бичер»дан соң кызлар озата китә, ә Фәрит берьялгызы өйләренә таба теркелде.

Армиягә китәсе көнне ул Сания белән тагын бер сөйләшеп карарга булды, чишмәгә суга төшкәнен көне буе сагалады. Их, шушы самимилек! Бәлки әле чиккән кулъяулык та бирер дип, ни өметләнде бит күңеле. Нигә? Йоласы шундый ла! Классташ кызлар тырышкан әнә: ике кесәдә – унбиш кулъяулык.

Инеш сукмагында очрашты алар. Тик Сания генә сөю тулы йөрәкне яралап үтте:

– Солдат шулпасы үстерә, диләр. Зу-у-у-ур булып үсеп кайт, яме, энекәш! – дип чыркылдады.

Бу көнне чишмә бурасына яңа сүзләр өстәлде, пыяла китеге белән «Сания – 1995» дип сырлады егет. Ә үзе ишетелер-ишетелмәс кенә җыр сузды:

Сания апа суга бара-а-а,
Көянтәсе алмалы-ы-ы.
Алмалы көянтәсенә-ә-ә
Кунмаган кош калмады-ы...

Ә көянтәсе чынлап та алмалы Саниянең. Әтисе Хәбир ясаган кадерле көянтә...

...Авылга бүген солдат кайткан! Иптәшләре клуб буена җыелганнар иде дә, завклуб Саҗидә апа авызларын тиз каплады:

– Ачмыйм клубны! Шундаен матур көндә, ничу тузан туздырып ятарга! Әнә, чишмә буена төшегез.

Дөрес сүзгә җавап юк. Очтылар гына! Магнитофон уйнап тора, яңа баш төрткән яшел чирәмдә биюгә ни җитә! Түгәрәк уртасында гел солдат егет булды. Бүген – аның көне, аның бәйрәме. Кызлар шаккатып тел шартлата:

– Армия үстергән сине, малай! Буй да җитми бит үзеңә, – дип көлешәләр.

Фәритнең дә авыз колакта. Кыяфәт шәп егетнең: ул түштәге значоклар, ялтыравык погоннар дисеңме! Тик менә Сания генә... Һаман күренми... Әллә яшьләрнең чишмә буенда җыелганын белми микән? Белмәс – бар! Мондагы музыка тавышы чукрак Самат бабай да ишетерлек ләбаса.

Тәки килде бит кызый! Алмалы көянтәсен асып, чишмәгә суга төште. Фәритне дә бәхет басты, гомерендә беренче тапкыр Санияне биюгә чакырды. Тагын шулай мең, миллион тапкыр да биер иде ул, тик ниндидер озын чәчле бер егет бәйләнде генә бит кызга. Музыка башлануга – ялт! – килә дә баса кыз каршына, килә дә баса, бер алдына, бер артына төшә. Ә Сания шуны гына көтеп тора диярсең, кош тоткандай, егеткә карап мөкиббән киткән.

...Таралыша башлагач, Сания көянтәсен тапмады. Эзләмәгән бер генә куак төбе дә калмады кебек, тик алмалы көянтәдән җилләр искән иде. Мөлдерәмә чиләкләрнең берсен – Сания, икенчесен теге егет тотып сукмактан күтәрелгәндә, Фәрит нәүмиз генә артларыннан карап калды.

Икенче көнне чыбыксыз телефон авылга яңа хәбәр җиткерде: «Сания шәһәр егетенә ияреп калага ук китеп барган!»

* * *

Авылга бүген килен төшә. Киленнең дә ниндие әле – Казан кызы! Туй буласы йорт әллә каян күренеп тора. Бизәгәннәр, матурлаганнар үзен, буяулары әле уңарга да өлгермәгән, кояшта ялт та йолт килеп утыра.

Авылда шул инде: килен төшәсе йорт яны мыжлап тора. Анда кем генә юк – бөтен авыл шунда җыелган...

– Кара, бөтен кеше Казанда – ресторанда туй үткәргәндә, болар ничек авылда туй итәргә булган соң?

– Фәрит шулай кушкан, ди. Илнары да акыллы малай икән, әтисенең сүзеннән чыкмаган: «Мин монда, төп йортта яшисе кеше, туйны авылда ясыйбыз», – ди икән.

– Ай-яй! Белмим шул. Шәһәр кызы авылда калыр микән?

– И-и-и-и-и, шәһәр кызы дип инде! Үзебезнең авылдан чыккан ла! Хәбир кызы Саниянең Алсуы ла ул! Җәй буе әби-бабай янында булды, бакчасын да утады, сыерын да сауды...

– Санияне әйтәм, теге нәмәрсәсеннән аерылгач, тәки кияүгә чыкмады...

– Соң, Фәритне күр син! Хатыны үлгәнгә – биш былтыр, мал тотып, сыер асрап дөнья көтте, балаларын укытты. Авызына ник бер тамчы аракы алсын!

– Җүнле атадан җүнле малай үсә инде. Илнарны үзебезнең мәктәпкә билгеләгәннәр бит!

– Кит аннан! Әллә институтын бетергән дә?

– Бетерми ни! Бетермәсә, өйләнмәс иде. Алсу үзе җыр укытачак, ди. Теге бик зу-у-ур гармун бар бит... пиа... пиаминамы шунда...

– Рояль диген инде...

– Вәйт шул... Балаларны менә шунда уйнарга өйрәтәчәк, ди...

– Кара-кара... Хәбир белән Зөлфирәне күрче! Егет белән кыз диярсең! Яшәреп киткәннәр...

– Беренче оныкларын кияүгә бирәләр бит...

– Кайталар! Кайталар!

– Әнә, авылга керделәр!

Машиналар выжылдап килеп туктады... Илнур кәләшне күтәреп кенә мамык мендәргә бастырды. Алсу бер дә каушамады: мендәрдән җиргә атлады да ак мендәрне, тузаннарын кагыштырып, Фәриткә сузды.

– Менә маладис! Булдырдың, – дип пышылдашты хатын-кыз...

Үкчәле туфли кигән, чәчләрен кабартып ясаган чибәр хатынны күпләр башта танымый торды.

– Бә-ә-әй! Сания түгелме соң! Сөбханалла!

Хатын-кыз көнләшеп чыш та пыш килде:

– Шәһәр кешесе картаймый да инде!

Сания вәкарь белән генә Фәриткә күз салды.

– О-о-о! Сания апа! Рәхим ит, рәхим ит! Менә кода-кодагый да булдык!

Сания моны ошатып бетермәде:

– Син бигрәк инде, Фәрит! Мин нишләп сиңа апа булыйм, ди! Икебез бер класста укыдык ла!

– Әйе, классташлар да бит әле без!

Фәрит, елмаеп, кодагыеның кулын кысты...



«Чишмә». Мәдияр Хаҗиев эше.

...Шау-шу, ыгы-зыгы тынып торган бер мәлдә Казан кунакларының берсе гөлдердәгән калын тавыш белән әйтеп куймасынмы?!

– А вот невестага су юлын күрсәтү дигән обычай булачакмы биредә?

Барысы да бер мәлгә тынып калды.

Авылда бу йола онытылып килә иде...

Әйе, онытылган шул... Каршы ярда, чишмәгә терәп диярлек, асфальт салдылар да, инешкә төшә торган сукмакны яшел үлән басып китте. Чишмә суын да хәзер, пластик савытларга тутырып, машина белән генә ташыйлар шул.

Бар иде, бар иде бит андый йола! Алмалы көянтәсенә мөлдерәмә чиләкләрен элеп, чишмә тавыннан каушый-каушый күтәрелгән иде Зөлфирә. Йөрәктәге сөюе кебек, суының тамчысын да читкә тамызмаган иде ул. Әле кичә генә кебек! Күпме гомерләр узган...

Зөлфирә сөю тулы күзләрен Хәбиренә төбәде.

– Чынлап та, нинди матур йола бар иде бит! Әйдәгез, яңартыйк без ул йоланы!

Һәркемнең күңеле күтәрелеп, йөзләре ачылып китте. Яшь килен дә ни арада күлмәген алыштырып, аягына чәмчәле чүәкләр киеп чыккан.

– Мин әзер!

Аңа һәркем сокланып һәм сөеп карады.

...Чиләкләре бик тиз табылды.

– Ә теге... ничек әле... кәкрүшкә ... коромысло кайда соң?

Казан кунагының гөлдердәвек тавышыннан башта рәхәтләнеп көлештеләр.

Көлүен көлделәр анысы, тик менә... көянтә генә юк иде шул. Йорт саен агып торган кран суы көянтәне дә оныттырган лабаса.

Әллә нинди уңайсыз, читен бер тынлык урнашты...

– Менә көянтә дә табылды!

Барысы дәррәү тавыш ягына борылды. Сарайдан чыгып килгән Фәрит алмалы көянтәне яшь киленнең иңнәренә салды.


– Бу бит минем көянтә! Минем алмалы көянтәм! – Сания тотырып Фәриткә карады. Күзләр очрашты... Ирнең яшерен моң сарган серле карашы керфекләрендә эленеп калды.

...Кызлар яшь киленгә су юлын күрсәтә, янәшәдә гаярь егетләр гармун уйнап җыр суза.

Сания апа, чиләгеңнә-ә-ә-н
Суларың түгелмәсе-е-е-н.
Башкалар сүзенә кара-а-а-п
Күңелең сүрелмәсе-е-е-н.

Ә урамда җәй, егерме беренче гасырның чәчәкле җәе патшалык итә...

PRESSA.RU



Онытгың бугай

Сине уйласам, мине моң баса,
Борчылып йөрим инде ничә ай.
Күңелем сизә: назлы язларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Еракта калды, дәртләнеп-ярсып,
Без җырлап үткән ул яшел тугай.
Кабатлап булмый торган
чакларны
Оныттың бугай, оныттың бугай.

«Сөй», – дип үтенмим,
ләкин үкенмим
Яшьлектә сине сөйгәнгә шулай.
Син мине түгел, яшьлекнең үзен
Оныттың бугай, оныттың бугай.

Гәрәй
РӘХИМ

«ОНЫТТЫҢ БУГАЙ» ОНЫТЫЛМЫЙ...

Моннан 58 ел элек туган авылым Федотовкадагы (аның XVI–XVII гасырлардагы борынгы тарихи исеме «Аналык», ягъни «Ана авылы») унъеллык мәктәптә урта белем алдым. Ул чакта элеккеге Шөгер районында ике генә татар урта мәктәбе бар иде – берсе Шөгер районы үзәгендә, икенчесе безнең авылда. Бу төбәкнең күренекле татар авыллары Сарабиккол, Чыршылы, Куакбаш, Ормышлы, Кирлегәч һәм башка авылларында җиденче сыйныфны тәмамлаган татар яшьләре безнең керәшен авылына килеп, урта белем алалар иде. Шушы авылларның берсеннән безнең мәктәпкә килеп укучы гаять чибәр, гүзәл бер кызга үлеп гашыйк булдым!

«Мәхәббәттә без күпләргә
үрнәк булдык,
Бер тамырдан чыккан
ике гөләп булдык.
Аерым-аерым уйламадык
бер уйны да,
Бер үк хисне кичергән
куш йөрәк булдык», –

дигән шигъри юлларым шул кыз турында иде инде. Озын чәч толымнары, уймак иреннәре, актрисаларныкына охшаган матур йөзе, татар кызларына хас оялчанлыгы һәм тыйнаклыгы мине тәмам сихерли иде. Озын, киң итәге, фонарик җиңле җәйге блузкасы һаман күз алдымда. Ничек килешә иде аңа бу киемнәре! Атлап йөрүләре, елмаюлары, тавышы... Бар да камил! Әлбәттә, ул да мине бик яратты. Без бер-беребез өчен гомергә онытылмаслык беренче мәхәббәтләр идек. Моны безнең авылда да, чибәркәйнең туган авылында да яхшы беләләр иде. Яшьтәшләр, сабакташлар үз итеп, җиңелчә генә үртәп тә алалар. Безнең очрашуларга Колмаксар каеннары, атаклы Шандор таулары, кылганлы тау кашагалары, әрекмәнле таллыклар, шомырт чәчәк аткан язлар, чәчәкле акланнар шаһит.

«Уңда ак ай батты,
сулда ал таң атты...
Күзгә-күз карарга кыймадык.
«Кеше күрер, кайтыйк инде», –
дидек,
Әллә иртәләдек,
әллә соңладык», –

дип яздым мин соңрак, ул көннәрне сагынып.

Әмма күпчелек беренче мәхәббәтләрнең киләчәге бик зур каршылыкларга дучар булып, күңел фаҗигасе дәрәҗәсендә калып, алга таба дәвам итә алмаганы кебек, без дә кавыша алмадык. Моның катлаулы сәбәпләрен сөйләп тормыйм. Ул кызның безнең мәктәптә укыган еллардагы образы күңелемдә мәңге онытылмаслык татлы хатирә булып калды.

Мәктәпне тәмамлап, төрлебез төрле якка таралгач, ул миңа: «Без синең белән мәңге бергә була алмыйбыз, бер-берсен артык нык яратканнар беркайчан да кавыша алмаган. Башкача миңа хат язма», – диде. Минем өзгәләнеп-өзгәләнеп аңа язган хатларым җавапсыз калды.

Инде бу бөек мәхәббәтебезне дәвам итәргә бер генә юлым калды – әдәби иҗатка чын-чынлап бирелеп киткәч, әледән-әле аңа багышлап шигырьләр яза башладым.

«Замана да, чор да түгел –
Гаепледер үзебез:
Мәңге бергә булалмаган
Мәңгелек мәхәббәт без!..

Күрәмсең, безнең гомерләр
Бәхетсез дә түгелләр...
Бәхетле дә түгелләр...»

Яки менә монысы:

«Син бүген дә миннән еракта,
Иртәгә дә миннән еракта,
Гомер буе миннән еракта –
Ләкин үзең һаман йөрәктә».

Укый микән, үзенә багышлап язганнарын сизә микән – бернәрсә белмим! 1960 нчы еллар тирәсендә аңа багышлап «Оныттың бугай» дигән шигырь язып ташладым. Шундый бер сагынычлы халәт иде инде. Китапларга кертмәдем, шулай да газета-журналларда басылып чыкты ул. Каләмдәшләрем, шигырьнең бик эчкерсез, чын күңелдән язылган икәнен әйтеп, мине котладылар. Бәлки, тынычландырганнардыр...

1965 нчы еллар тирәсендә халкыбызның талантлы җырчысы Гали Ильясов мине очратты да әйтте: «Гәрәй, мин, җырчы булуым белән бергә, әйбәт шигъри текстларга җырлар да язам бит әле. Синең «Оныттың бугай» дигән шигырең бик ошады. Мин аңа музыка яздым. Әйдә тыңлап карыйк әле», – дип, җырлап та җибәрде. Матур җыр иде ул! Гали бу җырны үзенең концерт программаларына кертте, башка җырчылар да яратып башкаралар иде. Озак та үтмәде, «Оныттың бугай»ны артистлар гына түгел, халык та җырлый башлады. Җыр татар авылларында мәҗлесләрдә, урамнарда яңгырый...

Шуннан соң мин аны 1974 елда басылган «Гөрләвек» исемле китабыма да керттем. Ул елларда нәшриятларда басылган күп кенә җыр китапларында да урын алды. Хәзер дә җырчыларыбыз репертуарында гына түгел, республикакүләм зур концертларда, Мәскәү, Төркия, төрки телле республикалар сәхнәләрендә яңгырый тора. Җыр миңа популярлык, танылу китерә. Шагыйрь буларак, моның белән бик горурланам.

Ләкин... Ләкин мин бу җырны язуыма эчтән генә, яшертен генә шактый үкенәм дә...

Йөзләгән, меңләгән тапкыр һәр тыңлавымда, ул минем йөрәгемне телеп-телеп ала. Ул бит минем бәхетсез мәхәббәтемне хәтерләтә, ничәмә-ничә дистә еллар буе үзәгемне өзә, елата...

Ә җыр дәвам итә. Хәзер инде аны минем оныкларым яшендәге яшь җырчылар да башкара. Шунысы кызганыч, бу җырны инде аның авторларыннан бер мин генә тыңлый алам. Җырның музыка авторы, күренекле җырчыбыз Гали Ильясов инде күптән арабызда юк. Югыйсә ягымлы елмаюы, тыйнаклыгы, шаян сүзләре, тенор тавышы, кабатланмас җырлары белән күпләрне сөендерер иде.

«Оныттың бугай» җыры менә шулай – кадерле хатирәләрне яңартты...

PRESSA.RU













ЖИҢҮЧЕ

КЕШЕ ЕЛМАЙГАНДА МАТУР БУЛА. НИ ӨЧЕН АЛАЙ ИКӘН УЛ?

Ризидә ГАСЫЙМОВА

Мин Миләүшәгә карап, аның фаҗигале язмышы турындагы мавыктыргыч хикәятен тыңлап, шул турыда уйланып утырам. Уйланмас та идем – Миләүшә гел елмаеп сөйли. Күзләре әледән-әле очкынланып китә, бит очларында сизелер-сизелмәс кенә мәхәббәт чокырлары күренеп ала. Кайсыдыр бер мизгелдә генә күзләре мөлдерәмә тулып куя да... Тагын елмая.

Матур дигәннән... Яшь чагында ул, мөгаен, Мамадышның иң матур һәм булдыклы кызы булгандыр. Зифа буй-сынлы, озын саргылт чәчләрен толымлап үреп иңнәренә салган... Мин аны шулай күз алдыма китерәм. Район җирендә бик кирәкле һөнәр ияләренең берсе – «товаровед» була Миләүшә. Аннары (90 нчы еллар!) безгә яхшы мәгълүм үзгәртүләр-кыскартулар башлана: сәүдә базасын тараталар, Миләүшәне раймагка күчерәләр. Хәер, ул инде үзе дә хөкүмәт эшенә генә карап утыра алмый – кайнап торган базар дөньясына кереп китә. Казан бинокльләрен, Чистай сәгатьләрен Польшага алып чыгып, сату белән дә шөгыльләнә. 1994 елда Миләүшә ак төстәге «шестерка» (ВАЗ-2106) сатып ала. Ә 1996 да «шестерка»сын өр-яңа «девятка»га алмаштыра. Кыскасы, хөкүмәт эше дә бар, бизнес та. Атлап түгел, йөгереп түгел, очып кына йөри торган чак! Тик... артык эшлекле-шөгыльле тормыш та арытып җибәрә бит ул кешене. «Их, ял итәсе иде берничә көн беркая бармыйча, беркемне күрмичә!» – дип уйлап куябыз бит кайчакларда. Гөнаһ шомлыгына каршы, Миләүшәнең дә күңеленә килеп китә мондый уй.
Ә язмыш кызны, шуны көтеп кенә торгандай, ашкынып алга барган җиреннән озакка... биш елга ук туктата. 1997 елның 1 гыйнварында ул машинасы белән юл һәлакәтенә очрый. «Күз тигәндер Миләүшәгә...» – аны авыр хәлдә больницага озаткан ЮХИДИ хезмәткәре шундый нәтиҗә ясый...

...Ул чакларда кызның һәм якыннарының кичерешләрен сөйләр өчен каян гына сүзләр табып бетерәсең? Мин шулай дип аптырап утырам менә, ә Миләүшә үзе бу хактагы истәлекләрен бик гади итеп яза:

«1997 елда үз машинам белән автоһәлакәткә очрадым. «Миләүшәнең үлгән хәбәре юкмы, некролог бирергә соңга калмадыкмы?» – дип, район редакциясенә шалтыратучылар күп булган...»

Шалтыратсалар да, кем әйтмешли, гаҗәп түгел – бик авырлык белән кире кайта кыз бу якты дөньяга. Авыруны урыныннан кузгатырга ярамый – операция ясау өчен Казаннан ашыгыч төстә нейрохирург Геннадий Васильевич Савкинны чакыралар. Юлның яртысын табиб Казан машинасы белән килә (бу бит Яңа елның беренче көне әле!), ярты юлдан мамадышлар каршы барып ала. Ничек итсәләр итәләр – кызга тәүлек узганчы операция ясала.

«Реанимациядә ятканда мин бер төш күрдем. Ачык капка каршында торам, имеш, ә анда, тәхеттә бер кечкенә генә ак сакаллы карт утыра. Бөтен халык аның каршына җыелган, фатихасын сорыйлар, имеш. Мин дә кермәкче булам. Тик, мин керәм дигәндә генә, капканы ябып куялар».

Әниләре мәктәпне тәмамлагач, укырга дип өйдән таралышкан кызларын (алар өчәү, Миләүшә – төпчекләре) максатчан төстә кире туган якларына – Мамадышка җыйган була. Бер-берсенә бик-бик кирәк булуларын алар шушы чакта, һичшиксез, тагын бер кат аңлаганнардыр. Апалары (Йолдыз белән Алсу) дүрт ай буе Миләүшә белән бергә «больницада яталар». Алсу (Алсу Спиридонова, «Нократ» газетасы журналисты) сеңлесенең берни тоймаган аякларына сәгать саен массаж ясый. Миләүшәнең җизнәсе Степан Петрович Спиридонов бөтен анализ кәгазьләрен, рентген «снимок»ларын җыеп, шушы юнәлештә эшләүче профессорлар белән киңәшләшеп кайта. Район больницасы табибы Булат Мөдәрисович Гыйлемханов авыруның хәлен белергә көненә унар мәртәбә керә. Шулай җыйнаулашып көрәшә торгач, ниһаять, көннәрдән бер көнне кыз бер аягының баш бармагы сизә башлаганын тоя.
Йә, моннан да зуррак сөенеч булырга мөмкинме кеше тормышында? Хәрәкәтсез ятуына 4 ай дигәндә, һаман да шул җизнәсе тырышлыгы белән Миләүшә район больницасыннан Казанның вертеброневрология үзәгенә барып эләгә. Кызны бүлек мөдире Геннадий Иванович Галочкин дәвалый. Авыруны, туры мәгънәсендә, «урыныннан кузгата» ул. Табиб ярдәме белән беренче мәртәбә торып утырганда, кыз шабыр тиргә бата. Аннары әкренләп кенә яңа «һөнәрләргә» – кулларына таянып, тезләнеп (эт сыман) басып торырга, үрмәләргә өйрәнә...

Үземнең күздән яшьләр тәгәри, ә үзем... хәлдән тайганчы педаль әйләндерәм...

«Мине җәй көне авылга – Урта Кирмәнгә алып кайтып куйдылар. Мин кайда – велотренажер да шунда. Әти белән әни йокларга яткач, үрмәләп өйалдына чыгам. Аякларны, шуып төшеп китмәсеннәр өчен, педальләргә ныгытып бәйләп куям да, тотынам әйләндерергә. Безнең авылдан ерак түгел М-7 трассасы уза. Төнге тынлыкны бозып, арлы-бирле чабышкан машиналар гүләве аермачык булып ишетелеп тора. Менә шул машиналар мине үзләре янына дәшәләр: «Миләүшә, җитте, ялың бик озакка китте, әйдә, бас аягыңа!» – диләр сыман».

Җизнәсе, мең мәшәкатьләр белән, аны Боровое Матюшинодагы икенче бер реабилитация үзәгенә урнаштыруга да ирешә. Бу үзәккә кыз инде коляскага утырып бара. Һәм аны үзе кебек коляскада утырган кешеләр каршы ала. Килеп керүгә аңлый кыз: монда бөтенләй башка дөнья. Болар алдында зарланырга, мескенләнергә ярамый! Монда барысы да синең юлны узган.

Биш ел дәвамында һәр ярты ел саен икешәр айга бара Миләүшә әлеге реабилитация үзәгенә. Кемнәр белән генә танышмый, кемнәр белән генә табышмый. Шунда гомерлек дуслар таба...

Больница ятакларында, реабилитация үзәкләрендә, әниләре, туганнары янында яшәгәннән соң, көннәрдән бер көнне ул, ниһаять, өенә кайтырга карар кыла. Фаҗигале Яңа ел төненнән соң 4 ел да 4 ай үткәч! Туганнары кергәләп йөрсәләр дә, хуҗа юклык эзсез узмаган – гөлләренең бөтенесе кибеп беткән.
Тик берсенең кечкенә генә бер яфрагы, күңелдәге өмет кебек, ничектер сакланып калган!

PRESSA.RU

Безнең өчен бик гади сүз бит инде ул – өй. Ә Миләүшә өчен бу мөстәкыйль тормышка кире кайту, дигән сүз. Туганнарына катгый төстә әйтеп куя ул – мин чакырмыйча киләсе түгел. Малосемейка бүлмәсе (ул вакытта әле үз фатиры юк) өченче катта – беренче көннәрдә култык таяклары белән шак-шок килеп баскычтан менәргә-төшәргә өйрәнә. Идәнне үрмәләп юа. Ашарына пешерә. Әле тагын бер мөһим эш бар бит – ни гомерләр чигереп килгән. Йорт каршындагы гараждан машинаны барып карыйсы бар. Тәвәккәлләп чыгып китә кыз. Машинаның, чыннан да, «исән җире» булмый. Арттагы юлны күрсәтә торган көзгесе генә, ни гаҗәп, төзек калган. Машинасын шул хәлендә сатып та җибәрә Миләүшә. Һәм озакка сузмыйча (нишли дип уйлыйсыз инде?), үзенә икенче машина эзли башлый. Туганнарының каршы булачагын чамалый, шуңа аларны борчып тормый, бу юлы элекке хезмәттәшләрен ярдәмгә чакыра. Дус-ишләре – дөнья күргән шофер егетләр, коляска кертергә ишеге уңай, дип, «восьмерка» алырга киңәш итәләр. Үзләре алып кайтып та бирәләр! Хәзер инде кул белән идарә итү җайланмасын көйләтәсе, һәм авылга кайтып, машинаны яңача йөртергә өйрәнәсе кала... Ә 2002 елның 24 августында (тарихи көн бу аның өчен!) Миләүшә машинасы белән берүзе дусты Гөлнәзирәнең туган көненә юнәлә.

Ә руль артындагы рәхәтлекне белсәгез! Мин – ирекле кош. Юк, канатларым каерылмаган минем!

Мамадышлар аны яңадан рульдә күреп шаккатканнар ул чакта! Машинада ул булуына ышанмыйча, узып киткән җирләреннән кире борылып килүчеләр дә була: «Миләүшә, чынлап та синме соң бу?!.»

«Мине кабат руль артына утырыр дип берәү дә уйламагандыр. Тик үзегезне дүрт стена арасында бикләнеп калган итеп күз алдына китереп карагыз әле сез! Дүрт стена, идән-түшәм – бик әйбәт тәрбияче алар».

Бу чын хикәятнең дәвамын... рухи яктан аякка басу дип атасак та буладыр. 1 нче группа инвалид ханым үз эшен ачып, шашлык сата башлар дип, мисал өчен, ул вакытта кем уйлаган? Дусты Гөлнәзирә (Мамадыштагы «Диләрә» кафесы, кибетләр хуҗасы) җаваплы вазыйфа тәкъдим иткәч тә, кире какмый Миләүшә – 10 ел дәвамында мөһим документлар, «поставщиклар» белән эшли. Хәзер инде аның тормышында тагын көтелмәгән борылыш – Мамадыш районы инвалидлар җәмгыяте тренеры Вәсимә ханым Имамова Миләүшәгә Паралимпия уеннары чемпионы Ирина Поляковадан махсус җайланмалы чаңгылар алып кайтып бирә – ул шулай итеп спортка килеп керә. Мамадышта узган чаңгы буенча республика чемпионатында (Ирина Поляковадан гына калышып) икенче урынны яулый. Кул көрәше, теннис, штанга, гер күтәрү, җиңел атлетика, шашка... Шуның өстенә әле бизнес – «Amway» продукциясен тарату белән дә шөгыльләнә. Вконтакте социаль челтәрендә инвалидлар оешмасының рәсми төркемен алып бара. «Татарстан яшьләре» газетасында аның инвалидлар тормышы турында язылган язмалары да дөнья күрә. Инвалидлар турында, чыннан да, бик аз язалар бит бездә. Хәвеф-хәтәргә юлыгып, көтмәгәндә гарипләнгән кешенең югалып калуы да табигый: ә моннан соң ничек яшәргә? Ничек итеп киенергә, кеше белән ничек сөйләшергә, үзеңне ничек кулга алырга?

...Без Миләүшә белән җиләк-җимеш җыю серләре турында сөйләшеп утырабыз.

– Каен җиләге урманнан кеше аягы бик басмаган ташландык болыннарга чыкты бит хәзер, – дип сөйли ул. – Витаминнары саклансын өчен ике сәгать эчендә шикәр комы белән болгатып, суыткычка куярга. Башта каен җиләге җыябыз, аннары җир җиләге өлгереп җитә, аннан – ирга...

Үзе шул арада миңа күчтәнәчкә җибәрергә дип суыткычыннан тәмле җиләк кайнатмасы ала.

Җиләктән соң сәяхәт темасына күчәбез. Россия төбәкләрен – Кырым, Төмәннәрне санамаганда да әле, кайларда гына булмаган Миләүшә! Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Мисырда, Төркиядә, Испаниядә, Польшада, Һиндстанда, Израильдә, Тунисta... Якын киләчәктә Мароккога һәм Иорданиягә барырга планлаштыра. Хыялланып тормый – максат куя да тормышка ашыра. Япа-ялгызың, билгеле, юлга чыга алмыйсың – туганнары да аның кебек үк сәяхәт итәргә ярата...

– Сәяхәт, дигәннән... Мин бит автобуска соңга калам!

– Әйдәгез, мин сезне машина белән озатып куям! – Миләүшә шундук тиз-тиз киенә башлый. Берничә минуттан без аның затлы «Фольксваген Гольф»ында олы юлга таба җилдерәбез. Бу аның сигезенче машинасы икән... Ну, Миләүшә!

– Тукта, без бит әле төп теманы истән чыгарганбыз! Миләүшә Хәсәнованың күптән түгел Алабугада узган «Ел хатын-кызы» бәйгесендә катнашып, җиңү яулавын. Хәзер бәйгенең йомгаклау турына – Казанга җыенуын...

– Әй, – дип көлеп каршы төшә миңа Миләүшә, – бәйгедә җиңү – минем җиңүмени ул? Бөтен район безнең өчен (без мамадыштан икәү) тырышты анда. Район хакимиятеннән шалтыратып, катнашырга тәкъдим иттеләр – мин тыңламый булдыра алмадым.

– Шулай да, ниләр сөйләдең соң?

– Минә шушыларны инде. Ничек яшәвем турында. Нәрсә сөйлим? Мин бит герой түгел.

«Күпме урын өсләрендә хәрәкәтсез ятканнан соң, мөстәкыйль рәвештә чаңгыда шуам. Егылсам да көләм генә. Карның нинди тәмле булуын сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый. Үземнең нинди сәләтләргә ия икәнлегемне белмичә үлеп китәсе булганмын икән!»

Миләүшәнең аянычлы да, куанычлы да кичерешләре язылган истәлек дәфтәрен укыйм да, ирексездән уйлап куям: «Ел хатын-кызы» бәйгесендә җиңү Миләүшәнең үзе өчен кирәк микән ул? Ул бит болай да җиңүче!»



Асия
ЮНЫСОВА

ГЕЛ ДӘ ГЕЛ БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕ БЕРӘҮНЕҢ ТОРМЫШ ЫГЫ-ЗЫГЫСЫНДА ҮЗЕН ЮГАЛТУЫН КҮРЕП, УЙГА КАЛАСЫҢ. НИ ӨЧЕН ШУЛАЙ БУЛГАН СОҢ ӘЛЕ МОНЫҢ ЯЗМЫШЫ? НИГӘ, НИЛЕКТӘН?

КАДЕРЕҢНЕ БЕЛ...

Менә мин дә аптыраашта калган берәү хакында уйланып утырам әле.

«Эш эзлим», – дип килеп басты ул безнең эш бүлмәсенең ишек төбенә. Бала гына кебек күренә кызыкай. Югыйсә югары белем алганлыкка дипломы да, татар теле белгече дигән профессиясе дә бар икән. Ә менә моңа кадәр әле беркайда да эшләп карамаган. Диплом алуга, аның чибәрлеген, садәлеген, тәҗрибәсезлеген олы бирнә сыман күргән бизнесмен егеткә кияүгә чыгып куйган. Шуның белән кайнап торган шәһәр тормышы, җәмгыять яшәеше аның өчен ишекнең тышкы ягында калган. Хәер, бала үстерү белән мәшгуль һәр хатын-кыз өчен шундый бер ара була инде ул.

– Ирең бизнесмен булгач, сиңа эш нигә кирәк? Улыңны тыныч кына үстереп, тик ят өйдә. Балаң исәя төшкәч, эше дә табылыр, – дип, төрлебез-төрле яктан үгетли башладык. Ул арада Гөлназның күзләренә яшь тыгылды:

– Ирем минем белән тормас инде. Аның сөяркәсе бар хәзер. Ул аны – үзеннән ун яшькә өлкән хатынны ярата. Ә ул хатынның баласы юк. Балабызны бик ярата ирем. Шуңа гына минем белән яши торгандыр инде ул. Яши, дип... Бер өйдә торабыз, диюем.

Гөлназ шундый да сөйкемле, чибәр ки, мондый гүзәл затны яратмау мөмкин түгелдер кебек. Аптырап калабыз. Теге иргә ачу чыга. Дәррәү Гөлназны юата башлыйбыз: «Сабыр бул. Бизә әле ирең ул хатыннан,



менә күр дә тор, матур итеп яшәп китәрсез. Ул да хәзерге ялгышы өчен бик үкенер. Сер бирмә, ягымлылык белән алдыр, хәйләкәррәк бул», – дип, үзебезгә юк акылны аңа өйрәтмәкче булабыз.


Гөлназ бу нәни сер-хәйләләрне сынап караган икән инде. Аның ире каты чикләвек булырга тиеш. Ир кеше бөтенесен алдан уйлаган, хәстәрен күргән икән. Туган авылына кунакка да хатыны белән баласын ияртмичә генә кайтып килә. Оныгын күрергә тилмергән әби-бабайга да Казанга юл ябык. Киленне яратып өлгергән ата-анасы хәзер инде Гөлназдан суынсын өчен бөтенесен эшли ир кеше. Ата-ана улларына фатир да алып биргән булганнар икән. Яшь гаилә шул фатирда яши.

– Мин, аерыла калсам да, торакка дәгъва кыла алмыйм. Әти-әнисе аны бит уллары өчен сатып алган, – ди яшь ана, баласын күтәреп, фатирдан чыгып китәргә әзерлеген белдереп. – Ирем мине дә, улыбызны да әле яши торган фатирга пропискага кертмәде. Инде баланы бакчага бирергә вакыт. Прописка булмагач, чиратка баса алмыйм. Сөяркәсе янына ешлагач, «Никах контракты» төзедек. Ул контрактта мин, «фатирга дәгъвам юк», дигән пунктка имза салдым. Ирем шулай кушты.

Менә сиңа мә! Имәндә икән чикләвек! Бик хәстәрчән булып чыккан әле бу ир. Беркатлы, садә күңелле хатын-кызларны кызык итә белә икән бу. Хуш, Гөлназ, баласын алып, фатирга чыгып киткәч, күпмедер вакыттан соң ата кеше баланы үзенә алу артыннан йөри башлаячак. Чөнки теге хатын баласыз, бәлки, таба да алмый торгандыр. Шул очракка ирнең дәлиле әзер: «Элекке хатынымның бала тәрбияләү өчен кереме дә, торак шартлары да юк!» – дияр ул. Һәм судта озакка сузылган тарткалаш башланыр. «Никах контракты»н төзегәндә ана белән баланың мәнфәгатьләрен кем уйларга тиеш булды икән соң? Әлбәттә, Гөлназ үзе. Инде әни булганның соңында ана-арысланга әйләнү тиеш иде бит аңа.

Без Гөлназны дүшәмбегә кабат чакырган идек. Ниятебез аны гаилә хокукларын белүче юрист белән очраштыру иде. Тик яшь ханым дүшәмбедә дә, аннан соң да килмәде. Катлаулы проблемасын хәл итүнең әмәлен тапты микән, әллә өенә кайтуга иренә кайда, нишләп йөргәнен сөйләп биреп «янды» микән?

PRESSA.RU



ЭКСПЕДИЦИЯ. АВЫЛЛАР. ҖЫРЛЫ ҖӘЙГЕ КИЧЛӘР. ДУСЛЫК КАДЕРЕ. САКСЫЗ КАГЫЛУДАН ДА ӨЗЕЛЕРГӘ ТОРГАН, КЫЛДАН НЕЧКӘ ХИСЛӘР...

Яшь студент кызның көндәлеге шулар белән шыплап тулган! Нәрсә булды Гөлчәчәккә? Кәефенең гел үзгәреп торуын, кәефсезлек чиген үтеп, иләсләнеп очып йөрүләрен ничек аңлатырга?



Эльмира ЗАКИРОВА

САҒЫНЫП КАЙТЫП КЕРСӘҢ...

(Дәвамы. Башы 2 нче санда.)

28 июнь. «Бүген кичекмәстән Балтачка китәргә кирәк, җәмәгать!» – җитәкчебез Фәнисә апа иртүк шулай уятты. Тагын шул авыр сумка, рюкзакларны асып, Лираның транзисторындагы дәртле марш астында яңгырдан соң тәмам сазлыкка әйләнгән юлдан автовокзалга атладык. Үтереп йокы килә. Монда сәгать инде иртәнге 8, ә бездә 6 гына әле.

«Җир бераз җилләсен, автобус килер, мөгаен», – диделәр. Йә киләчәк, йә килмәячәк, димәк. Тиктормас Алик үз эшендә: «интервью, интервью» дип сикергәли. Әле берсенә, әле икенчесенә килеп бәйләнә.

– Э-ээ, гафу, Зөфәр иптәш, ничек уйлыйсыз, бүген без бу җәһәннәм тишегеннән китәләбезме, юкмы?

– Тракторның көпчәкләре таралган. Шуны төзәткәч инде, – ди Зөфәр, үзенә хас салмаклык белән.

– О-оо! Фәнисә апа! Бер соравыма җавап бирегез: бу бишьеллыкта без китәләбезме, ничек уйлыйсыз?

– Бишьеллыкның хәлиткеч елы булганлыктан, китәрбез дип уйлыйм, – дигән тапкыр җавап яңгырый.

– Ә сез кайсы авыл чибәре?

Сылу Зөләйха аптырап калмады:

– Килә-килә, авылымны да оныттым инде, – дип, үзеннән читкә этәрде.

Кара бу Аликны! Безнең группада укымагач, беребезне дә белми. Һәм танышуның шундый җаен тапкан!

– Гөлчәчәк туташ! Гөлчәчәк Мирзаһитова! Менә кем ул чын татар кызы!..

Әһә! Чират миңа җиткән икән! Тик... мин ул кадәр үк миллилек үрнәге түгел бугай: чәчләр – киселгән, итәкләр – тездән югары... Юктан да кызара, ояла торган кызый булганга үртәвеме соң? Ә мин артистланып:

– Мин Өфедән, башкорт кыды! – дидем кыланып. «Миндәлә кыдыл бодаулары»на башкортчага күчү әллә ни кыен түгел иде.

Алик, күзләрен мутландырып, тагын нидер әйтмәкче иде, «автобус Балтачка баралмый» дигән хәбәр бу уенны күмеп китте. Тиз генә ничек китүне хәл итәргә кирәк иде: шәһәрара электричкага утырып, кабат Янаулга кайтып киттек. Минем урын Радик белән янәшә. Ул ничектер сынап карый.

– Син чынлап та башкорт кызымы? – ди.

Менә бит, кеше ышандырырлык итеп алдашканмын. Уңайсыз булып китте. Кызарып чыктым. «Юк ла, шаярттым гына. Минзәләдән мин», – дим. Ә Радик Агыйделне иңләп-буйлап йөзеп үскән егет икән. Уфаныкы! Таныштык та!

Янаулга җитәрәк, безнекеләргә тагын җан керде. Әйтмәсәм дә, Радик уйларымны каян сизде икән: Сара Садыйкованың «Әй, ямьле син, Минзәләм ягы!»н уйнап җибәрде. Бөтенесе күтәреп алды.

Әй, ямьле син, Минзәләм ягы! / Синдә минем яшьлегем таңы...

Янаул. Йөрибез шулай Янаул белән танышып. Берзаман Камал театрының автобусы күзгә чалынмасынмы! Үзебезнекеләр! Нәҗибә Ихсанова, Наилә Гәрәева, Наил Әюповлар... Башкортстанда гастрольләре икән. Бүген кич Нефтекамскида «Диләфрүзгә дүрт кияү»! «Бәхетлеләр!» – дип куйдым, тамашачыларны күз алдында тотып. Радик: «Минем дә бәхетле буласым килә! Әйдә, көз көне бергә барып карыйк әле, кызлар!» – диде дә: «Чәчкә! Син барасыңдыр бит?!» – дип миңа төбәлде.

Уу-у-у! Көз җиткәнче әле!

...Без утырган автобус матур урман аланында туктады. Без, кызлар, йөгерә-йөгерә зәңгәр чәчәкләр җыйдык. Нурия такыя үреп... Радикка кигерде. Кы-зы-ык... Аликка да, Зөфәргә дә, Тимурга да түгел! Юк, мин алай эшли алмас идем. Чәчәкләремне кочаклап, Айсылу янына күчтем. «Утырыгызчы икәүләп!»

Балтач. Эңгер-меңгердә генә Балтачка килеп җиттек. Фәнисә апа белән Тимур урнашыр урын эзләп киттеләр, без бала-чага кебек «Бүкән ярыш»лы, «Күз кысыш»лы уйный башладык. Уф, бу Аликны! Артистланып, минем сүзләрне, хәрәкәтләрне кабатлый. Юри мине үрти! Үпкәләп, елап, читкә киттем. Нурия белән Лира килеп карады, аннан – Алик. Гафу үтенде, шаяртканны да аңламыйсың, ди. Һаман эндәшмим. «Авыл кызы булсаң, авыл кызы бул инде! Бигрәк юкка-барга үпкәләгән булып...» – диде дә, чырыйлата-чырыйлата күтәреп, түгәрәк янына алып китте. Радик минем турыда нәрсә уйлады икән?

Тимкә. Райком машинасы безне колхоз идарәсе каршына китереп туктатты. Авыл халкы артистлар дип кабул итте. Бүген кич беренче концертыбыз. Аңа кадәр әле интернатка урнашасы, ашарга хәстәрлисе, фольклор җыеп йөрисе бар. Берничә төркемгә бүленеп, авыл буйлап киттек. Нурия белән мин Лотфулла бабайга барырга тиеш идек. Радик безгә иярде. Капка төбе саен ата казлар ысылдап килә. Котым очып, урамның каршы ягына йөгерәм. «Авыл кызы шулай буламыни!» – Нурия пыр туздыра мине. Радик көлә. «Чәчкә! Син минем сеңлемә охшагансың! Нәкъ Рания инде!» – дип, баласытып карый. Әһә, сеңлесе дә бар икән... Кичкә кадәр шактый материал тупладык. Ә аннары аякларыбыз үзеннән-үзе яшел болын ягына атлады. Рәхәтләнеп волейбол уйнадык.

Их, ничек матур итеп әйтте ул бу сүзләрне!

30 июнь. Халык фольклор җыярга чыгып китте. Айсылу белән Наил авыл мулласыннан алып кайткан китапны баш та күтәрми күчерәләр. «Киткәндә кире китереп бирерсез», – дип, кат-кат әйткән бабай. Наил гарәп хәрефләрен татарчага әйләндергәндә, һәр сүзне җентекләп тикшерә, мәгънәсенә төшенергә тели. Шундый ул безнең! Урал якларында үскән шәһәр малае, татарчаны камил өйрәнү өчен, тарих бүлегеннән махсус безгә күчте. Телне өйрәнү өчен ниләр генә эшләми: рус телендә укылган лекцияләрне дә татарча язып бара, татарча китаплар укый, көн-төн «читалка»да утыра. Бер рус сүзен дә кыстырмыйча сөйләшергә тырыша егетебез. Авыл аның өчен бөтенләй ят дөнья. Башка планетага эләккән кеше кебек йөри. Әнә бүген дә тышаулап куелган бозауның чирәм чемченүен исе китеп күзәтте дә: «Айсылу, сыер баласы кем була ул?» – дип сорый!

Лира белән мин кизү торып калдык. Савыт-саба юарга, ашарга әзерләргә, кер юарга... Аликның зәңгәр джинсыен – беренче чиратта, диделәр. Кичке концертка ничек тә киптереп куярга! Лира – бер балагына, мин икенчесенә ябыштык. Ак күлмәген дә юарга кирәк әле! Кәстрүлдә аш кайный. Радик безгә бәрәңге әрчеп бирде.

– Волейбол уйныйбыз, Чәчкә, яме? – ди.

– Ә эшләр?

– Ә мин эшең беткәнче көтәрмен!

...Кичкә таба клубка җыена башладык. Өстәл тирәсендә мәш киләләр: берсе – күлмәк, икенчесе чалбар үтүкли, косметичкаларны актаралар. Тимурның гитарасын күтәреп, авыз эчемнән генә җырлап, клубка йөгердем: «Озын юллар кыска тоела... Тара-тара, тарататам...» Нурия белән миңа шул җырны җырларга куштылар. «Кәефне күтәреп җибәрә!» – диделәр. Башкалар килеп җиткәнче, баянга кушылып, кат-кат кабатлап карадык. Радик музыка укытучысы ролендә: кайда нинди хәрәкәтләр ясарга, ничек сузарга, ничек

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

тәмамларга... Без, кызлар, сәхнәгә милли киемнәрдән чыгарга сөйләшкән идек. Яшел капрон күлмәк, зәңгәр бәрхет камзул, чигүле калфаклар кигәч, бер-беребезне таный алмый тордык хәтта! Ватык көзгегә карый-карый, чәчләремне төзәткәләдем. Күзгә бераз сөрмә дә тартып җибәрсәң?!

– Нурия, күзне буйыйммы?

Радик шул сүзләрне ишетеп, кашларын күтәреп миңа карады. Сизеп торам: ошатмады! Кырыс күренде хәтта! Югалып калдым. Ә ул бераз елмайгандай итте дә:

– Йә инде, күзләрең болай да матур ич! – дип ычкындырды! – Шулай бит, Нурия? – дип тә өстәп куйды. Бер аның гына фикере түгел, янәсе. Ярар соң, буямам. Сезгә шулай ошый икән...

Сәхнәгә чыгып тезелдек. Дулкынланабыз!

– Сез кайдан дип сорасагыз – / Без – Казаннан, Иделдән...

Фирүзәнең матур яңгыравыклы тавышы бөтен залны әсир итте. Үзе дә күзнең явын алырлык! Озын ак күлмәге зифа сынын тагын да нәфисләндерә, сөрмәле күзләреннән нур сирпелә.

– Урамнары ак ташлы, / Җырлый Сәйдәш, Такташны!..

Алик бөтен залга елмаеп, дәвам итте. Айсылу үз шигырьләрен укырга чыкты. Лира биюче инде! Зөфәр җырлады. Шәп бара, барысы да шәп! Алкышлар! Безне хәтта Казаннан килгән артистлар дип атадылар!

Миннән дә бәхетлерәк берәрсе булды микән шул минутларда?!

1 июль, Уразай. Егетләр торганчы (алар озак йоклый!), без, гадәттәгечә, китәргә җыенып беттек. Бер эндәштек, ике, өч...

Әгәр һаман киреләнсәләр, уяту күренеше безнең өчен кызыклы тәмамлана: чиләк белән салкын суны «гөрс!» өсләренә! Сикереп тә торалар, безне куа да башлыйлар! Менә шундый физзарядка. Тик Радик кына салкын суларга исе китмәс кеше булды. Иң соңыннан ул кузгала.

Колхозның әрҗәле машинасы безне Уразайга алып китте. Иң шатланганыбыз шул булды: авылда ашханә бар! Йөрибез авыл урамы буйлап. Клуб янында «Казан дәүләт университеты студентларының зур концерты» дигән белдерү эленеп тора. Без юри белдерү тактасы яныннан кат-кат урыйбыз. Шуңа карап узу ничектер бик рәхәт иде. Ә кич күрше авыл Янбайда чыгыш ясаячакбыз. Алырга килгән машинага төялештек. Радик баянын алды: «Нинди көйне уйныйм, әйт тизрәк!» – ди миңа. Елмаеп кына куйдым. Ул «Әй, ямьле син, Минзәләм ягы»н уйный башлады.

...Бөтен хисләремне кушып, дулкынланып, концертта үзем язган лирик парчаны укыдым. Юк, әллә нинди сихри бер дөньяда йөздем! Мәктәп, укытучы апа, чыгарылыш класс укучысы хисләре... Тимур гитара кылларына чирткәләп, фон биреп торды. Ул музыка аша яфраклар шыбырдашуы, торналар җыры ишетелгәндәй булды. Сөйләп бетергәч, йөгереп сәхнә артына чыктым да учым белән йөземне капладым. Ошаттылар шикелле. Иң беренче булып Радик: «От-лич-но!» – дип мактады. Аннары Фәнисә апа, калганнар...

2 июль. Нурия белән Әбрәр бабайларга киттек. Түбәтәен кыңгыр салып, капка төбендә уйланып утыра иде ул. Әллә кайчангы танышлары кебек, ачык итеп исәнләштек. Ул, безне танырга тырышып, кулын каш өстенә куеп, бер тын карап торды. «Ару әле, балалар. Күзем дә күрмәй. Кем кызлары дип әйтсәм дә...» – дип сөйләнде. Казаннан ук икәнебезне белгәч, бөтенләй җанланып китте. «Хуш...» – дип тамагын кырып куйды. Нишләп йөрүебезне аңлаттык. Күпне күргән сугыш ветеранының җырын тиз-тиз язып алдым.

...Кайтуыбызга Лира чәй әзерләп көтә иде. Зифа буйлы, кара чәчле, зәңгәр күзле. Карап кына тормалы бер чибәр. Ак борчаклар төшкән күлмәге ничек килешә! Актрисалар сыман ул. Бездән зуррак, мәктәптә укытып килгән. Тәмле телле. Җайлап сөйләшә.

– Радик белән сезне сыйларга булдык!

«Радик белән?!» Шундук кәефем төште. «Урманга бардык!.. Күрәсезме, нинди кызыл җиләкләр җыйдык! Әйдә, матурым, чәй ясый тор!» – дигән сөенечле тавыш белән Радикка эндәшүе исә бөтенләй һуштан яздырды. «Матурым?!» Әнә нинди дуслар икән! Тик Радик кына нигәдер шат күренмәде... Әллә нәрсә булды миңа. Тиктомалдан елыйсым килә. Башкалар җиләк белән чәй эчкәндә, мин сиздерми генә ишегалдына чыгып шылдым. Юк, берәү сизде шулай да. Радикның күз карашын тойдым. Артымнан чыгып та җитте: «Җиләктән авыз итмәдең бит, Чәчкә... Сыйлыйм инде үзеңне», – дип, кызыл тәлгәшләрне сузды. Алмаска иткән идем, бала-чаганы көйләгән кебек: «Бер генә кап, әһ, тәмле! – дип, иреннәремә үк китерде. – Нәрсә булды сиңа, аңламыйм... Ә-ә, белдем нишләргә икәнен! Әйдә, су коенырга киттек, Чәчкә! Тиз, тиз!» – дип, үпкәләремне таратырга тырышты. Ул педта укый бит. Бала-чаганы ничек җайларга икәнен белә. Җыенып чыкмый кала аламмы соң! Башкалар күптән суга чумарга әзер икән инде. Әллә нинди киртәләр аша сикереп, шайтан таякларына кадалып, юлда ромашкалар өзгәләп, су буена ашыктык.

...Босоножкаларымны кулга тотып, чылатмыйм дип, клеш итәкләремне бераз күтәреп, суга кереп карадым. Җылы! Җил дулкыннарны йөгертте, чәчләрне тузгытты, итәгемне күтәреп шаярды, ромашкаларымны йолыккалады. «Ак чәчәкләр белән каршы алырмын», дип җырлап, көлә-көлә, комны юып уйнаган дулкыннар буйлап йөгердем, «ярата-яратмый» дип, чәчәк таҗларын суга ташлый бардым.

– Җитәр инде, Мадъяров! Бер Гөлчәчәккә артыграк түгелме?!

Аликның шул сүзләренә борылып карасам, ни күрим: Радик фотоаппараты белән һәр хәрәкәтемне, елмаюларымны кадрга эләктерә бара! Аңа, «кирәкми», дип, бармак янадым. «Оригинально!» – диде дә тагын төшереп алды.

(Дәвамы бар.)



ЗӘЙНИЕВ Илгиз

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты.

Өйләнгән, ике бала атасы

Карьера: танылган драматург, режиссер, Г. Камал театры артисты.

Тормыш шигаре: «Эт өрә – бүре йөри тора...»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Без арттык әле!..

Күптән түгел улыбыз Хәйдәр туды. Кызыбыз Гәүһәргә иптәш, энекәш булды. Апа кеше ул хәзер! Безне дә хәзер чын гаилә дип санарга мөмкин. Бер генә балалы гаилә әле тулы түгел ул дип әйтәләр, дөрес икән. Кечкенә улыбыздан башка моңарчы ничек яшәгәнбездер, белмим. Тиздән, Алла боерса, ишегалдындагы карны көрәргә кеше булачак, дип сөенеп йөрибез менә.


Эшеңнең кирәклеген тою – бәхет

Камал театры яңа гына Мәскәү, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә гастрольләрдә булып кайтты. Кая гына барсак та, спектакльләр аншлаг белән үтте. Безне тулы заллар белән каршы алдылар, көчле алкышлар белән озатып калдылар. Бу минем өчен бик сөенечле күренеш. Татар халкы үзенең театрына, сәнгатенә битараф түгел икән, димәк, без юкка хезмәт итмибез!

Без ялгыз түгел!

Астрофизиклар соңгы вакытта тереклек булырга мөмкин, ягъни кеше яши алырдай тагын 60 планета барлыгын хәбәр иттеләр. Алар Кояш системасыннан бигүк ерак та түгел икән. Әле җитмәсә, Бөекбритания астрофизиклары теге 60 планета янына тагын 54 не өстәп куйганнар. Аларда су да, һава да бар ди. Димәк, Җиһанда Җир кешеләре өмет белән багардай 114 планета бар дигән сүз. Хәзер менә ул планеталарга илтеп җиткерердәй тизлеккә ия очкыч уйлап табасы гына кала. Чөнки иң якын планетага 40 елда барып җитү өчен генә дә ул очкычның тизлеге яктылык тизлегенә бәрабәр булырга тиеш.

сөендерде









көендерде

сөендерде










көендерде

сөендерде







көендерде

Берәү килә, берәү китә...

Әбиемне мәңгелек йортына озаттык... Яшьли тол калып, өч улын аякка бастырган, соңрак безне – дүрт оныгын үз балаларыдай тәрбияләгән әбиебез Разия Җамалетдин кызы 80 яше туларга бер ай кала арабыздан китеп барды. Әбине күпме генә яратсак та, бу дөньяда аңа җитәрлек дәрәҗәдә кадер-хөрмәт күрсәтә алмадык кебек. Аның безгә кылган яхшылыкларын санап бетерерлек түгел. Аллаһы Тәгалә әбиебезгә җәннәт ишекләрен ачсын иде!

Иртәгәсе көнгә ышаныч какшый...

Соңгы арада Россиядә бер-бер артлы төрле банклар ябылу турында хәбәрләр килеп тора. Бу үз чиратында илдәге икътисадый тотрыксызлыкка ишарә. Меңләгән кешеләрнең шул сәбәпле зыян күрүе кызганыч. Россия икътисады элек-электән шулай: алга бер адым ясаса, икене артка чигенә. Әлеге өлкәдә, кызганыч, һаман да бернинди уңай традицияләр һәм продуктив механизмнар булдырылмаган...

Дельфиннар ни әйтергә тели?

Яңа Зеландиядә 400 ләп дельфин үз-үзләрен яр читенә чыгарып ташлады. Озак та үтмәде, андыйларның саны тагын 200 гә артты. Табигатьтә җан ияләренең үз-үзләрен үтерүгә баруы үтә дә сирәк очрый торган хәл. Кайсыдыр чыганаклар бу фаҗигане суасты көймәләренең геолокациясе белән бәйләде; икенчеләре акулалар һөҗүменнән качулары, дип шәрехләде. Яңадан океанга җибәргән хәлдә дә алар кире ярга ташлана, диделәр. Һәрхәлдә, сәбәбе әлегәчә төгәл билгеле түгел, шуңа күрә ярдәм итеп тә булмый.

PRESSA.RU


Фото интернеттан алынды

КЫРЫКТАН СОҢ

КЕМДЕР ӘЙТЕР, БУ ЯШЬТӘ КЕШЕЛӘР ИНДЕ БАЛАЛАРЫН ҮСТЕРЕП БЕТЕРЕП, ҮЗЛӘРЕ ӨЧЕН ЯШИ БАШЛЫЙЛАР, ДИП. ШУЛАЙДЫР, АНДЫЙЛАР ДА БАРДЫР. Ә МЕНӘ МИН 40 ТАН СОҢ ЯШИ ГЕНӘ БАШЛАДЫМ ӘЛЕ.

Университет тәмамлаганда әти җитди авырып китте дә, мин эш урынын аңа якынрак җирдән сайларга мәҗбүр булдым. Энекәшем әле бик кечкенә, ә сеңелләрем бер-бер артлы кияүгә китте: әтине карауны шулай итеп үз өстемә алырга туры килде. Тәүлеккә өч тапкыр әтигә укол ясаудан һәм эштән генә торган бу елларда шәхси тормышымны җайлау, гаилә кору турында уйларга вакыт та, теләк тә булмады: барыбер әтине ташлап китә алмас идем. Бу чорның иң шатлыклы көннәре сеңелләремнең балалары туу, аларны карарга булышу булды. Туганнарым сабыйларын авылга кайтаргач, минем өчен иң бәхетле көннәр башлана. Тик үсә барган саен, бу сабыйларның минеке булмаячакларын ачыграк аңлый барам. Ә яшь атлый, инде 30 ның аръягына чыкканга да байтак. Үз тиңнәрем инде күптән гаилә корды, балалары мәктәптә укый. Ә мин һаман ялгыз...

Сәламәтлек белән проблемалар башланды. Инде яр табу турында уйламыйм, бала алып кайтырга өлгерәсе иде. Сеңелләрем дә шуңа өнди. Әти-әни дә мине аңлар дип уйлыйм. Ләкин баланы үзең генә алып кайтып булмый бит... Ниһаять, тәвәккәлләдем. Тулы медицина тикшерүе үттем, табиблар: «Шунсыз бала таба алмаячаксың», – дигәч, планлы операциягә яттым.

Иң элек ният кирәк, ниятләгәч, Ходай ярдәм итми калмый, диләр. Ялгыз әни исемен күтәрергә дә ризалашып йөргән көннәрдә, хастаханәдән чыгып ике ай үткәч, булачак ирем белән таныштым. 40 яшем тулган атнада никахыбыз булды.

Балага узу бәхете көттеребрәк килде. Бик җиңел кичердем йөклелек чорын. Иртә белән бераз күңел болганучы һәм тынчу автобусларда йөрергә яратмавымны санамаганда, токсикоз кыенлыкларын да сизмәдем. Эшемдә йөгерә-йөгерә йөрим. Беркем гаҗәп-

ләнмәде шулай соңга калып әни булырга җыенуыма, чөнки үз яшемне бирмиләр дә иде.

Атна саен табибка күренү өчен чират тору, төрледән-төрле анализлар бирү генә ялыктырды. Яшьләргә караганда, өлкән яшьтә әни булырга җыенучыларга анализларны күбрәк бирергә туры килә, чөнки яшь барган саен, авыру бала туу куркынычы зуррак. Бу чорда акушер-гинекологтан күп нәрсә тора. Табибың яхшы булса, сәламәт бала табу шансың күбрәк, дип саныйм. Рәхмәт табибларга, берсеннән дә «картаеп табучы» дигән кимсетүле сүзләр ишетмәдем, хәер, тирә-юньдәгеләрдән дә кырын караш сизмәдем. Үзем дә нәрсә соралса, шуны үтәдем.

Анализларның иң куркынычы – йөклелекнең 19-20 нче атнасында уздырылучы кордоцентез дигәне булды. Карындагы баланың кызылча, токсоплазмоз һәм Даун синдромы кебек куркыныч авыруларын ачыклаучы бу тест озын инә белән яралгының кендек канын алудан гыйбарәт. 100 очракның берсендә бала төшү белән тәмамланучы бу анализга ике мәртәбә барырга туры килде – беренчесендә лабораториядә ут сүнеп, анализ ясый алмаганнар булып чыкты. УЗИ ярдәмендә башкарылучы бу процедураны ясаганда, табибларның: «Кара-кара, коты очты баланың, ашказаны астына ук барып посты», – дип сөйләшкәннәре истә. Алла саклады, исән чыктык. Анализларым да яхшы иде.

...Йөклелегемнең әтиемнең хәле көннән-көн авырлаша барган фонда узуын, «инде дәвалау мөмкин түгел», дип, табиблардан хөкем карары кебек яңгыраган сүзләрдән соң чак баламны югалтмавымны, акушер-гинекологтан баланы тизрәк таптыруын, ярып алуын сорап ялваруымны, шулай әти янына ашкынуымны тасвирлап тормыйм – бу бик авыр кичерешләр...

Алмагачлар чәчәк аткан, дөнья яз исенә тулган искиткеч матур көнне – майның 15 ендә улым туды. Баламны ярып алсалар да, эпидураль анестезия белән ясагач, аңымда идем – палатага чыгаруга улым тууын әнигә хәбәр иттем, бик авыр хәлдә булса да, әтигә дә әйтергә куштым. Бераздан кабат шалтыраттым. «Әйттем, җиңел сулап куйды, башын какты да, йоклап китте», – диде ул. Шул йокыдан әти уянмаган инде, мәңгелеккә күчкән. Көтеп алган зур шатлык белән күтәрә алмаслык кайгы бер көнне ишелеп төште иңнәремә. Берсен бирде, икенчесен алды...

Улым булмаса, белмим, ничек күтәрер идем бу хәсрәтне?! Әти кызы идем бит. Әнигә сөйли алмаганнарны да әти белән уртаклаша идем. Ул да: «Үземнең бер кызымны кешенең сигез улына да алмаштырмас идем», – дип кабатлый иде. Шулай да яраткан кызының әни булу бәхетен белеп китте, көтеп җиткерде бу шатлыгымны, дип юанып яшим.

...Аллаһы Тәгалә сораганымны бирде – сау-сәламәт, зирәк, сөйкемле, йомшак күңелле, рәхимле җанның әнисе булдым 41 яшемдә. Балам белән үткәргән һәр мизгелем – чиксез бәхет ул. 3 яшендә хәреф танырга, 4 яшендә иҗек җыеп укырга өйрәнде. Азаплый икән баласын, димәгез, үзе шундый кызыксынучан ул. Һәм бик максатчан. Теләгәнен эшләмичә калмый. Үземдә булмаган күп сыйфатларны күрәм аңарда: бүгенге эшне иртәгә калдырмау (мин «иртә кичтән хәерлерәк» дигән сәбәп табарга яратам), сабырлык (минем каударлыгыма капма-каршы), уйлап эшләү (хисләргә бирелеп, уйланмаган адымнар ясау гадәтем бар), һәр эшне системалаштырырга ярату (минем кебек илһам килгәндә генә түгел) һәм башкалар. Беренче көннән якын дустыма, хәтта киңәшчемә дә әйләнде балам. Каян белә бу моның кадәр, дип аптырап калган мизгелләрем күп була. Үземнең аның яшендәге вакытымны искә төшерәм дә, бик баналь яңгыраса да, хәзерге балалар, чыннан да, югарырак үсешле, индиго-лар дигән фикерем ныгый бара.

Шулай бер-беребезне тәрбияли-тәрбияли, быел 7 яшебезне тутырырга җыенабыз, Алла теләсә.

Әни булырга соң түгел әле.

Бала булгач, мин олы яшьтә, кәефем юк, дип утыра алмыйсың – аның ышанычын акларга кирәк. Авырып ятарга да вакыт юк. 48 яшьтә тимераякка бастырды ул мине, утыз ел дәвамында (мәктәп тәмамлаганнан бирле!) чаңгы шуу турында уйлап та карамаган әнисен һәр атна ялын ашкынып көтеп алып, чаңгы юлына чыгучыга әйләндерде. Әле күптән түгел генә шахматның бер фигурасын да танымасам, бүген инде икәүләп шахмат биремнәре чишәбез. Бассейнга язылырга өнди. Килешергә туры килер кебек. Тагын футбол, каратэ көтә әле безне. Картаюның мине куып тотарга шанслары кими бара!

Кечкенә чагында: «Әни, сиңа ничә яшь?» – дип бик аптыраткач, «кырык» дигән идем. Шуннан бирле ул миңа 40 яшь дип саный. Кайнанам быелтыр: «Әниеңә инде 47 тулды», – дип әйткәч, улым бөтен җитдилеге белән: «Юк, алай түгел, әниләр картаймый», – дип җавап бирде. «Әнием, син минем өчен иң яхшы, иң матур әни, мин башканы теләмәс идем. Син минем молодец!» – дип торганда, картаеп буламыни?!


Мин әни булгач, өч елдан соң сеңлем дәү әни булды. Үзе турында онытып, оныгы өчен яшәп яткан көннәре, чөнки яшьләрнең әле киного барасылары килә, әле тау чаңгысына чыгып китәләр, әле кичке клубны тансыклаганнар... Шулай, уртак мавыгулар белән яшибез туганым белән – кем бала үстерә, кем онык.

Бөтен барлыгын балага багышлаган бу, дип уйласагыз, бик ялгышасыз – дәрәҗәле, кызыклы яраткан эшем бар, театр-концертларга да йөрергә өлгерәм, китап уку рәхәтен дә онытмадым. Улым өлгер булырга, вакытны юкка-барга исраф итмәскә өйрәтте.

Ходайга бик зур рәхмәтлемен – Җир йөзендәге иң зур бәхетне – әни булу бәхетен насыйп итте. Инде улыбызны үзебезгә үстерергә язсын да, ул гомер буе шатлыгыбыз, горурлыгыбыз, таянычыбыз булсын, дип кенә сорыйм.

Гүзәл НАСЫЙРОВА

PRESSA.RU



КАФ ТАУ АРТЫНДА

ЮЛ ЧАТЫНА БАСАБЫЗ ДА, СВЕТОФОРНЫҢ ЯШЕЛ УТЫ КАЙСЫ ЯККА АЛДАН КАБЫНА, ШУЛ ЯККА КУЗГАЛАБЫЗ!

Рушания МИҢНУЛЛИНА

«Светофорның яшел уты янган якка китәбез», – дисәм дә, алай ук булмады, билгеле. Карелиядә – салкын, Абхазиядә булган бар... «Грузия матур инде ул, әйеме?» – дим, нәрсә әйтерләр икән дип куркып кына. Ирем, улым һәм кызым минем шул сүземне генә көткәннәрмени! Өчәүләшеп интернеттан карап, маршрут та төзи башладылар. Тә-әк, сәгатенә 100 км тизлектә барсагыз, 30 сәгатьтән Россия–Грузия чигенә барып җитәсез, ди безгә навигатор. Булмаганны! Грузия кайда да, Казан кайда! Ярар, ни булса шул булыр, җыендык та, ике тәүлеклек ризык алып, юлга кузгалдык.

Волгоград артта калуга, ачык тәрәзәдән дала җиле керә башлады, һава эсселәнде. Димәк, корылыгы, эсселеге белән аерылып торган калмык даласына борылганбыз.

Гаиләдә машина йөртүчеләр өчәү без, җайлы – берберебезне алмаштырып, ял итеп барабыз. Машинабыз да 8 урынлы минивэн, иркен. Ул безнең кечкенә генә өебез кебек. 20 литр эчә торган суыбыз да, юлда туктап аш пешерергә казан да, палатка да бар.

Ирем белән улым һаман навигатор белән мәш килә: «Карале, чынлап та, 30 сәгатьтән Грузия чигенә җитәбез бит!» – диешәләр. «Ярар, барыйк, күрик», – дим. Ул җирләр Каф тавы артында кебек бит әле!

Менә каршыбызда бер-берсенә сыенып, бер-берсен кочаклап дигәндәй утырган берничә тау күренде. Пятигорск! Биштау! Әйе, бик матур җирдә, биш тау итәгендә, яшеллеккә күмелеп, кояшның тау артына киткәндә сузылып калган нурларына коенып утыра. Оҗмах шушыдыр, мөгаен... Шул вакыт кояш батты да,



■ Безнең эрага кадәр I гасырда барлыкка килгән, Грузиянең IV гасырга кадәр баш каласы булган Мцхети изге җир санала.

■ 2384 метр биеклектә – Атаклы сынчы Церетели ясаган Дуслык аркасы.





Автор фотолары

тирә-юнь караңгылыкка чумды, һәм әле бер, әле икенче почмакта җемелдәшеп урам утлары кабына башлады... Ә без чиккә якынлашабыз! Дүшәмбе көн кичке алтыда кузгалган идек, нәкъ 30 сәгать дигәндә, төнге уннарда Хәрби грузин юлына килеп җиттек.

XIX гасыр ахырында Осетия–Россия хәрби крепосте буларак төзелгән Владикавказ белән Тбилиси шәһәрләрен тоташтыручы тау юлының озынлыгы 208 чакрым. Ул Кавказ тавы сырты буйлап бара. Башта 10 чакрымнар Дарьял тарлавыгыннан үтәсең. Таудан ташлар төшү хәтәрлеге зур, диләр. Әле без килгәнче юлга кыя-тау ишелеп, юл ике атнага ябылган булган. Хәзер ачылган икән. Әмма, барыбер, төнлә анда кертмиләр. Яктыра башлагач, махсус приборлар белән тикшереп, тау ишелү куркынычы юклыгына инангач кына, чикне ачалар һәм бернично чакрымга сузылган машиналар чираты акрын гына кузгала башлый. Тарлавык тар, каршыңа килгән йөк төягән фура инде сыта, инде беттем, дигәндә, әкрен генә, бер-береңә юл бирә-бирә, шуышып диярлек, узып китәсең...

Шушылай ун чакрымнар «шуышкач», уң ягыбызда ап-ак тау күренде. Казбек! Биеклеге 5 чакрымлап күкләргә ашкан мәгърур тау! Күз алдына китерегез: без аста, ике тау арасында, караңгы, кояш әле безне күрми, ә менә аның нурлары Казбек тавының ак карларын җемелдәтеп, балкытып тора. Нинди матур күренеш! Инде хыялланудан туктап, күзләрегезне ачсагыз да була, чөнки Кавказның бормалы-бормалы юлларында бик игътибарлы булырга кирәк: ул бер төшә, бер үргә күтәрелә. Температура кисәк кенә 16 градуска төште! Дөнья океаны тигезлеге белән үлчәгәндә, 2,5 чакрым өстә икәнбез ләбаса, шуңа күрә басым безнең башларны кыса – колак шаулый.

Тауның ике ягында авыллар урнашкан, аста сарык көтүләре, печән чүмәләләре. Тукта, ни бу? Бормалы-сырмалы авыр юл кисәк кенә 90 градуска борылган урында, юл уртасында сыер күшәп ята! Бераз арырак, инде болай да тараеп беткән юл чатында бозавы басып тора. Аста упкын, тар юл, бозау ни уңга, ни сулга китми... Хуҗалары иртән чыгарып җибәрә дә кичкә хәтле оныта икән монда сыерларны. Ашап-йөреп туйгач, сыер танасын, бозавын ияртеп, өенә кайтып керә. Кыска аяклы бу тау сыерларының сөте бик тәмле. Әйтүләренә караганда, иртән өстенә утырган каймагы 10 см тирәсе була икән.

Монда син – патша, синең яныңда официант бөтерелеп кенә йөри...

Шулвакыт кызым: «Әнием, карале, аста зур күз!» – кычкырып җибәрде. Ике тау арасында – фирүзә төсендәге күл җәйрәп ята. Бу табигать могҗизасын карарга дип әллә никадәр машина туктаган. Без дә Грузия җиренә шушы төштә аяк басарга булдык. Әлбәттә, алдарак та тукталырга була иде, чөнки Казбектан ерак түгел Түбән Ларс, Казбеги станицалары калды, анда кунакханәләр, кафе-ресторааннар да күп, ял итү урыннары ясалган. Теләгән кеше махсус машиналарда Казбекка да менә ала (әлбәттә, Казбекның үзенә түгел, аңа якынрак тауларга барып, фотога төшерергә була). Альпинистлар да шушы авылларда туктала икән.

Юлыбызны дәвам итәбез. Таулар әле уңда, әле сулда кала, аста упкын, кайчак тау икегә ярылган кебек була да без шулар арасына кереп китәбез.

...Ниһаять, Тбилисига да килеп җиттек. Биредә безгә бар нәрсә дә шундый кызык! Машиналарның бер-берсенә юл сабышмавы дигән нәрсә бөтенләй юк бугай. Ничә көнгә нибары бер авария күрдек, анысы да төнлә белән, тар юлда иде. Ә полиция – адым саен! Юк, алар куак артында канун бозучыларны сагалап утырмый. Киресенчә, рульдәгеләргә булышырга дип, басканнар. Берсендә юл сорап торуыбызны күреп (номерлар чит мәмләкәтнеке бит!), яныбызга туктап, аңлатып, кат-кат саубуллашып, күңелле юллар теләп озатып калдылар.

Тбилисида безне кочак җәеп каршы алучы юк иде, билгеле. Әмма бер танышларның танышлары Давид дигән кешенең телефонын биргән иде. Уңайсызланып кына шалтыраткан идек, ул исә безне иң якын кунакла-

PRESSA.RU



■ Ике тау арасында, безнең белән чик буеннан ук килгән тиз агышлы тау елгасының бер ягында фирүзә төсендәге күл җәйрәп ята. Аның матурлыгы! Чыннан да, нәкъ Язгөл әйткәнчә, мөлдерәп торган күзгә охшаган.

■ Тирә-як уч төбендәгедәй күренгән бер урында XVII гасырдан сакланган Ананури замогы тора. Тау кенәзләре шәһәрен Дарьял тарлавыгы ягыннан килгән дошманнан саклар өчен салынган таш пулат бу. Янындагы манара XIII гасырга карый, диделәр.



ры кебек каршы алды, фатир белешеп, шунда урнаштырды (юлга чыгып киткәндә кайда тукталасыбызны бөтенләй белми идек). Безгә кайсы җирләрне карарга кирәклеген әйтеп, кичен күрешергә сүз куешып, үз эшләре белән чыгып китте.

Табын артында һәр кешенең үз роле, үз урыны — биредә беркем тыз-быз чабып йөрми.

Ә без кафега барып ашап алырга булдык. Бу хакта иркенләп утырып сөйләргә кирәк. Чөнки Кавказ халыкларында ашау ул – культ. Тиз-тиз генә капкалап алу, аяк өсте тамак ялгау аларда бөтенләй юк! Кафемы ул, ресторанмы, барыбер – сиңа официант килә, заказны ала, ризык сиңа тәгаенләп әзерләнә, матур итеп бизәлә, һәрбер ризыкның исеме, ничек эшләнгәне әйтелә. Башта аш алырга булдык, ике көн бит инде кайнар шулпа күргән юк. Аның янына грузин яшелчәләре китерергә булдылар. Ничек инде, Грузия булсын да, хачапури ашама! Ярар, чәй эчәргә анысы да кирәк булыр. Аш, салат, чәйгә сырлы икмәк... Җитәрме икән? Әйдә, второй дигәннәрен дә китерсеннәр әле. Берзаман ташый башлады безгә официант. Зу-ур тәлинкәгә тутырып шулпа, әнинең бәлеш сала торган табасы хәтле тәлинкәдә салат, аннан да зуррагында – итле ризык, һәм ахырдан дүртебезгә дүрт хачапури! (Шикләнгән идем аны официант бик аптырап кына заказ алганда.) Безгә берничә көнгә җитәрлек ризык лабаса бу! Моның кадәр зур савытларда китерерләр дип кем белгән?! Ашның яртысын, салатның тәмлерәк җирләрен, тавыкның гарнирдан башка үзен генә ашадык та, хачапурига карап утыра башладык...

Тбилисида 1,5 миллион кеше яши, шәһәргә нигез V гасырда салына. Башта Грузиянең баш каласы безнең эраның I гасырына кадәр легендар патша Мцхетос салдырган Мцхети шәһәре була, ул Тбилисидан төньяк-көнбатыштарак урнашкан. Борынгы замокка шәһәр үзәгеннән экскурсия дә оештыралар. Шул чорда яшәгән патшалар хәзерге Тбилиси урнашкан, элек куе урманнар үсеп утырган бу тирәләргәауга чыгарга яраткан. Бер көнне атылган фазан суга төшә һәм пешеп чыга. Шунда бу тирәләрдә термаль су чыганаклары барлыгы беленә һәм башкаланы бу урынга күчерергә карар кылына. «Мунчалар районы» дип аталган җирдә гөмбәз кебек эшләнгән мунчалар бихисап, анда җирле халык та, туристлар да мунча керергә, кайнар чыганакларда дәваланырга, арган мускулларын иркәләп ятарга ярата. Ә без юлыбызны дәвам итәбез һәм, Давид киңәше белән, Грузиянең иң биек ноктасына – 770 метрлы Мтацминда тавына юл тотабыз. Бирегә безне трамвайлар – 1900 елда Бельгия инженерлары төзегән фуникулерлар алып менә.


Икенче көнне безнең белән танышырга Давидның бөтен гаиләсе килгән иде – әнисе, апасы, энесе. Алар өчен без иң кадерле кунак икән! Гомумән, урамда да, диңгез буенда да безгә шундый игътибарлы булдылар, таксистмы ул, кибеттә сатучымы, барысын җиренә җиткереп аңлаталар, адашсаң, өеңә хәтле китереп куярга мөмкиннәр. Таксист Георгий әйтмешли, кунак – Аллаһы бүләге ул, аны кадерләргә кирәк. Шулай булды да! Давидның апасы Кэтиван диңгез буенда безнең өчен фатир белешкән, Кутаиси шәһәрендә безне мәгарәләрдә йөртергә дип ике туган абыйсы белән сөйләшкән, грузин шәраблары сатучы кибеттә ташламаларны килештергән. Көне буе шәһәрдә сәяхәттә йөрдек ул көнне. Иртән тагын ерак юлга чыгып киттек – безне Төркия чигендә урнашкан Батуми шәһәре көтә: диңгездә коенасыбыз, кояшта кызынасыбыз килә. Диңгез ярын берничә төргә бүләргә мөмкин. Беренчесе, Уреки шәһәрчеге. Әлбәттә, эвкалипт аллеялары, чиста комлык бөтен курортларда да бар. Ә биредәге комлыкка какшаган нервыларны һәм буын авыруларын дәваларга киләләр. Ул кара төстә, магнитка бай. Мондый дәвалау үзлегенә ия булган комлык Кара диңгез буенда Болгариядә һәм Грузиядә генә, диләр. Икенче диңгез яры – ул, әлбәттә, Батуми шәһәре.

Шәһәр пляжында кеше күп икән, тавыш, чыр-чу, икенче көнне без су коенырга Батумидан арырак ур-



■ Тынычлык күпере; пыяладан төзелгән, тыштан граммофонны хәтерләткән музыка һәм драма театры; чәчәк таҗларына охшаш Юстиция министрлыгы бинасы.

■ Юл буендагы бер бәләкәй генә мәчетнең эче шундый купшы итеп бизәлгән!



нашкан Сарпи шәһәрчегенә киттек. Суы чиста, халкы аз, тауда берсе өстенә икенчесе салынган отельләр... Һәм иң кызыгы: бер чакрымнан – Төркия! Бер көнне чит ил паспортларын алдык та, чикне узып, Төркиягә киттек! Маршрут автобуслары йөреп тора. Грузия халкы Төркиягә эшкә йөри икән – чикләвек, зәйтүн җыярга. Чыкканда бик тиз тотсак та, Грузиягә кире кергәндә бераз көтәргә туры килде, чөнки бер автобус эшчеләр өйләренә кайта иде. Ул арада чик буенда урнашкан мәчеткә дә кереп чыктык. Һәм андагы затлылыкка шаккаттык! Бу якларда барлык мәчетләр дә шундый затлы, бай эшләнгән икән. Мәчеткә шулай ук аджарлар да килә. Батуми – Аджар иленең баш каласы санала, урта гасырларда алар ислам динен кабул иткән. Йомшак климаты, диңгезе, эвкалипт агачлары, җиләк-җимеш бакчалары бу тирәләрне оҗмахка тиңли. Басып алучыларның нәфесе яхшы җирләргә кызыга, әлбәттә. II–III гасырда римлылар, соңрак византиялеләр, госманлылар хуҗа була аджар биләмәләренә.

Инде без ял итеп арыдык бугай, күз алдында кыздырган балыклары да тәмле, әмма авылда яңа бәрәңге өлгергән ди анда! Әле Тбилисига кадәр ерак, юл буенда Иосиф Джугашвилиның туган шәһәре Гори кала, аның нигезен дә күреп китәсе килә. Кич кенә калага килеп кердек. Кайтышлый Кэтиван үзләренә тукталырга кушкан иде. Аларга керсәк, йа Хода! Бу мул табын безнең хөрмәткә әзерләнгән икән! Кэтиның дүрт кызы бар, алар матур итеп киенгән (кадерле кунак көтәләр!), Кэтиның әнисе, гаиләләре белән абыйлары килгән. Менә, ичмасам, халык бу! Без инде шунда белдек чын тамаданың кем, нинди булырга тиешлеген – ул, әлбәттә, иң олы хуҗа, шушы табынның иң дәрәҗәле кешесе, аксакал – Давид. Хуҗабикә дә кухня ягында түгел, түрдә, бар әйберне табынга чыгардылар, акрын гына, үзең теләгән ризыкны ашап, көлешә-көлешә, чын грузин шәрабын авыз итә-итә матур итеп утыра беләләр. Табын дигәнем 5 сәгатькә сузылган икән! Ни арада төн җиткән?! Акыллы хуҗабикәнең барысы да җайланган икән инде – без Кэтиванның әнисендә кунабыз, иртән алар безне шәһәр күрсәтергә алып чыгачаклар икән.


Кэтиның өе Мтацминда тавы каршындагы икенче бер биек ноктага урнашкан. Алар яши торган квартал, гомумән, борынгы шәһәр уртасы булып чыкты. Биредә бер генә машина сыешлы тар урамнар.

Батумилылар «без җирнең нәкъ уртасында урнашкан», дип горурлана. Шаярталар, әлбәттә!

Иртәнге кояш нуры битне иркәли, ачык тәрәзәдән кошлар сайравы ишетелә, әллә нинди тәмле чәчәк исләре башны әйләндерә. Кэти безне кибетләргә, атаклы хәерчеләр базарына алып барасы икән. Яшелчә базарыннан тәмләткечләр, чикләвекләр җыйдык, подвалларга кереп, татып карый-карый дусларга дип 10-15 еллык шәраблар сайладык, тәмле шафталулар алдык...

Совет заманында бик шәп яшәгәннәр, өлкән буын сагынып сөйли. Мандарин, чикләвек, йөзем, анар өлгергәндә бигрәк сезне искә төшерәбез, диләр. Ә яшьләр инде заманча яши, күбесе рус телен белми диярлек. Рәсәйгә дошман булмасалар да, Европага йөз тоталар. Эшсезлек сизелә. Соңгы елларда, тынычлык урнашкач, туристлар кабат килә башлаган, әлбәттә, әмма моннан диңгез буе халкына гына табыш керә. Өлкән буын да, яшьләр дә гыйбадәтханәгә йөри, ураза тота, ә тау башларында, халык күзеннән еракта бик күп монастырьлар урнашкан. Үзләренең күршеләре мөселман аджарларга да хөрмәт белән карыйлар, без ислам динен тотуыбыз белән алар алдында тагын да бер башка күтәрелдек бугай әле.

Менә ялыбызның ун көне үтеп тә китте. Бу сәяхәтебез матур төш кебек кенә истә калды. Әмма безнең кебек кыска вакытка түгел, озаккарак барырга кирәктер. Иркенләп, грузиннар кебек ашыкмыйча, барысын да җиренә җиткереп, сокланып йөрергә.




Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

16+

ЯКЫН КЕШЕЛӘРДӘН ДӘ ЯКЫНРАК УЛ...



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Артур МИНҺАҖЕВ, җырчы,
Татарстанның атказанган артисты.
өйләнгән;
гаилә стажы – 17 ел;
ике бала атасы:
улы Данилга – 16 яшь,
кызы Диана 3 нче сыйныфта укый.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Хатын-кыз хәтта янымнан гына үтеп киткәндә дә мин һәрвакыт аның күзләренә игътибар итәм. (Күзләрдә – бөтен сорауларга да җавап бар, диләр, дөрес ул.) Аннан инде – чәчләренә. Миңа озын толымлы кызлар бик ошый, күңелемә, йөрәгемә бик якын андыйлар. Кигән киеме, буй-сыны да күзгә чалына, билгеле.

2 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Монда җавап бер генәдер – хыянәтне. Гомерлек яр итеп сайлаган хатын-кызны без бары үзебезгә тугры итеп кенә күрәбез. Ул минем балаларымның әнисе, ә әни кеше чиста булырга тиеш, дип уйлыйбыз.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Икенчеседер, мөгаен... Студиядән, эштән, йә гастрольдән арып өйгә кайтып керәсең. Өйдә сине хатының көткәнен, тиздән аны күрәчәгеңне белү шундый рәхәт. Бу җылылыкны мин хәтта ара ерак булганда да тоям. Аш пешкән, чәй кайнаган, өйдә җылылык, нурлылык...

Һәр кайтып керүемдә шулай булуын теләсәм дә, мин аңа «өйдә генә тор», дия алмыйм. Беренчедән, тормыш бик катлаулы хәзер – иртәгә безне ни көткәнен беребез дә белми: хатыным да аягында нык басып торырга тиеш. Икенчедән, хатын-кызның да күңеле бар: аралашу, үсү, күренү аңа да кирәк. Һичьюгы шул матур күлмәкләрен, туфлиләрен дөньяга алып чыгу өчен ул эшкә йөрергә тиеш.

Бүген иртән мин – кызыбызны, ул улыбызны укуга илтеп килдек. Лекцияләре соңрак башлана икән Казан дәүләт мәдәният университетында укыта ул. Кире кайтып, матур итеп бизәнде, чәчләрен ясады, тунын киеп, шарфларын урап чыгып китте. Артыннан хушбуй исе аңкып калды... Шундый матур, чибәр иде ул киткәндә! Сөенеп, яратып карап калдым артыннан. Эшен бик ярата ул, аның шулай эшкә бәйрәмгә баргандай ашкынып китүе миңа да шатлык. «Машинада карап кына йөр, барып җиткәч, телефонда күпме кирәк шуның кадәр сөйләшерсең, «смс»ларны аннары язарсың», – дип калдым. Телефоннан сөйләшергә ярата шул! Юк, гафу итәм мин аның бу гадәтен. Хатын-кыз бер-берсе белән аралашырга тиеш – һәр сөйләшүдән үзе өчен ниндидер яңалык ала бит ул.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Кайчак авыр көннәр була. Кайтасың өйгә, кәеф юк. Шунда хатының сак кына: «Нәрсәдер булдымы әллә?» – дип сорый. Башта әйтмәгән буласың. Аннан, ашап-эчеп алгач, тел чишелә. Барысын сөйләп бирәсең. Синең борчуың инде аңа да күчә... Һәм шул вакыт аңлыйсың: ә бит хатының сиңа якын кешеләрдән дә якынрак.

Бергә яшәгән еллар күбәйгән саен бер-береңә карата хөрмәт арта. Аны сүзсез дә аңларга, тоярга өйрәнәсең. Аңа яхшылык кына телисең, аны сакларга, кадерләргә тырышасың. Бу хис, минемчә, мәхәббәттән өстенрәк.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Хәтерлим! Йошкар-Олада сәнгать-мәдәният колледжын тәмамладым да, Казан мәдәният институтына укырга кердем. Хор бүлеген сайладым – теләгем хор дирижеры булу. Институт хорына 70 ләп кеше җыелдык. Җитәкчебез Марат Гомәр улы Яхъяев безне бер-беребез белән таныштыра. Чират миңа җитте. «Минһаҗев Артур, Марий Иленнән, Бәрәңге районыннан», – ди. Хорда басып торган җиремнән, башымны гына чыгарып, башкаларга күрендем. Үземә караган бүтән йөзләрне хәтерләмим, ә Луизаның ярты битен каплап торган зур күзлеге шунда ук истә калды. 1996 ел бу. Зур күзлек модада булган чак идеме икән соң? Әмма Луизаны мин моңарчы күргән идем инде. Хатыным моңа бик озак ышанмады. Йошкар-Олада 3 нче курста укыган чагым. Казаннан каникулга кайткан туганнан туган абыем бер фото күрсәтте: уртада

ул баскан, янында ике кыз. «Болар кемнәр?» – дим. «Берсе – Лениза, ә икенчесе – Луиза», – диде. «Луиза? Кара, нинди матур исем!» – дигән идем. Мин бу хакта Луизаның күзлекләрен күргән көнне түгел, соңрак искә төшердем әле... Укытучыбыз: «Луиза Петровна Чебарева. Хорның старостасы», – дип таныштырды аның белән. (Луизаның әтисе – мукшы, әнисе – татар.)

Без Луиза белән матур гына йөреп киттек. Ә 2000 нче елга керер алдыннан мин аңа тәкъдим ясадым. Бәйрәм алдыннан кибеткә барган идек. Казанда беренче супермаркет ачылган вакыт. Кибеттән чыксак, урамда мамык-мамык кар ява. Әкият кебек! «Әйдә, җәяү генә кайтабыз», – дим. Трамвай рельслары буйлап киттек икәү җитәкләшеп. Ут янган бер багана төбендә туктап, мин аны кочаклап алдым. Үбештек... «Мин сине бик яратам. Әйдә, минем хатыным бул», – дидем мин аңа шул вакыт. «Чынлап әйтүеңме?» – ди ул, аптырап. Мин аңа бу сүзне бер әйтәчәгемне, әлбәттә, беләидем, әмма нәкъ менә шул көнне, шул урында дип уйламадым. Кары матур ява иде шул!

Яңа елдан соң әниләр белән Актүбәгә кыз сорарга киттек. Безнең Бәрәңгедән Казанга кадәр 150 чакрым, Казаннан Актүбәгә кадәр тагын да күбрәк. Кайтабыз, кайтабыз... Караңгы төшә башлады. Әти шул вакыт: «Улым, кызны якын-тирәдәнрәк табып булмый идеме соң?» – диде. Хәзер дә искә төшереп көлешәбез.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Әле армиягә киткәнче үк: «Хатыным да әни шикелле булсын иде», – дип тели идем. Аның кебек үк көдрә чәчле, шундый ук сөйкемле карашлы... Яшим дип ашкынып торган. Әни белән Луиза йөз-биткә охшаган дип әйтә алмыйм. Әмма эчке дөньялары, аш-су әзерләүләре, өйне ничек итеп җыештыруларына кадәр бер аларның!

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бүгенге көндә очрый торган күренеш. Әлбәттә, ир-ат акчаны күбрәк эшләргә тиеш. Ләкин шулай килеп чыккан икән инде, моңа карап дөнья бетми бит. Хатын-кыз бертуктаусыз: «Син миннән акчаны азрак табасың», – дип ирен битәрләп тормаса, бетми. Әйткәнемчә, тормыш бик катлаулы, иртәгә ул ничек, кай якка борылыр – беребез дә белми. Бер-береңне аңлап яшәгәндә, гаиләдәге мондый авыррак чорны да узарга буладыр ул. Хатын-кыз: «Аллага шөкер, ирем исән-сау, үзем исән-сау», – дип, күбрәк кабатласа, проблема артык зур булып тоелмас.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Оялчан ир-егетләр дә бар бит арабызда. Холык бит инде ул, аны үзгәртеп булмый. Шундый очракта хатын-кыз дилбегәне үз кулына алудан кемгә начар?! Мин хәтта бу сөйләшүне болайрак итеп күз алдына да китерәм. Бер-берсенең күзләренә карап йөрүдән берничек тә уза алмагач, кыз беркөнне егетне туктата да: «Карале, мин бит сине бик каты яратам, синсез яши алмыйм, әйдә, минем ирем бул», – ди. Тегесе: «Ярар, мин риза...» – дип, шунда ук күнә.

9 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Мин бит җырлар да язам. Ә җыр җиңел тумый, ул мизгелләрдә үзгә бер халәттә яшәп аласың. Андый чакта бөтен нәрсәне, һәр әйткән сүзне йөрәккә артык якын кабул итәм. Бу вакытта миңа күбрәк игътибар кирәк. «Нигә бу Луиза мине аңламый икән инде?» – дип уйлаган вакытлар була шул...

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Эшендә нинди дер борчуы булса, Луиза өйдә дә нигәдер бик озак шуның белән яши: әле алай, әле болай дип уйлый. Мин үзем «минемчә булырга тиеш» дим дә, кисәм дә куям. (Болай әйтү дөрес кенә булмый булуын.)

Аңламаган очракларның тагын берсе: ялга барырга җыенабыз, инде кая барасы хәл ителгән, акчасы түләнгән – путевка кулда. Ә Луиза һәрвакыт сайлавын дәвам итә: тегендә отель яхшырак, монда бәясе арзанрак... Нигә, белмим.

11 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып кересез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Ачуым чыгар иде инде анысы... Тик кафега да чыгып китмим, пиццага да заказ бирмим. Беркайчан да! Әллә нәрсә майтара алмасам да, тотам да үзем пешерәм. Йә бәрәңге кыздырам, йә шулпа куеп җибәрәм (итен пешәр-пешмәс килеш алып, ваклап турап кире салсаң, тиз өлгерә ул). Шулпасыз яши алмыйм – ким дигәндә көнгә бер тапкыр шулпа ашарга кирәк миңа.

12 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Чынлап та шулай бит бу! Каядыр барырга җыенсак: «Бу күлмәкне киимме, тегесенме, ә бәлки чалбардан барыргадыр...» – дип тотына. «Синең күлмәкләр белән шкаф тулган, концерт костюмнарыма урын юк. Ничек инде шуннан нәрсә кияргә икәнен таба алмыйсың?!» – дип аптырыйм. Соңга кала башлыйбыз... Түзмим, машинага чыгып утырам да, шунда көтәм. Ул, ниһаять, чыккач, башта сөйләшмәгән булам, аннары онытам, билгеле.

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Бер-беребезгә бүләк бирү гадәте бездә дә бар. Ул миңа, гадәттә, футболка, эчке кием-салым кебек әйберләр ала. Нәрсә бүләк итсә дә: «Нигә моны алган инде?» – дигәнем юк. «Бу бит мине һаман ярата икән әле», – дип кенә уйлап куям. Ә мин... хушбуй бирергә яратам. Сирәк кенә – чәчәкләр. Яшьрәк чакта алган булды. «Акча әрәм итмә, өч-дүрт көннән сулалар, берәр кирәкле әйбер, һичьюгы гөл алып кайт», – диде дә, шуннан сүрелдем... Кая барсам да, эре бөртекле яхшы чәй алып кайтырга тырышам. Балалар торганчы, икәү утырып, куе итеп ясалган сөтле чәй эчәргә яратабыз. Әле битләр юганчы, чәчләр тараганчы ук... Иң тәмле чәй шул вакытта!

PRESSA.RU

БӘЙРӘМЕБЕЗ БЕЛӘН,

Казан үзәгендәге аулак бер урамда хатын-кызларны бәхетле итә торган урын бар – «ЛЮКС» бутигы ул. Минем бутик. Хыялымны ничек тормышка ашыруым, хатын-кызлар өчен кибет кенә түгел, бер утрау булдыруым турында сөйләп, укучыларның башын катырасым килми. Бүген сезнең белән үзебез турында сөйләшәсем килә.
Күпләребез тормыштан никтер канәгать түгел. Нигә икән? Шул хакта уйлап караганыгыз юкмы? Гәүдәсе, тышкы кыяфәте, яше, эше, өе, ире, балалары, туганнары, дуслары – берсе дә ошамый аңа... Сәбәпләр табыла инде ул. Һәрчак нәрсәнедер яхшыртырга, үзгәртергә кирәк була. Борчылу, җан тынычлыгын югалту өчен дә җае чыгып кына тора. Кәеф төшә, үз-үзеңнән канәгатьсезлек тоясың... Үзебезнең җитеш дөньяга, рәхәтлекләргә рәхмәтле була белергә кирәк безгә. Тормышыбыздагы яхшы якларны күрә белергә һәм шуңа сөенергә кирәк. Бәхетле була белү бер дә кыен түгел. Булганына канәгать итә һәм рәхмәтле була белергә кирәк. Тормыштагы бер әйберне гел истән чыгармау мөһим. «Нәрсә генә булмасын, һәр мизгелдә, теләсә нинди очракта бәхетле буласым килә минем!» – дип яшәгез.

Матур төс-кыяфәт, кирәкле вакытта тиешле урында була белү – уңышның нигезе, диләр. Килешмим.
Атаклы киноактриса Софи Лорен менә нәрсә ди бу хакта: «Хатын-кыз олыгая барган саен, мораль һәм физик дисциплинага мохтаҗ була башлый. Түземлек, үз-үзеңне каты кысада тоту һәм үҗәтлек – чын ледины гади хатыннан аерып куя торган сыйфатлар менә шулар. Әллә ни күзгә ташланып тормаса да, кабатланмас була белүе, ныклы холкы белән ул башкалар янында дөньяда бер матур булып күренә. Эчке гармония һәм тынычлык – хатын-кызның иң күркәм сыйфаты».
«Тышкы кыяфәтең күңел кайтарырлык булса, эчке дөньяң берәүгә дә кызык тоелмас. Акыллы кеше беркайчан да тышкы кыяфәтен күздән кичермичә кеше арасына чыкмый», – журналист, мода дөньясында билгеле Эвелина Хромченко фикере бу.
Бутик хуҗасы буларак, әлеге атаклы ханымнарның һәр сүзен хуплыйм. Уйлаганың тормышка ашсын дисәң, үзеңдәге эчке һәм тышкы гармонияне килештерә белергә кирәк. Эчке гармониядән башка дөрес киенә белү мөмкин түгел. Бу очракта мин: «Зәвык белән, кайда һәм кайчан киясеңне белеп, холкыңа килештереп», – дип тә өстәр идем. Психологлар фикеренчә, дөрес итеп киенгәндә генә кеше үзен ышанычлы һәм уңайлы хис итә икән. Шул чакта гына синең костюмыңа түгел, йөзеңә карыйлар. Үлчәме, гәүдәгә һәм яшеңә туры килеп торуы белән генә килешле була алмый әле кием. Сайлаган образ кәефеңне, холкыңны да чагылдырырга тиеш. Кием урынга һәм вакытка карап та сайлана.
Мин хатын-кызларны күзәтергә яратам: киенүләрен, атлап йөрешләрен, сөйләшүләрен... Юк, мин тәнкыйтьче түгел. Анализ гына ясыйм шулай. Хатын-кызны үзенә читтән карарга өйрәтү – ул минем бурычым, ә «ЛЮКС» бутигы аларга үз образын табарга булыша. Килешәсезме? Киемне дөрес сайлый белү шулай ук мөһим, ләкин ул гына да җитми әле. Иң мөһиме: йөзеңә кунган елмаю, якты караш, күңелең белән яшь калу, яшисе килү!
Урамда – яз. Бәлки, күпләрегез әле күреп тә өлгермәгәндер, ләкин кояш инде башкача җылыта, кошлар да бүтәнчә сайрый, тирә-як елмаюлардан гына тора диярсең. Безне бәйрәм көтә – 8 Март!
Ул безнең бәйрәм! Яз башында бәйрәм итүнең дә үз сере бар. Хатын-кыз гына дөньяга яңа тормыш алып килергә, аны матурлыкка һәм гармониягә күмәргә сәләтле!

Сезнең НАТАЛИ



ГҮЗӘЛ ЗАТЛАРЫБЫЗ!



PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Татарстанның атказанган артисты, «Татар җыры» лауреаты Раяз ФАСИХОВ аш-су тирәсендә кайнашырга яратмый, ул моны үзе дә яшерми. «Шулай да, 8 Март үзенчәлекле бәйрәм, бу көнне кадерле кешеләреңне бераз иркәләми булмый. Мин хатыным Люциядән уздырып пешерә белмәсәм дә (ә менә аныкы искиткеч тәмле була!), бу көнне аның күңелен күрергә, һәм кызыбыз Венера белән икесенә берәр күңелле һәм, әлбәттә, тәмле сюрприз ясарга яратам. Аларны сөендерү җаныма шулкадәр рәхәт – менә шул мизгелләр өчен, хәтта кулны камырга тыгарга да риза булырсың», – ди халык күңелен яуларга өлгергән җырчы егетебез. «Оста кулинар түгел мин», – дип тыйнаклык күрсәтсә дә, Раязның синнабоннары искиткеч тәмле килеп чыкты. Балы да таман гына, мае да!



БӘЙРӘМ ЧӘЕНӘ – СИННАБОН



Кирәк:

(камыр өчен)

• 200 мл сөт;
• 10 г чүпрә;
• 2 йомырка;
• 1/3 стакан акмай (җылыда торып йомшарган);
• 4 стакан чамасы он;
• 0,5 стакан шикәр комы;
• 1 чәй кашыгы ванилин;
• 1 чәй кашыгы тоз;
• 1 аш кашыгы он җилеме (бер уч камырны салкын суда югач, кулда калганы он җилеме була).

Эчлек өчен:

• 1,3 стакан йомшарган акмай;
• 1 стакан көрән шикәр (агы гына да ярый);
• 4-5 аш кашыгы дарчин (корица).

Глазурь өчен:

• 7-8 аш кашыгы акмай (җылыда торып йомшарган);
• 1,5 стакан шикәр оны;
• 1/2 чәй кашыгы ванилин;
• 2-3 аш кашыгы каймаклы сыр («Филадельфия», «Маскарпоне», «Альметте» ише).



Эш барышы:

■ йомыркаларны суыткычтан алдан ук алып куярга кирәк, камырга салганда алар җылы булырга тиеш. Йомырканы зур савытка сытып, бик яхшылап туглыйбыз, сөт, шикәр комы, тоз, ванилин, май, он җилеме, чүпрә салып (чүпрәне бераз күпертеп алырга да була), йомшак кына итеп камыр басабыз. Он бераз кимрәк яки күбрәк китәргә мөмкин, күпме кирәген үзегез чамалагыз.

■ Камырны җылы җиргә күпертергә куябыз. Гадәттә, 2 сәгать дигәндә әзер була ул (ара-тирә баскалап, камырны төшереп торсаң, ул йомшак, күперенке, җиңел була).

■ Әзер камырны куна тактасына бушатып, 0,5 см калынлыгында җәябез. (Диаметры якынча 50 см чамасы була.)

■ Камыр өстенә мул итеп акмай ягып, күрән шикәр һәм дарчин сибәбез (шикәр белән дарчинны бергә бутап сипсәң, тагын да яхшырак).

■ Камырның бер читеннән тотып, рулет сыман төрәбез. Тыгызрак итеп төрергә тырышыгыз, алар бик җәелеп пешәргә тиеш түгел. Чын синнабоннар тыгыз була.

■ Рулетны нечкә кыл яки бик үткен пычак белән 3-4 см кисәкләргә бүләбез.

■ Таба төбенә пергамент (калька да ярый) кәгазь җәеп, синнабоннарны бер-берсеннән 1,5 см ара калдырып тезәбез. Араны зуррак калдырсаң, алар бик нык җәелә, якынрак тезсәң, пешми кала.

■ Синнабоннар 160–180 градустагы кайнар мичтә 20 минутлап пешә. Йөзе килсә, димәк, әзер.

■ Мичтән алып, бераз суынганнан соң, синнабоннар өстенә май канаты яки кашык ярдәмендә глазурь ягабыз.

Глазурь:

акмай, сыр, шикәр оны (әгәр дә шикәр оны булмаса, шикәр комын кофетарткычтан яки тегермәннән тарттырып ясап була), ванилинны бергә кушып, яхшылап туглыйбыз. Ул каймак куелыгында булырга тиеш. Катырак булса, җылы урынга куеп, бераз йомшартып алырга була.

Тиз генә кофе пешереп, синнабон белән икесен матур подноска урнаштырабыз да, сөеклебез уянганчы, сюрприз ясарга ашыгабыз. Бәйрәм белән сине, сөеклем һәм сезне дә, кадерле хатын-кызларыбыз!

PRESSA.RU




Күз явын алырдай чәчкәләргә карап, аларның шулкадәр кыска гомерле булуына уфтанучы бер мин генә түгелдер. Гөлсарга утыртырга да өлгермисең, шиңәргә генә торалар. Ә бу матурлыкны ничек тә озаграк сакларга иде бит. Киптерергә мөмкин, диярсез. Кипкән чәчәкләрнең чын матурлыгы бик тиз югала шул. Ә бит әчәкләрне шиңдермичә айлар, хәтта еллар буе да сакларга мөмкин. Бу бик катлаулы эш түгел. 8 Март бәйрәменә гөлләмә бүләк итсәләр, аның сулганын көтмәгез, тиз генә безнең киңәшләрне тотыгыз.

Мастер-классны
Лилия ГӘРӘЕВА
үткәрә

СУЛМАС ГӨЛЛӘР







Кирәк:

- чәчәкләр;
- матур пыяла савыт (банка, бокал);
- глицерин;
- кайнар су;
- матур ташлар, сәйләннәр;
- фольга;
- декоратив тукыма;
- тар атлас тасма;
- ике ягы да ябышкак тар скотч

Эш тәртибе:

■ савытка никадәр сыеклык кергәнен исәпләргә кирәк. Шуның ике өлеше күләмендә – су, бер өлеше күләмендә глицерин алына. Глицеринны кайнар суга салып, суынырга алып куябыз.

■ Саклыйсы чәчәкләрне сайлап алып, корыган, шиңгән таҗ яфракларыннан арындырабыз һәм үзебезгә кирәк булган кадәрен генә алып, сабагын үткен пычак яки кайчы белән кыйгачлап кисеп алабыз. Кискән урынны бераз яргалап җибәрәбез, сабак очының каерысын кубарабыз. Кипкән яфракларны да өзеп алырга кирәк.

■ Сыеклыкка батыргач, чәчәкләр



өскә калкып чыга (ике атнадан, глицеринны сеңдергәч, ул төпкә төшеп утыра утыруын, әмма аңынчы өстә йөзеп йөрергә мөмкин). Моны булдырмас өчен, чәчәкләрне сабак очыннан гына гади җеп белән авыррак берәр ташка яки зуррак сәйләнгә бәйлибез.

■ Савыт төбенә декоратив ташлар салып калдырып (бу – матурлык өчен генә, мәҗбүри түгел), чәчәкне урнаштырабыз. Күбрәк чәчәк сыйдырам дип, дыңгычларга ярамый. Савытның зурлыгына карап, бер яки ике-өч чәчәк җитә. Ваграк чәчәкләрне ишлерәк тә итәргә була. Чәчәк өстеннән сак кына глицерин белән су катнашмасын коябыз. Ул чәчәкләрне тәмам күмәргә тиеш. Әгәр дә капкачлы савыт кулланса-гыз, капкачын һава кермәслек итеп борып кына куясы кала. Без исә композицияне бокалга урнаштырдык. Аның капкачы юк.

■ Фольгадан бокал авызыннан 1 см чамасы зуррак итеп түгәрәк кисеп алабыз. Капкач шул булачак. Бокал авызы тирәли ябышкак тасманы ябыштырып, фольганы каплыйбыз, читләрен сак кына сыпырып (фольга тиз ертылучан, сак булырга кирәк), тасмага ябыштырабыз. Аның өстеннән декоратив тукыма (ул челтәр дә булырга мөмкин, җитен дә) каплап, тар гына атлас тасма белән күбәләкләп бәйләп куябыз.

■ Чәчкәле савытны ике-өч атнага караңгы салкынча урынга куябыз. Бу вакыт эчендә савыттагы су саргаерга, хәтта чак кына исләнергә дә мөмкин. Ул шулай булырга тиеш.

■ Савыттагы сыеклыкны бушатып, яңадан шушы ук микъдарда глицерин кушылган су салабыз. Монысы инде – озакка, һәрхәлдә, савыттагы чәчәкне башкасына алыштырасыгыз килгәнчегә кадәр.

ЧӘЧӘКЛӘР САЙЛЫЙБЫЗ

■ Роза, лалә кебек, тиз сула торган чәчәкләр сайлаганда игътибарлырак булырга кирәк. Флористлар алдан әзерләп куйган гөлләмәләргә кызыкмагыз, аны үзегез сайлаган чәчәкләрдән ясауларын сорагыз.

■ Роза белән лаләнең таҗлары әле ачылып бетмәгәннәрен алсагыз яхшырак, өйгә кайткач, алар тулысынча ачылачак һәм озаграк торачак.

■ Чәчәкләрнең кайчангы булуын бутон төбендәге касә яфраклары да «әйтеп бирә». Күптән түгел генә киселгән чәчәкләрдә алар бутонга терәлеп үк тора, ә күптән киселгәннәрендә ул аска таба салынып төшкән була.

■ Өйгә алып кайткач, чәчәкләрне бүлмә җылылыгындагы суга утыртыгыз, утыртасы суга 1-2 шакмак шикәр, шулай ук 1 литр суга 1 төймә исәбеннән аспирин яки 1 аш кашыгы аш серкәсе салырга була. Бу аларны тукландыру өчен кирәк.

■ Вазага утыртыр алдыннан сабак очларын үткен пычак белән кыйгачлап кисеп, 1-2 см чамасы кыскартабыз. Моны чәчәкләрнең суын алыштырган саен да кабатлыйлар.

■ Суга чәчәкләрнең сабаклары гына кереп торырга тиеш. Астагы яфракларны өзми калдырсаң, алар тиз арада череп, суны бозачак.

■ Өйдә һава эссе һәм коры булса, бутоннарга һәр 5-6 сәгать саен пульверизатордан су бөркеп торсаң яхшы.

PRESSA.RU



КАЙДА, КЕМ, НИЧЕК?

Дөньяның төрле почмагында яшәүче хатын-кызларның зифалык, чибәрлек җәһәтеннән үз серләре бар. Аларның күбесе матурлыкны сылулык дип белә. Әйдәгез әле, кайбер илләрдәге яшерен серләрнең читен ачып карыйк.

Япония

Суүсемнәр. Японнар суүсемнәрне ашларга да сала, салатка да куша, суши, ролл дигән ризыкларын да суүсемгә төрә. Анда май юк диярлек, протеиннар, витаминнар, йод бар. Суүсемнәр матдәләр алмашын тизләтә, кандагы шикәрне киметә.

Киңәш: диңгез кәбестәсе, помидор, суган, зәйтүн җимешеннән салат ясагыз да, зәйтүн мае белән тәмләтеп җибәрегез.

Доминикана

Кырку ризыклар. Кариб диңгезе утрауларында ачы, кырку ризыклар яратучылар яши. Чили борычы, табаско (соус)ише үтеңне сытарлык тәмләткечләр матдәләр алмашын «кыздырып» җибәрә дә, калория дигәне бик тиз янып бетә икән. Андый тәмләткечләр иммунитетны бик тә яхшырта.

Киңәш: татлыны кырку белән аралаштыр. Мәсәлән, тавык итен чили борычы һәм ананас белән аша.

Тунис

Кузаклылар. Тунис гарәпләренең табынын кузаклылардан башка күз алдына да китереп булмый. Чөнки ногыт, борчак, фасоль ише кузаклыларда май юк, ашкайнатуны яхшырта торган җепселле матдәләр байтак.

Киңәш: борчак, фасоль ашын ешрак пешер, салатка яшел борчак куш.

Финляндия

Арыш сохарие. Финнар кетердәгән ипи ашарга яраталар. Дөрес эшлиләр бит, әй! Юка гына итеп киптерелгән арыш ипие телемнәре эчәкләрнең эшчәнлеген яхшырта, кандагы шикәрне киметә. Җитмәсә, туклыклы да икән бит әле.

Киңәш: эремчекле сыр яки майсыз эремчек янына сохари куй. Редис, тавык түше, кыяр белән дә сохари аша.

Һиндстан

Карри. Һиндстанда каррилы һәр катнашманың аерым бер тәме бар. Ул тәмләткечләрнең барысы өчен дә уртак нәрсә – чили борычы, кара борыч. Алар аппетитны киметә, матдәләр алмашын яхшырта.

Киңәш: карри майсыз ит белән, мәсәлән, тавык ите белән әйбәт бара.

Испания

Чи яшелчә белән туклану. Испан кызлары күп итеп яшелчә ашарга яраталар. Пешмәгән яшелчәдә калорияләр бик аз була. Мае да юк, витаминнары да күп.

Киңәш: туклыклы матдәләр кытлыгы башланмас өчен ярма ризыклары, йогуртлар да ашарга онытма. Бездә катык инде ул.

Голландия

Педаль әйләндер! Голланд кызлары артык авырлыкны велосипед ярдәмендә киметә. Велосипедта акрын тизлектә берәр сәгать йөреп кайту да 380 килокалорийны яндыра.

Киңәш: көн саен велосипедта йөргән кешеләр сирәгрәк авырыйлар.

Греция

Зәйтүн мае. Тәза яшелчә-җимеш, сөт ризыклары, балык, аз-маз гына ит – менә шушы инде греклар табынында. Зәйтүн мае да шушы исемлектә. Зәйтүн мае тәнгә үргән майны яндыра, калорияләрне эшләтә. Кандагы шикәрне дә киметә.

Киңәш: ризык әзерләгәндә зәйтүн, йә рапс мае файдалан.

Кытай

Яшел чәй. Кытайлар ярата торган яшел чәй ярдәмендә бик тиз ябыгырга мөмкин. Яшел чәй составындагы матдәләр тәнне җылытып җибәрә, шуңа күрә калорияләр сарыф ителә.

Киңәш: су кайнап чыккач, беркадәр сүрелсен. Ике минуттан соң гына суны чәй өстенә кой. Өч минут пешсен чәең.


Кучкар. Яңа күтәрелешләр һәм яңа уңышлар ае. Кул кушырып ятмасагыз, күпкә ирешәчәксез. Шәхси тормышын үзгәртергә теләүчеләр өчен яхшы вакыт. Ай ахырында гениаль фикерләр туар, аларны хәтта язып барсагыз да була.


Үгезбозау. Күбрәк ял итегез. Бу айда зур эшләргә алынмагыз, яңаларын башламагыз. Кыйммәтле әйбер сатып алганда яки кәгазьләргә кул куйганда җентекләп өйрәнегез, алдану ихтималы зур.


Игезәкләр. Иҗади көчнең активлашкан чоры. Моңарчы бернинди сәләте беленмәгән кешеләрнең дә тирә-юньдәгеләрне шаккаттыруы ихтимал. Мөһим эшләрне айның беренче ун көнендә төгәлләгез.


Кысла. Тормышыгызда үзгәрешләр булыр, абруегыз да, керемегез дә артыр. Күңелегездә йөрткән хыялыгызны да тормышка ашыра алырсыз. Тирә-юньдәгеләр, үзләре дә сизмәстән, сезгә ярдәм итәчәкләр. Белем алу, яңа эшкә өйрәнү өчен яхшы вакыт.


Арыслан. Уңышлы ай. Үзегезгә нәрсә кирәген яхшы беләсез, максатыгызга җиңел ирешерсез. Көтелмәгән керем керү ихтималы бар. Ай уртасында эшлекле тәкъдим булыр, яңа мөмкинлекләр ачылыр.


Сөмбелә. Күңелле мәшәкатьләр бөтереп алыр. Сәбәбе нинди генә булса да, алар җаныгызга рәхәтлек бирәчәк. Айның икенче яртысында тормышыгызга яңалык кертердәй кеше белән очрашырсыз, тормышка карашыгыз үзгәрер.


Бизмән. Шатлык-сөенечләргә бай ай булыр. Яңа мөмкинлекләр ачылырга тора, уяу булыгыз. Хыялыгызда гына йөрткән максатыгызга ирешү юлын күрерсез, файдасы тиярдәй кешеләр белән танышырсыз.


Чаян. Көчле тәэссоратлар һәм кичерешләр вәгъдә итүче ай. Шәхси тормышыгызда уңай якка үзгәрешләр булыр, тотрыклы керем чыганагы барлыкка килер. Ниятләнгән эшләрегезне башкарып чыгарсыз.


Укчы. Яңа танышлыклар, яңа тәэсирләр ае. Җаныгыз иреккә омтыла, бераз күңелегезне күрү җаен да карарга тырышыгыз. Моңа кадәр «йокымсырап яткан» талантларыгыз ачылыр. Белем алу, яңа эшләргә өйрәнү өчен бик кулай чор.


Кәҗәмөгез. Искиткеч мөмкинлекләр ае, алдыгыздагы һәр ишек ачык булачак. Кыюрак эш итсәгез, әллә нинди уңышларга ирешеп, үзегезнең нәрсәгә сәләтле булуыгызны күрсәтә алырсыз.


Сукояр. Ай башы тыныч узса да, ай урталарына таба вакыйгалар ташкыны бөтереп алыр. Ерак арага сәфәр чыгу ихтималы зур. Эшегездә үзгәрешләр булып, югарырак вазыйфа тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Финанс ягы тотрыклыланыр.


Балык. Беренче урында торган мөһим эшләрне барлап, көчегезне әлегә шуларга гына сарыф итегез. Вазыйфаларыгызга кермәгән эшләргә алынмагыз. Йолдызлар сезгә яхшы тәэсирләр, шатлыклы вакыйгалар вәгъдә итә.

*Март*та кабынган йолдызлар

Татарстан



Ләлә Сабирова (1.03.1947) – **балалар язучысы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.**

Элеккеге Дөбъяз (хәзерге Биектау) районының Мәмдәл авылында туа. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлап, «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1971–1988 елларда – Биектау районының Олы Битаман мәктәбендә укытучы, директор урынбасары. 1988 елдан ул кабат Казанда – «Яшь ленинчы» (1990 елдан «Сабантуй») газетасында хезмәт куя. 1995 елдан ул шунда баш мөхәррир. Балалар язучысы буларак, матбугатта 1960 нчы еллардан башлап күренә. 1964 елда «Тылсымлы таяк» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. «Кызарган алмалар» һәм «Мыеклы фәрештә» исемле китаплары дөнья күрә.

Россия



Тамара Акулова (25.03.1957) – **Россиянең атказанган артисты.**

Воронеж өлкәсенең Новая Усмань авылында туган кыз кечкенәдән ишегалдында спектакль куеп мәш килсә дә, мәктәпне тәмамлагач, политехника институтына укырга керә. Анда бер ел укыгач, документларын ВГИКка тапшыра. Ул елны монда бер урынга 380 кеше гариза бирә. Тамарага бәхет елмая. ВГИКны уңышлы тәмамлый һәм шул елны ук аны «Бедная Маша» фильмында баш рольгә чакыралар. Сергей Тарасовның «Баллада о доблестном рыцаре Айвенго» фильмында уйнап танылу ала. Әле дә үзенең иң уңышлы эше дип, ул шушы фильмны атый. «В поисках капитана Гранта», «Воскресный папа» – 80 нче еллар тамашачысы аны шушы фильмнар аша да яхшы белә.

Чит илләр



Гленн Клоуз (19.03.1947) – **актриса, продюсер.**

Ике мәртәбә «Алтын глобус», өчәр мәртәбә «Эмми» һәм «Тони» премияләре иясе булган атаклы актриса Американың Коннектикут штатында туса да, балачагы Конгода үтә. Әтисе анда медицина клиникасын җитәкли, кызын да медик булырга әзерли. Әмма Гленның хыялы сәхнә була. Швейцариядә урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, үз сүзен сүз итеп, театр мәктәбенә укырга керә. 20 яшеннән чыгыш ясый башлый. Беренче зур ролен 25 яшендә Джордж Рой Хиллның «Жизнь по Гарпу» комедиясендә уйный. Гленны ул чакта ук «Оскар» премиясенә тәкъдим итәләр. Әмма алты тапкыр тәкъдим ителеп тә, аның әле «Оскар»ны ала алганы юк.

PRESSA.RU





МАТУРЛЫК

Итекчедән – итекче, читекчедән читекче туа диләр икән, ул чагында портрет остасы, профессиональ рәссам Нәкый Әбделкәрим улы Бикташев кызының да әтисе юлыннан китүенә гаҗәпләнәсе түгел. Әтисенең замандашлары Виктор Куделькин, Лотфулла Фәттахов, Мәхмүт Усманов, Ефим Симбирин кебек мәшһүр рәссамнарның Земфирага гел гел йә буяу, йә кылкаләм, йә карандаш бүләк итүләренең гаҗәбе юк. Менә шуннан соң рәссам булмый кара инде син! Башта сәнгать мәктәбенә йөри, аннан Казанның сәнгать училищесында укый. Әтисе белән Рәссамнар берлегенең сәнгать фонды баскычыннан төшеп барганда Бакый ага Урманче очрый үзләренә.

– Бу – минем кызым Земфира. Быел үзебезнең училищега укырга керде, – дип таныштыра әти кеше Урманчены кызы белән.

Шул чагында түшенә гел алъяпкыч ябып йөрүче олпат рәссамның: «Мин синең яхшы рәссам булачагыңа ышанам, кызым», – дип, башыннан сыйпаганын хәтерли әле Земфира. Хәзер инде бик аңлый: үзенә күрә фатиха бирүе булган аксакалның.

2005 елда рәссамнарга Урманче премиясен тапшыру тантанасында үзе дә махсус бүләккә ия булгач, кабат хәтерендә яңарта Земфира Бикташева әлеге вакыйганы.

Урманченың юраганы чыннан да юш килде. 1996 елдан Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы ул. Республика, Бөтенроссия, төбәк һәм халыкара күргәзмәләрдә, симпозиумнарда еш катнашып килә. Символ-тамгаларга корылган гаҗәеп паннолар иҗат итүче гамәли сәнгать рәссамы Земфира ханым бүген чыннан да үз өслүбе, үз йөзе булган оста. Аның татар милли бизәкләренә нигезләнеп башкарылган эшләрен ялгышып та башка берәүнеке белән бутамыйсың. Аныкылар үзенә бер: милли дә, купшы да, зәвыклы да, җете дә. Берьюлы берничә техникага – чигү (тамбур җөй), аппликация, «колаклы» техникага мөрәҗәгать итү дә аның өчен ят нәрсә түгел. Яраштыра, килештерә белә ул аларны. Ул ныклап үзләштергән атлас тасмалардан эшләнә торган «колаклы» («тырнаклы» дип тә әйтәләр) бизәү ысулы борынгыдан ук килә торган сәнгати алым.

– Беренче тапкыр әлеге техника нигезендә эшләнгән калфакны Сынлы сәнгать музеенда күрдем. «Мондый ысул белән хәзер эшләүче юк инде», – диделәр. Шулчак моны өйрәнәчәкмен, гамәли сәнгатебезгә кире кайтарачакмын дип, күңелемә салып куйган идем, – ди оста.

Һәм кайтара да! Иҗатының башлангыч чорында аппликация янәшәсендә тамбур җөй белән теләк рәвешендә чигелгән «Хәерле иртә!», «Исәнлек-саулык» кебек сүзләрне яки шагыйрьләребезнең икеюллыкларын, дүртьюллыкларын очраткан булсак, хәзер исә оста тулысы белән «колаклы» техникада башкарылган катлаулы композицияләргә өстенлек бирә. Бүген инде ул чын-чынлап иҗат үрендә. Соңгы вакытта рәссам март аенда «Хәзинә» милли сәнгать галереясында озачак шәхси күргәзмәсенә әзерләнә.

Моннан элегрәк оештырган күргәзмәләренең берсендә Земфира ханым елап торган бер тамашачыны күреп, ни булды икән дип, янына барса, бөтенләй дә көтелмәгән җавап ишетә: «Матурлыктан күңелем тулды... Тыелып кала алмадым». Рәссамның эшләрен караганда күңелләр матурлыктан, нәзакәтлелектән, камиллектән мөлдерәмә тулса да гаеп түгел.

Расиха ФАИЗОВА













ЗЕМФИРА БИКТАШЕВА

PRESSA.RU

КОТЛАУЛАР



**Әдип Абдулла улы ХӘЙРУЛЛИН
Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсенең профсоюз оешмасы рәисе**

Без яшьлек шәһәре Түбән Камада яшибез. Бездә зур эшләр кайный. Түбән Кама «Нефтехим» акционерлык җәмгыяте җитештергән синтетик каучук, пластик материаллар, этилен дөньяның төрле почмакларына җибәрелә. Һәм анда фидакарь хатын-кызларыбызның да өлеше бихисап! Алар нефть эшкәртә, химия ярдәмендә могҗизалар тудыра, балалар үстерә, агачлар утырта, ак калабызны гөлләргә күмә... «Сөембикә» журналы аша барлык хатын-кызларыбызны 8 Март – яз һәм чәчәкләр бәйрәме белән котлыйм! Сез – дөньябызны ямьләүчеләр, гадәти көнкүрешебездән әкият ясаучылар. Елмаюлар, сөенечләр, чәчәкләр, җылы сүзләр ничек килешә сезгә! Гел шулай ягымлы, нәфис, матур булыгыз! Һәммәгезгә сәламәтлек, бәхет телим!



**Ришат Рәсим улы ГАЛИМОВ
Түбән Кама районы Сухарево авылы җирлеге башлыгы**

*«Белое солнце пустыни» фильмын хәтерлисезме? Миңа «Ел хатын-кызы-2017» бәйгесендә, хатын-кыз карашы аша «Ел ир-аты» дигән номинациядә катнашырга тәкъдим иттеләр, һәм без кылт итеп шушы фильмны искә төшердек! Зәринә, Җәмилә, Гүзәл, Сәидә, Зөһрә, Ләйлә... Мин, имеш, кызылармеец Сухов. Хатын-кызларыбызны тезеп бастырдым да, һәркайсын үз исемнәре белән барлап чыктым, эшләрен тикшердем, йомышлар куштым... Үз авылыбыз тормышын сәхнәләштереп күрсәттек шулай! Ә бит шул гүзәл затларыбыз – йорт, авыл, туган җир теткасы! Шуңа күрә безнең тормыш ипле, җайлы, тәртипле. Янәшәбездә яз кебек ягымлы, кояш кебек җылы, гөрләвекләр кебек ашкынулы, чәчәкләр кебек нәфис гүзәл затлар булганга, дөньябыз бөтен.
Бәйрәмегез котлы булсын!*

«Сөембикә» журналы – бәйрәмгә иң әйбәт бүләк
Язылу индексы: 73002 (РФ регионнарында), П2204 (Татарстан буенча)